«Татарстан Республикасы Алабуга суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары суд участоклары чикләре турында» 2011 елның 19 маендагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кушымтасына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 5; 2013, № 6 (II өлеш), 3 нче суд участогы чиге тасвирламасының икенче абзацыннан «һәм Алабуга шәһәренең басу аша кишәрлеге» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.



**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 10 мае
№ 27-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 452. «Татарстан Республикасы Казан шәһәре суд районнары буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Казан шәһәре суд районнары буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» 2011 елның 16 июнендәге 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 6 (I өлеш); 2013, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтада:

а) 1 нче суд участогы чиге тасвирламасында «торак пункт кырые буйлап уза торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 нче суд участогы чиге тасвирламасында «(Борисоглебский торак пункты)», «КАПО-14» бакчачылык ширкәте һәм Борисоглебский торак пункты» сүзләрен төшереп калдырырга, «территорияләрен» сүзен «территорияләрне» сүзенә алмаштырырга, «, Крутушка, Щербаково, Кадышево, Зәңгәр Күл торак пунктлары территорияләрен кертеп,», «торак пункт кырые буйлап уза торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 5 нче суд участогы чиге тасвирламасында «(Борисоглебский торак пункты)», «КАПО-14» бакчачылык ширкәте һәм Борисоглебский торак пункты территориясе кырыеннан» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 2 нче кушымтаның 8 нче суд участогы чиге тасвирламасында «төньяк-көнбатышка таба Мәскәү урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп,» сүзләрен «көньяк-көнчыгышка таба Мәскәү урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп,» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 нче кушымтада:

а) 2 нче суд участогы чиге тасвирламасында «360 метр төньяк-көнбатышка таба Калинин торак пунктының төньяк-көнчыгыш кырые буйлап» сүзләрен «көнбатыш юнәлештә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 нче суд участогы чиге тасвирламасында «Юдино торак пунктында» сүзләрен төшереп калдырырга, «Лейтенант Красиков, Бирюзовая урамнары һәм Политехника тыкрыгының» сүзләрен «Лейтенант Красиков, Бирюзовая һәм Политехника урамнарының» сүзләренә алмаштырырга, «Юдино торак пунктының көнчыгыш кырые буенча» сүзләрен төшереп калдырырга, «Ремплер торак пунктының» сүзләрен «Ремплер авылының» сүзләренә алмаштырырга, «, Урман арты торак пункты территориясен кертеп,», «(Яңа Юдино торак пунктын)» сүзләрен төшереп калдырырга, «Политехника тыкрыгына кадәр уза, алга таба, сул якта урнашкан йортларны кертеп, Политехника тыкрыгының күчәр сызыгы буйлап» сүзләрен «Политехника урамына кадәр уза, алга таба, сул якта урнашкан йортларны кертеп, Политехника урамының күчәр сызыгы буйлап» сүзләренә алмаштырырга, «Лейтенант Красиков, Бирюзовая урамнары һәм Политехника тыкрыгының» сүзләрен «Лейтенант Красиков, Бирюзовая һәм Политехника урамнарының» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 нче суд участогы чиге тасвирламасында «төньяк юнәлештә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге буенча, күпернең көнбатыш чиге буенча, аннары, торак пункт территориясен кертеп, Займище торак пунктының көньяк-көнбатыш кырые буенча» сүзләрен «төньяк һәм төньяк-көнбатыш юнәлештә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге буенча» сүзләренә алмаштырырга, «(Займище, Куземетьево һәм Кызыл Тау торак пунктларын)», «Юдино торак пунктында» сүзләрен төшереп калдырырга, «Политехника тыкрыгына кадәр» сүзләрен «Политехника урамына кадәр» сүзләренә алмаштырырга, «Политехника тыкрыгының күчәр сызыгы буйлап» сүзләрен «Политехника урамының күчәр сызыгы буйлап» сүзләренә алмаштырырга, «Лейтенант Красиков, Бирюзовая урамнары һәм Политехника тыкрыгының» сүзләрен «Лейтенант Красиков, Бирюзовая һәм Политехника урамнарының» сүзләренә алмаштырырга, «, Юдино торак пунктының көнчыгыш кырые территориясен кертеп,» «Юдино торак пунктының көнчыгыш кырые буенча» сүзләрен төшереп калдырырга, «, торак пункт территориясен кертеп, 360 метр көньяк-көнчыгышка таба Калинино торак пунктының төньяк-көнчыгыш кырые буйлап» сүзләрен «көнчыгыш юнәлештә» сүзләренә алмаштырырга, «(Яңа Аракчино, Иске Аракчино, Игумново торак пунктларын, 32 нче хәрби шәһәрчекне, бакчачылык ширкәтләрен)» сүзләрен төшереп калдырырга;



4) 4 нче кушымтада:

а) 6 нчы суд участогы чиге тасвирламасында «Левченко торак пункты янында», «, Левченко торак пункты территориясен кертеп,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 7 нче суд участогы чиге тасвирламасында «, Кызыл Октябрь торак пункты территорияләрен кертеп,» сүзләрен төшереп калдырырга, «Ремплер торак пунктының» сүзләрен «Ремплер авылының» сүзләренә алмаштырырга;

5) 5 нче кушымтада:

а) 1 нче суд участогы чиге тасвирламасында «(Дуслык торак пункты)» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 нче суд участогы чиге тасвирламасында «, Брикетный торак пунктындагы шәхси сектор йортларын кертеп,», «Брикетный торак пунктының көнчыгыш кырые буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 3 нче суд участогы чиге тасвирламасында «Дуслык торак пунктының» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 4 нче суд участогы чиге тасвирламасында «Брикетный торак пунктының көнчыгыш кырыена кадәр» сүзләрен «8 нче Кадыш урамында урнашкан шәхси сектор йортларына кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

6) 6 нчы кушымтада:

а) 1 нче суд участогы чиге тасвирламасында «, Мирный торак пункты территориясен кертеп,», «, Дәүләки, Петровский, Иске Победилово торак пунктларын кертеп,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 нче суд участогы чиге тасвирламасында «, Поповка торак пунктының шәхси секторындагы йортларны кертеп,» сүзләрен төшереп калдырырга, «Полянка» бакчачылык кооперативы» сүзләрен «Спартак» бакчачылык ширкәте» сүзләренә алмаштырырга, «Борисково торак пункты һәм «Хәрби шәһәрчек — 33» микрорайоны арасыннан үтүче автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, Борисково торак пункты территориясен кертеп, Ачинск урамына кадәр бара» сүзләрен «Ачинск урамына кадәр үтүче автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап бара» сүзләренә алмаштырырга, «, Калининский һәм Воскресенское торак пунктларын кертеп,» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 4 нче суд участогы чиге тасвирламасында «, Ферма-2 торак пункты территориясен кертеп,» сүзләрен төшереп калдырырга, «Полянка» бакчачылык кооперативының» сүзләрен «Спартак» бакчачылык ширкәтенең» сүзләренә алмаштырырга, «Борисково торак пункты һәм «Хәрби шәһәрчек — 33» микрорайоны арасыннан үтүче автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, «Хәрби шәһәрчек — 33» микрорайоны территориясен кертеп, Ачинск урамына кадәр бара» сүзләрен «Ачинск урамына кадәр үтүче автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап бара» сүзләренә алмаштырырга, «, Беренче Май торак пунктын кертеп,» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 6 нчы суд участогы чиге тасвирламасында «, Иске Таулар торак пунктының шәхси секторын кертеп,» сүзләрен төшереп калдырырга, «Салмачы торак пунктының көньяк-көнчыгыш кырыена кадәр (5 нче Яшел урамындагы йортлар) бара, алга таба көнбатыш юнәлештә Салмачы һәм Җимеш питомнигы торак пунктларының көньяк кырые буенча, Ванюшино күлен һәм» сүзләрен «5 нче Яшел урамындагы йортларга кадәр бара, алга таба көнбатыш юнәлештә 4 нче Яшел, 3 нче Яшел, 2 нче Яшел, Сабантуй, Овражная һәм Липки урамнары буйлап үтүче торак секторның көньяк чиге буенча, Ванюшино күлен кертеп, һәм алга таба төньяк-көнбатыш юнәлештә,» сүзләренә алмаштырырга;

д) 8 нче суд участогы чиге тасвирламасында «Җимеш питомнигы торак пунктының көнбатыш, көньяк һәм көнчыгыш кырыйлары буйлап, әлеге торак пунктын кертеп, Комиссар Гәбишев урамындагы 4 нче йортның төньяк-көнчыгыш ягыннан әлеге урамның күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза» сүзләрен «дәүләт урман фондының урман утыртмасы кырые буенча Липки урамына кадәр уза, аннары сулга борыла һәм, так якта урнашкан йортларны кертеп, Липки урамының күчәр сызыгы буйлап Лесная урамы белән кисешкәнгә кадәр һәм аннары төньяк-көнчыгышка таба урман утыртмасының көньяк-көнчыгыш почмагына кадәр уза, сулга борыла һәм урман утыртмасының көнбатыш чиге буйлап төньяк юнәлештә бара, аннары көнбатыш юнәлештә сулга борыла һәм, Клубничная урамындагы йортларны кертеп, Уртак һәм Ясмин урамнарының күчәр сызыклары кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Ясмин урамының күчәр сызыгы буйлап Листопадная урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары төньяк-көнбатыш юнәлештә Ромашкалар урамының һәм автомобиль юлының күчәр сызыклары кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Ромашкалар урамы буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба Комиссар Гәбишев урамындагы 4 нче йортның төньяк-көнчыгыш почмагына кадәр һәм алга таба Комиссар Гәбишев урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара» сүзләренә алмаштырырга;

е) 9 нчы суд участогы чиге тасвирламасында «, Алтан торак пункты территориясен кертеп,» сүзләрен төшереп калдырырга, «Салмачы торак пунктының көнчыгыш кырыена кадәр уза, алга таба уңга борыла һәм көнбатыш юнәлештә Салмачы торак пунктының көньяк-көнчыгыш, көньяк кырыйлары һәм Алтан торак пунктының көньяк кырые буйлап» сүзләрен «5 нче Яшел урамындагы йортларны кертеп, шушы урамдагы йортларга кадәр бара, аннары уңга борыла һәм көнбатыш юнәлештә торак секторның көньяк чиге буйлап, 4 нче Яшел, 3 нче Яшел, 2 нче Яшел, Сабантуй, Овражная урамнарындагы йортларны кертеп, автомобиль юлына кадәр уза, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба урман утыртмасының көньяк-көнчыгыш почмагына кадәр бара, сулга борыла һәм төньяк юнәлештә урман утыртмасының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көнбатыш юнәлештә сулга борыла һәм Уртак һәм Ясмин урамнарының күчәр сызыклары кисешкән ноктага кадәр бара, уңга борыла һәм төньякка таба Уртак урамының күчәр сызыгы буйлап, так яктагы йортларны кертеп, Уртак һәм Каенлы урамнарының күчәр сызыклары кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба сулга борыла һәм көнбатыш юнәлештә, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Каенлы урамының күчәр сызыгы буйлап» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 10 нчы суд участогы чиге тасвирламасында «, Вишневка һәм Восточный торак пунктларын кертеп,» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 7 нче кушымтада:

а) 2 нче суд участогы чиге тасвирламасында «Зур Клыки торак пунктының көньяк кырые буенча» сүзләрен төшереп калдырырга, «Вознесенское торак пункты кырыена кадәр» сүзләрен

«урман утыртмасының көньяк-көнчыгыш кырыена кадәр» сүзләренә алмаштырырга, «Вознесенское торак пункты кырые буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 нче суд участогы чиге тасвирламасында «һәм Царицыно зираты коймасының төньяк-көнчыгыш ягы буенча, «Нокса» бакчачылык ширкәте территориясен кертеп, Царицынский Бугор торак пункты кырыена кадәр бара, алга таба көнчыгыш юнәлештә Царицынский Бугор һәм Константиновка торак пунктларының төньяк-көнбатыш, төньяк-көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш кырыйлары буйлап, бакчачылык җәмгыятьләре һәм ширкәтләре территорияләрен кертеп,» сүзләрен «һәм, «Нокса» бакчачылык ширкәте территориясен кертеп, Царицыно зираты коймасының төньяк-көнчыгыш ягы буенча бара, алга таба Каспий урамының дәвамы булып төньяк-көнчыгыш юнәлештә автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап бара, аннары Бәхетле урамындагы 32А йорт каршында уңга борыла һәм төньяк юнәлештә автомобиль юлы буйлап Алмагач урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, уңга борыла һәм Алмагач урамының күчәр сызыгы буйлап «Табигать сөюче – 2» бакчачылык ширкәтенең көнбатыш почмагына кадәр бара, алга таба уңга борыла һәм көньяк-көнчыгыш юнәлештә «Яшелчәче» бакчачылык ширкәтенең төньяк почмагына кадәр, алга таба «Яшелчәче» бакчачылык ширкәте территориясенең көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап, бакчачылык ширкәтләренең территорияләрен кертеп, аннары көньяк юнәлештә» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 нче суд участогы чиге тасвирламасында «, Колсәет торак пункты территориясен кертеп,» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 6 нчы суд участогы чиге тасвирламасында «һәм Кече Клыки торак пунктының шәхси сектор йортларын» сүзләрен төшереп калдырырга, «һәм «Нокса» бакчачылык ширкәте коймасының көньяк-көнбатыш ягы буенча, Царицыно зираты территориясен кертеп, Царицынский Бугор торак пункты кырыена кадәр бара, алга таба көнчыгыш юнәлештә Царицынский Бугор һәм Константиновка торак пунктларының төньяк-көнбатыш, төньяк-көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш кырыйлары буйлап бакчачылык җәмгыятьләре һәм ширкәтләре территорияләре буенча, Царицынский Бугор һәм Константиновка торак пунктлары территорияләрен кертеп,» сүзләрен «һәм, Царицыно зираты территориясен кертеп, «Нокса» бакчачылык ширкәте коймасының көньяк-көнбатыш ягы буенча бара, алга таба Каспий урамының дәвамы булып төньяк-көнчыгыш юнәлештә автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап бара, аннары Бәхетле урамындагы 32А йорт



каршында уңга борыла һәм төньяк юнәлештә автомобиль юлы буйлап Алмагач урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, уңга борыла һәм Алмагач урамының күчәр сызыгы буйлап Кулагинская урамының күчәр сызыгының дәвамы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба тагын уңга борыла һәм, так якта урнашкан йортларны кертеп, Кулагинская урамының күчәр сызыгы буйлап, аннары Кулагинская урамының күчәр сызыгының дәвамы булып һәм алга таба көнбатыш юнәлештә Беловежская урамына кадәр бара, аннары көньяк-көнчыгыш юнәлештә, так якта урнашкан йортларны кертеп, Беловежская урамының күчәр сызыгы буйлап һәм алга таба көньяк-көнчыгыш юнәлештә «Яшелчәче» бакчачылык ширкәтенең төньяк почмагына кадәр бара, аннары «Яшелчәче» бакчачылык ширкәте территориясенең көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап һәм алга таба көньяк юнәлештә» сүзләренә алмаштырырга, «Самосырово торак пунктының көньяк кырые буйлап, Самосырово зираты һәм Самосырово торак пункты территорияләрен кертеп,», «, аның сул ярында урнашкан Зур Клыки торак пунктын кертеп, аның көньяк кырыена кадәр» сүзләрен төшереп калдырырга, «Зур Клыки торак пунктының көньяк кырые буйлап» сүзләрен «көнчыгыш юнәлештә урман утыртмасының төньяк чиге буйлап, Крутая, Тыныч һәм Балкыш урамнарындагы йортларны кертеп, торак секторның көньяк чиге буенча һәм алга таба» сүзләренә алмаштырырга;

д) 10 нчы суд участогы чиге тасвирламасында «, Вознесенское һәм Привольный торак пунктлары территорияләрен кертеп,», «Самосырово торак пунктының көньяк кырые буйлап», «Зур Клыки торак пункты буйлап» сүзләрен төшереп калдырырга, «Вознесенское торак пункты кырыена кадәр» сүзләрен «урман утыртмасының көньяк-көнчыгыш кырыена кадәр» сүзләренә алмаштырырга, «, Вознесенское торак пункты территориясен кертеп,» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 10 мае
№ 28-ТРЗ

## 453. «Россия Федерациясеннән депортацияләнергә йә административ чыгарып җибәрелергә тиешле чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча тоту өчен махсус учреждениеләрне Татарстан Республикасында булдыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Россия Федерациясеннән депортацияләнергә йә административ чыгарып җибәрелергә тиешле чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча тоту өчен махсус учреждениеләрне Татарстан Республикасында булдыру тәртибе турында» 2010 елның 25 декабрендәге 101-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 10 мае
№ 29-ТРЗ



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 454. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ һәм $6^2$ статьялар өстәргә:

«$6^1$ статья. **Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү**

1. Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен кирәгеннән артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә китерә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезләнмәгән чыгымнары барлыкка килүенә китерә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында уздырыла.

2. Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү җирле үзидарә органнары (җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары) тарафыннан

әлеге Закон нигезендә муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

3. Муниципаль норматив хокукый акт проектының җайга салу йогынтысын бәяләү нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органы (җирле үзидарә органының вазыйфаи заты) тарафыннан бәяләмә әзерләнә, анда муниципаль норматив хокукый акт проектында эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен кирәгеннән артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә китерә торган нигезләмәләрнең, шулай ук эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезләнмәгән чыгымнары барлыкка килүенә китерә торган нигезләмәләрнең булуы (булмавы) турында нәтиҗәләр булырга тиеш.

4. Әлеге статьяның 3 өлешендә каралган бәяләмә тиешле муниципаль норматив хокукый акт кабул итәргә (чыгарырга) вәкаләтле җирле үзидарә органы (җирле үзидарәнең вазыйфаи заты) тарафыннан карау өчен мәҗбүри була.

5. Әлеге статьяның 3 өлешендә каралган бәяләмәне карау нәтиҗәләре буенча фикер каршылыклары килеп чыккан очракта, мондый каршылыклар муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

6$^{2}$ статья. **Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза**

1. Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруны нигезсез кыенлаштыра торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында уздырыла.

2. Муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза тиешле җирле үзидарә органнарында раслана торган планнар нигезендә җирле үзидарә органнары (җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары) тарафыннан әлеге Закон нигезендә муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

3. Муниципаль норматив хокукый актка экспертиза нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органы (җирле үзидарә органының вазыйфаи заты) тарафыннан бәяләмә әзерләнә, анда муниципаль норматив хокукый актта эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруны нигезсез кыенлаштыра торган нигезләмәләрнең булуы (булмавы) турында нәтиҗәләр булырга, шулай ук, күрсәтелгән нигезләмәләр булган очракта, аларны бетерү алымнары хакында тәкъдимнәр булырга тиеш.

4. Әлеге статьяның 3 өлешендә каралган бәяләмә муниципаль норматив хокукый актны үз көчен югалткан дип танырга йә аңа үзгәрешләр кертергә вәкаләтле җирле үзидарә органы (җирле үзидарәнең вазыйфаи заты) тарафыннан карау өчен мәҗбүри була.

5. Әлеге статьяның 3 өлешендә каралган бәяләмәне карау нәтиҗәләре буенча фикер каршылыклары килеп чыккан очракта, мондый каршылыклар муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.»;

2) 15 статьяның 1 өлешендә:

а) 21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21) адресация объектларына адреслар бирү, адресларны үзгәртү, юкка чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге, муниципаль районның җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш) исемнәр, җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый исемнәрне үзгәртү, юкка чыгару, дәүләт адрес реестрында мәгълүмат урнаштыру;»;

б) 33 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«33) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтү, халык дружиналарының эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;»;

в) 35 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 16 статьяның 1 өлешендә:

а) 12 пунктта «медицина учреждениеләрендә» сүзләрен «медицина оешмаларында» сүзләренә, «Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең» сүзләрен «гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең» сүзләренә алмаштырырга;

б) 30 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 34 пункт өстәргә:

«34) адресация объектларына адреслар бирү, адресларны үзгәртү, юкка чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш) исемнәр, муниципаль районның авылара территориясе чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый

исемнәрне үзгәртү, юкка чыгару, дәүләт адрес реестрында мәгълүмат урнаштыру.»;

4) 17 статьяның 1 өлешендә:

а) 14 пунктта «медицина учреждениеләрендә» сүзләрен «медицина оешмаларында» сүзләренә, «Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең» сүзләрен «гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең» сүзләренә алмаштырырга;

б) 27 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27) адресация объектларына адреслар бирү, адресларны үзгәртү, юкка чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш) исемнәр, шәһәр округы чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый исемнәрне үзгәртү, юкка чыгару, дәүләт адрес реестрында мәгълүмат урнаштыру;»;

в) 37 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«37) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтү, халык дружиналарының эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;»;

г) 39 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 18 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктында «муниципаль заказны формалаштыру һәм урнаштыру» сүзләрен «муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуларны гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

6) 45 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«45 статья. **Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алулар**

1. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.»;



7) 55 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«55 статья. **Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары эшчәнлеген тикшереп тору һәм аңа күзәтчелек итү**

Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары эшчәнлеген тикшереп тору (күзәтчелек итү) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, аның 1 статьясындагы 2 пунктның «а» һәм «б» пунктчаларыннан, 3 пунктның «в» пунктчасыннан һәм 4 пунктның «б» һәм «в» пунктчаларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктның «а» пунктчасы, 3 пунктның «в» пунктчасы һәм 4 пунктның «б» пунктчасы 2014 елның 1 июленнән үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктның «б» пунктчасы һәм 4 пунктның «в» пунктчасы «Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашу мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 2 апрелендәге 70-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көннән үз көченә керә.

4. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (әлеге Закон редакциясендә) $6^1$ һәм $6^2$ статьялары нигезләмәләре түбәндәгеләргә карата кулланыла:

1) Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә – 2015 елның 1 гыйнварыннан;

2) муниципаль районнарга, шәһәр округларына (Казан шәһәре муниципаль берәмлегеннән тыш) – 2016 елның 1 гыйнварыннан;

3) башка муниципаль берәмлекләргә – 2017 елның 1 гыйнварыннан.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 10 мае
№ 30-ТРЗ

## 455. Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 апрелендә
кабул ителде

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 108-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына (алга таба – җирле үзидарә органнары) Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирә.

### 1 статья. Җирле үзидарә органнарына бирелә торган Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре

Җирле үзидарә органнарына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча түбәндәге Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре (алга таба – дәүләт вәкаләтләре) бирелә:

1) 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны (алга таба – авыл хуҗалыгы исәбен алу) үткәрү өчен җаваплы федераль башкарма хакимият органы соравы буенча авыл хуҗалыгы исәбенә алына торган объектлар турында үзләрендә булган белешмәләрне бирү;

2) авыл хуҗалыгы исәбенә алына торган объектлар турында белешмәләр җыючы затларның эшләве һәм авыл хуҗалыгы исәбен алу кәгазьләрен, авыл хуҗалыгы исәбен алуның башка документларын саклау өчен телефон элемтәсе һәм җиһазы булган биналар, шулай ук транспорт чаралары бирү;

3) тиешле административ-территориаль берәмлекләрдә яшәүче гражданнарны авыл хуҗалыгы исәбенә алына торган объектлар турында белешмәләр җыюга җәлеп итүгә булышу.

### 2 статья. Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган муниципаль берәмлекләрнең исемнәре

Татарстан Республикасында түбәндәге муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә:

Казан шәһәре, «Чаллы шәһәре», Әгерҗе муниципаль районы, Азнакай муниципаль районы, Аксубай муниципаль районы, Актаныш муниципаль районы, Алексеевск муниципаль районы, Әлки муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Апас муниципаль районы, Арча муниципаль районы, Әтнә муниципаль районы, Баулы муниципаль районы, Балтач муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль районы, Буа муниципаль районы, Югары Ослан муниципаль районы, Биектау муниципаль районы, Чүпрәле муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Кайбыч муниципаль районы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кукмара муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы, Мамадыш муниципаль районы, Менделеевск муниципаль районы, Минзәлә муниципаль районы, Мөслим муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Нурлат муниципаль районы, Питрәч муниципаль районы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Саба муниципаль районы, Сарман муниципаль районы, Спас муниципаль районы, Тәтеш муниципаль районы, Тукай муниципаль районы, Теләче муниципаль районы, Чирмешән муниципаль районы, Чистай муниципаль районы, Ютазы муниципаль районы.

### 3 статья. Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган чор

Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре 2016 елга бирелә.

4 статья. **Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү**

1. Җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруына бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла.

2. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга җирле бюджетларга субвенцияләр Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә.

3. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләрне исәпләү әлеге Законга кушымтада каралган 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр исәпләү методикасы нигезендә башкарыла.

4. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләр күләме Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

5 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырыла торган матди чаралар**

1. Җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен кирәк булган очракта, тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә түләүсез файдалануга тапшырыла.

2. Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген төзү, аны раслау һәм матди чаралар тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек өчен җаваплы итеп билгеләнә торган вәкаләтле органы (алга таба – махсус вәкаләтле орган) тәкъдимнәре нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан башкарыла.



6 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләр исәбеннән дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итәргә;

2) дәүләт вәкаләтләрен кирәкле матди чаралар белән тәэмин итәргә;

3) үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлек уставында каралган очракларда һәм тәртиптә өстәмә рәвештә үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан файдаланырга;

4) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмати, консультатив, оештыру ягыннан һәм методик ярдәм алырга.

2. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнары түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру эшчәнлеген башкарырга вәкаләтле җирле үзидарә органнарын һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларын билгеләргә;

2) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын, шулай ук дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының үз компетенцияләре чикләрендә кабул ителгән актларын үтәргә;

3) җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган матди чараларны һәм финанс чараларын исәпкә алуны, шулай ук алардан нәтиҗәле һәм максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

4) авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрү өчен җаваплы федераль башкарма хакимият органына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле документлар һәм мәгълүмат тапшырырга;

5) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга, бу максатларга бүлеп бирелгән матди чаралардан һәм финанс чараларыннан файдалануга бәйле кирәкле мәгълүмат һәм документлар тапшырырга;

6) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру һәм финанс чараларын тоту турында хисаплар тапшырырга;

7) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп торуда ярдәм итәргә.

7 статья. **Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Татарстан Республикасы Президенты җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын үз компетенциясе чикләрендә тикшереп тора.

2. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тапшырылган дәүләт вәкаләтләренең үтәлешенә бәйле мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнарыннан һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларыннан документлар һәм мәгълүмат соратып алырга;

2) үз компетенциясе чикләрендә җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруы мәсьәләләре буенча мәҗбүри үтәлергә тиешле норматив хокукый актлар чыгарырга һәм аларның үтәлешен тикшереп торырга;

3) җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруы мәсьәләләре буенча ачыкланган законнар бозуларны бетерү буенча язмача күрсәтмәләр бирергә;

4) Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган финанс чаралары максатчан билгеләнеше буенча тотылмаган очракта, аларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә кире кайтартырга.

3. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле матди чараларны һәм финанс чараларын җирле үзидарә органнарына тапшырырга;

2) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын, шулай ук шушы максатлар өчен бирелгән матди чаралардан һәм финанс чараларыннан файдалануын тикшереп торырга;



3) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмати, консультатив, оештыру ягыннан һәм методик ярдәм күрсәтергә.

8 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, шул исәптән финанс чараларын тоту турындагы хисапларны Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм рәвешләр буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына тапшыралар.

9 статья. **Тапшырылган дәүләт вәкаләтләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырылуын тикшереп тору**

1. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгеләр тарафыннан башкарыла:

1) җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру эшчәнлеген тикшереп торуны тәэмин итү өлешендә махсус вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәге юллар белән:

а) дәүләт вәкаләтләрен үтәү турында кирәкле документлар, хисаплар һәм мәгълүмат соратып алу;

б) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеген урынга барып тикшерү;

2) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан түбәндәге юллар белән:

а) дәүләт вәкаләтләрен үтәү турында кирәкле документлар, хисаплар һәм мәгълүмат соратып алу;

б) кирәк булганда, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча, шул исәптән алдан соратылган документларны, хисапларны һәм мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозу буенча ачыкланган фактларга бәйле рәвештә урынга барып тикшерү үткәрү;

в) закон бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча кирәкле чаралар күрү;

3) Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга бирелгән очракта, дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына бирелгән дәүләт мөлкәтен саклап калу һәм аннан тиешенчә файдалану өлешендә мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан түбәндәге юллар белән:

а) дәүләт вәкаләтләрен үтәү турында кирәкле документлар, хисаплар һәм мәгълүмат соратып алу;

б) кирәк булганда, дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, шул исәптән алдан соратылган документларны, хисапларны һәм мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук законнар бозу буенча ачыкланган фактларга бәйле рәвештә тикшерүләр үткәрү;

в) закон бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча кирәкле чаралар күрү.

10 статья. **Җирле үзидарә органнарының аларга бирелгән дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын туктату шартлары һәм тәртибе**

1. Җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруы Татарстан Республикасы законы белән түбәндәге очракларда туктатыла:

1) җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен җайга салу өлкәсендә законнар таләпләрен үтәмәгәндә яисә тиешенчә үтәмәгәндә;

2) җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары әлеге Законны бозуларны бетерү турында күрсәтмәләрне үтәмәгәндә;

3) җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра алмаслык итеп федераль законнар яисә Татарстан Республикасы законнары үзгәргәндә.

2. Җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын туктату, дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелеп, файдаланылмый калган финанс чараларын һәм матди чараларны кире кайтаруга китерә.

3. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча законнар таләпләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, махсус вәкаләтле орган күрсәтелгән закон бозулар ачыкланган көннән соң 10 көн эчендә җирле үзидарә органнарына аларны бетерү турында күрсәтмә җибәрә.

4. Ачыкланган закон бозуларны бетерү турында күрсәтмә җирле үзидарә органнарына кергән көннән соң 10 көннән дә



соңга калмыйча мәҗбүри каралырга тиеш. Күрсәтмәне карау нәтиҗәләре турында кичекмәстән язма рәвештә махсус вәкаләтле органга хәбәр ителә.

5. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очракларда махсус вәкаләтле орган җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын туктату турында тәкъдимне һәм Татарстан Республикасының тиешле законы проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каравына кертә.

11 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары әлеге Закон үз көченә кергән көннән соң ике ай эчендә аңа туры китерелергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 14 мае
№ 31-ТРЗ

«Муниципаль районнарның һәм
шәһәр округларының
җирле үзидарә органнарына
2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы
исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча
Татарстан Республикасы
дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

## 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр исәпләү методикасы

1. Әлеге Методика җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл

хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслауны тәэмин итү максатларында эшләнде.

2. Татарстан Республикасы бюджетыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен i-муниципаль районы (шәһәр округы) бюджетына бирелә торган субвенция күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Р_{общ} = З_{рпу} + З_{охр} + З_{тр} + З_{св},$$

монда:

$Р_{общ}$ – i-муниципаль районы (шәһәр округы) бюджетына бирелә торган субвенция күләме;

$З_{рпу}$ – i-муниципаль районында (шәһәр округында) исәпкә алу участокларын бирү чыгымнары күләме;

$З_{охр}$ – i-муниципаль районында (шәһәр округында), исәпкә алу участоклары урнашкан урыннар сакланмаган очракта, исәпкә алу участокларын саклау чыгымнары күләме;

$З_{тр}$ – i-муниципаль районында (шәһәр округында) авыл хуҗалыгы исәбенә алына торган объектлар турында белешмәләр җыючы затларны транспорт чаралары белән тәэмин итү чыгымнары күләме;

$З_{св}$ – i-муниципаль районында (шәһәр округында) авыл хуҗалыгы исәбенә алына торган объектлар турында белешмәләр җыючы затларны исәпкә алу участокларындагы телефон элемтәсе чаралары белән тәэмин итү чыгымнары күләме.

3. Исәпкә алу участокларын бирү чыгымнары күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$З_{рпу} = С_б \times П \times В_п \times К,$$

монда:

$С_б$ – бер исәпкә алу участогын урнаштыруга (эксплуатация чыгымнарын кертеп) тәүлегенә бер квадрат метр өчен i-муниципаль районында билгеләнгән аренда түләве күләме (сум);

П – бер исәпкә алу участогы мәйданын билгели торган норматив (квадрат метр);

$В_п$ – бер исәпкә алу участогын урнаштыру өчен урынны арендалау вакытын билгели торган норматив (тәүлек);

К – i-муниципаль районында (шәһәр округында) исәпкә алу участоклары саны (берәмлек).

4. Исәпкә алу участоклары урнашкан урыннар сакланмаган очракта, исәпкә алу участокларын саклау чыгымнары күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:



$$З_{охр} = С_{охр} \times В_{охр} \times К,$$

монда:

$С_{охр}$ – тәүлек буе эшләгәндә бер исәпкә алу участогын бер тәүлек саклауны тәэмин итү бәясен билгели торган норматив (сум);

$В_{охр}$ – бер исәпкә алу участогын тәүлек буе саклау режимындагы бер исәпкә алу участогын саклау вакытын билгели торган норматив (тәүлек);

К – i-муниципаль районында (шәһәр округында) исәпкә алу участоклары саны (берәмлек).

5. Авыл хуҗалыгы исәбенә алына торган объектлар турында белешмәләр җыючы затларны транспорт чаралары белән тәэмин итү чыгымнары күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$З_{тр} = С_{тр} \times К_{тр} \times В_{тр} \times К,$$

монда:

$С_{тр}$ – транспорт чарасыннан файдаланган өчен бер тәүлеккә аренда түләве күләмен билгели торган норматив (сум);

$К_{тр}$ – бер исәпкә алу участогы өчен i-муниципаль районында (шәһәр округында) j-төрдәге транспорт чараларының санын билгели торган норматив (берәмлек);

$В_{тр}$ – транспорт чарасын арендалау вакытын билгели торган норматив (тәүлек);

К – i-муниципаль районында (шәһәр округында) исәпкә алу участоклары саны (берәмлек).

6. Авыл хуҗалыгы исәбенә алына торган объектлар турында белешмәләр җыючы затларны исәпкә алу участокларындагы телефон элемтәсе чаралары белән тәэмин итү чыгымнары күләме телефон элемтәсенең гамәлдәге тарифлары нигезендә түбәндәге формулалар буенча исәпләнә:

$$З_{св} = З_{св1} + З_{св2},$$
$$З_{св1} = С_{асв} \times К_{тел} \times В \times К,$$

монда:

$З_{св1}$ – i-муниципаль районында (шәһәр округында) телефон элемтәсе чараларыннан файдаланган өчен абонент түләве күләме (сум);

$С_{асв}$ – бер телефоннан файдаланган өчен i-муниципаль районында (шәһәр округында) бер айга абонент түләве күләме (сум);

$К_{тел}$ – i-муниципаль районында (шәһәр округында) бер исәпкә алу участогына телефон номерлары санын билгели торган норматив (берәмлек);
В – исәпкә алу участогындагы телефон элемтә чараларыннан файдалану вакытын билгели торган норматив (тәүлек);
К – i-муниципаль районында (шәһәр округында) исәпкә алу участоклары саны (берәмлек);

$$З_{св2} = С_{мсв} \times К_{тел} \times Л_{мсв} \times В_{п} \times К,$$

монда:
$З_{св2}$ – i-муниципаль районында (шәһәр округында) шәһәрара элемтә хезмәте күрсәтү бәясе (сум);
$С_{мсв}$ – i-муниципаль районында (шәһәр округында) шәһәрара элемтә хезмәте күрсәтү тарифы (сум);
$К_{тел}$ – i-муниципаль районында (шәһәр округында) бер исәпкә алу участогына шәһәрара элемтә телефон номерлары санын билгели торган норматив (берәмлек);
$Л_{мсв}$ – бер исәпкә алу участогына бер тәүлеккә шәһәрара элемтә хезмәте күрсәтүдән файдалану лимитын билгели торган норматив (минут);
$В_{п}$ – бер исәпкә алу участогындагы шәһәрара элемтә чараларыннан файдалану вакытын билгели торган норматив (тәүлек);
К – i-муниципаль районында (шәһәр округында) исәпкә алу участоклары саны (берәмлек).

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 456. Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексының 21 статьясындагы 1 пунктының 5 пунктчасын (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш);



1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) дәүләт яисә муниципаль милектәге җирләрдән – тулысынча федераль бюджет акчалары, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары яисә җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган күчемсез мөлкәт объектын төзүгә дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт яисә муниципаль контракт төзелгән затларга күчемсез мөлкәт объектын төзү вакытына;».

**2 статья**

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясындагы тугызынчы абзацында (1999 елның 6 декабрендәге 2486 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I өлеш); 2005, № 4 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; 2012, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2014, № 1 – 2) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында» 2005 елның 21 июлендәге 94-ФЗ номерлы» сүзләрен «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 37 статьясындагы 2 өлешен (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1, № 9 (II өлеш); 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш);

2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән дәүләт заказы кысаларында товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.».

**4 статья**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 3 өлешендәге 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) дәүләт милкендәге җирләрдә урнашкан урманнарны саклау, яклау, торгызу чараларын гамәлгә ашыру федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары буйсынуындагы дәүләт бюджет һәм автономияле учреждениеләргә яисә урманнардан файдаланучы затларга йөкләнмәгән очракларда, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә урманнарны саклау, яклау, торгызу эшләрен сатып алуларны гамәлгә ашыру;»;

2) 8 статьяда «урманнарны саклауга, яклауга һәм торгызуга дәүләт заказын яисә муниципаль заказны бер үк вакытта урман утыртмаларын сату белән урнаштырганда» сүзләрен «урманнарны саклау, яклау, торгызу эшләрен сатып алулар дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырылганда» сүзләренә алмаштырырга.

**5 статья**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы



Җыелма басмасы, 2010, № 1 — 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 — 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 3 өлешендә «товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштырганда» сүзләрен «товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуларны гамәлгә ашырганда» сүзләренә алмаштырырга;

2) 22 статьяның 2 пунктында «социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәт күрсәтүләргә дәүләт заказын урнаштыру» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтүләрне сатып алуларны дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга.

**6 статья**

«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 8 — 9; 2012, № 1) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 17 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар китереп торуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру» сүзләрен «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 17 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктында «сатып алуга дәүләт заказы урнаштыру» сүзләрен «сатып алуларны гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга.

**7 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясындагы 3 өлешендә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011 № 10 (I өлеш); 2012, № 3) «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар китереп торуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру» сүзләрен «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны,

эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы» сүзләренә алмаштырырга.

**8 статья**

«2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программасын раслау турында» 2011 елның 22 апрелендәге 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кушымтасының 3 бүлегендәге 3.5 бүлекчәсенең 3.5.2 пунктындагы уникенче абзацында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2014, № 1 – 2) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында» 2005 елның 21 июлендәге 94-ФЗ номерлы» сүзләрен «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга.

**9 статья**

«Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» 2011 елның 1 августындагы 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 3 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 8 (I өлеш) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы» Федераль законда каралган тәртиптә янгыннан саклауның иҗтимагый берләшмәләреннән дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуларны гамәлгә ашыру;».

**10 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында» 2012 елның 14 июлендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 3 өлешендә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 7 (I өлеш) «дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру» сүзләрен «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы» сүзләренә алмаштырырга.



**11 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 14 мае
№ 32-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 457. Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) вазыйфаи бурычларны үтәгәндә расасына, милләтенә, теленә, дингә мөнәсәбәтенә һәм башка хәлләргә карамастан кеше һәм гражданның хокукларын, иреген һәм законлы мәнфәгатьләрен, шулай ук оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;»;

2) 15 статьяда:

а) 1 өлештә:

4 пунктта «медицина учреждениесе» сүзләрен «медицина оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

«10) законлы нигезләр булмыйча торып, аны чакыру комиссиясе бәяләмәсе нигезендә чакырылыш буенча хәрби хезмәт узмаган дип тану (контракт буенча хәрби хезмәт узган гражданнардан тыш).»;

б) 2 өлештә «ир белән хатынның балалары» сүзләрен «ир белән хатынның балалары һәм балаларның ире яисә хатыны» сүзләренә алмаштырырга;

3) түбәндәге эчтәлекле $17^1$ статья өстәргә:

«$17^1$ статья. **Муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә таләпләр**

1. Муниципаль хезмәткәр түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) вазыйфаи бурычларны намус белән, югары профессиональ дәрәҗәдә үтәргә;

2) барлык физик һәм юридик затларга һәм оешмаларга бертигез, гадел мөнәсәбәт тәэмин итәргә, нинди дә булса иҗтимагый яисә дини берләшмәләргә, һөнәри яисә социаль төркемнәргә, гражданнарга һәм оешмаларга өстенлек бирмәскә һәм мондый берләшмәләргә, төркемнәргә, оешмаларга һәм гражданнарга карата аерым мөнәсәбәттә булмаска;

3) вазыйфаи бурычларны намуслы үтәүгә каршылык тудыра торган нинди дә булса шәхси, мөлкәти (финанс) һәм башка мәнфәгатьләр йогынтысына бәйле гамәлләр кылмаска;

4) үз һөнәри хезмәт эшчәнлегенә сәяси партияләр, башка иҗтимагый һәм дини берләшмәләр һәм башка оешмалар карарларының тәэсир итү мөмкинлеген калдырмыйча, нейтральлек сакларга;

5) гражданнар белән аралашканда әдәпле булырга;

6) Россия Федерациясе халыкларының әхлакый гореф-гадәтләренә һәм традицияләренә карата ихтирамлы булырга;

7) төрле этник һәм социаль төркемнәрнең, шулай ук конфессияләрнең мәдәни һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алырга;

8) милләтара һәм конфессияара татулыкка ярдәм итәргә;

9) аның репутациясенә яисә муниципаль органның абруена зыян китерерлек конфликтлы вәзгыятьләргә юл куймаска.

2. Җитәкче булып торган муниципаль хезмәткәр сәяси партияләр, башка иҗтимагый һәм дини берләшмәләр эшчәнлегендә муниципаль хезмәткәрләрне мәҗбүри катнаштыру очракларына юл куймаска тиеш.»;

4) 19 статьяның 3 өлешендә:

а) 8 пунктта «хәрби бурычлылар» сүзләрен «запастагы гражданнар» сүзләренә алмаштырырга;



б) 9 пунктта «медицина учреждениесе» сүзләрен «медицина оешмасы» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 14 мае
№ 33-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 458. Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.3 һәм 8.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1–2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3 статья. **Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенә каршылык күрсәтү**

1. Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенә аларның карарларына йогынты ясау максатында катышкан, аларның законлы таләпләрен вазыйфаи затлар тарафыннан үтәмәгән, шулай ук Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенә бүтән рәвештә каршылык күрсәткән өчен —

ике меңнән алып өч мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

2. Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә мәгълүмат (документлар, материаллар, мөрәҗәгатьләргә җаваплар) бирүнең билгеләнгән срокларын вазыйфаи затлар тарафыннан үтәмәгән өчен —

бер меңнән алып ике мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.»;

2) 8.1 статьяның 6 өлешендә «Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенә кагылышлы)» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил (Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенә кагылышлы)» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 14 мае
№ 34-ТРЗ



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 459. Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле «б$^2$» һәм «б$^3$» пунктчалары өстәргә:

«б$^2$) депутатка карата Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу яисә аларның булуы, акча һәм башка кыйммәтләрне саклау, тиешле сайлауларда кандидат буларак теркәлгән чорда чит ил финанс инструментларын биләү һәм (яисә) алардан файдалану фактлары билгеле булу;

б$^3$) депутат, аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балалары тарафыннан Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу (аларның булуы), акча һәм башка кыйммәтләрне саклау, чит ил финанс инструментларын биләү һәм (яисә) алардан файдалану;»;

2) 10$^1$ статьяда:

а) 1 пунктта тиешле килештә «комиссия» сүзен тиешле килештә «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Депутатның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр әлеге Законның 1 — 2 нче кушымталары нигезендәге белешмәләр формалары буенча тапшырыла. Җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне,

акцияләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләрен, пайларын) сатып алуга кагылышлы һәр алыш-биреш буенча депутатның чыгымнары турында, шулай ук аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында, әгәр алыш-биреш суммасы депутатның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчыга кадәр соңгы өч елда гомуми кеременнән артса, һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган форма буенча тапшырыла.»;

в) 3 пунктның 3 пунктчасында «төп хезмәт (эш) урыны буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 4 пунктта «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

д) 6 пунктта «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

3) $10^2$ статьяда:

а) исемендә татарча текст үзгәрешсез кала;

б) 1 пунктта «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

в) 3 пунктта «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

г) 4 пунктта «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

4) $10^3$ статьяда:

а) 2 пунктта «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

б) 5 пунктта «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

в) 6 пунктның беренче абзацында «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

г) 7 пунктның 6 пунктчасында «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

д) 11 пунктта «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

е) 12 пунктның 3 пунктчасында «комиссиягә» сүзен «Комиссиягә» сүзенә алмаштырырга;

ж) 14 пунктта «комиссиянең» сүзен «Комиссиянең» сүзенә алмаштырырга;

з) 16 пунктта «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;



и) 18 пунктта «комиссиягә» сүзен «Комиссиягә» сүзенә алмаштырырга;

к) 19 пунктта «комиссиядә» сүзен «Комиссиядә» сүзенә алмаштырырга;

л) 20 пунктта «комиссия» сүзен «Комиссия» сүзенә алмаштырырга;

5) $10^4$ статьяда:

а) 1 пунктның 4 пунктчасында «төп хезмәт (эш) урыны буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 6 пунктта татарча текст үзгәрешсез кала;

6) 1 нче кушымтада татарча текст үзгәрешсез кала;

7) 2 нче кушымтада татарча текст үзгәрешсез кала;

8) 3 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяга түбәндәге эчтәлекле $7^1$ пункт өстәргә:

«$7^1$) аларга, шулай ук аларның хатыннарына (ирләренә) һәм балигъ булмаган балаларына карата Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу яисә аларның булуы, акча һәм башка кыйммәтләрне саклау, чит ил финанс инструментларын биләү һәм (яисә) алардан файдалану фактлары билгеле булуга;»;

2) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар өчен чикләүләр һәм тыюлар**

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга федераль законнар нигезендә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы

Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләр һәм тыюлар кагыла.»;

3) 20 статьяның 3 өлешендә «һәм 19 статьяның өченче өлешеннән» сүзләрен төшереп калдырырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 14 мае
№ 35-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 460. Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 пунктчасына «саклау» сүзеннән соң «, җирләрне мелиорацияләү» сүзләрен өстәргә;



2) 4 статьяның 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

3) 12 статьяда:
а) 2 пунктта:
1 пунктчада «, шул исәптән дәвалау-савыктыру урыннарының һәм курортларның» сүзләрен төшереп калдырырга;
5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5) аеруча кыйммәткә ия җирләр.»;
б) 4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;
в) 5 пунктта «, шулай ук дәвалау-савыктыру урыннарының һәм курортларның» сүзләрен төшереп калдырырга;
г) 6 пунктта беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Дәүләт табигать тыюлыкларына, милли паркларга, табигать паркларына һәм табигать ядкарьләренә тискәре антропоген йогынтыларны булдырмый калу өчен алар янындагы җир кишәрлекләрендә һәм су объектларында саклау зоналары төзелә.»;

4) 15 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Запас җирләрдән файдалану аларны башка категориягә күчергәннән соң, запас җирләр аучылык җирләре чикләренә кертелгән очраклардан һәм федераль законнарда каралган башка очраклардан тыш, рөхсәт ителә.»;

5) 21 статьяның 2 пунктындагы беренче абзацында беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Хезмәт буенча имана җирләре икътисадның аерым тармакларындагы оешмалар, шул исәптән транспорт, урман хуҗалыгы, урман сәнәгате, су, балык хуҗалыклары оешмалары, аучылык хуҗалыгы өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар, дәүләт табигать тыюлыклары һәм милли парклар белән идарә итүче федераль дәүләт бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренә түләүсез вакытлыча файдалануга бирелә.»;

6) 32 статьяның 2 пунктындагы 1 пунктчасында «крестьян (фермер) хуҗалыгы алып бару өчен» сүзләрен «крестьян (фермер) хуҗалыгы үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен» сүзләренә алмаштырырга;

7) 34 статьяда:
а) 1 пунктның 1 пунктчасында «крестьян (фермер) хуҗалыгы алып бару өчен» сүзләрен «крестьян (фермер)

хуҗалыгы үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктның 1 пунктчасында «крестьян (фермер) хуҗалыгы алып бару өчен» сүзләрен «крестьян (фермер) хуҗалыгы үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен» сүзләренә алмаштырырга;

8) 42 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

9) 48 статьяның 2 пунктындагы җиденче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 28 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 16 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 4);

2) «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 31 июлендәге 41-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 5 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш).

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 14 мае
№ 36-ТРЗ



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 461. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $13^1$ һәм $13^2$ пунктлар өстәргә:

«$13^1$) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәклеген ачыклау тәртибен билгеләү;

$13^2$) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр өчен «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм фонды турында» Федераль законның $20^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә ачылган махсус счетларга салынган акчалар исәбеннән түләү тәртибен билгеләү;»;

2) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле $6^1$ һәм $6^2$ өлешләр өстәргә:

«$6^1$. Капиталь ремонт фондларын исәпкә алу системасын алып бару буенча региональ оператор функцияләре региональ оператор белән төзелгән шартнамә нигезендә дәүләт бюджет яисә казна учреждениесе рәвешендә төзелгән бүтән юридик зат тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин. Бу чакта региональ оператор мондый юридик зат гамәлләре өчен үз гамәлләре өчен җаваплы булган кебек үк җаваплы була.

$6^2$. Региональ оператор Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында счетлар, махсус счетлардан тыш, ачарга хокуклы. Россия Федерациясе Торак кодексында каралган башка очракларда региональ оператор тарафыннан счетлар, махсус

счетлар ачу Россия Федерациясе Торак кодексының 176 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән таләпләргә туры килә торган һәм конкурс нәтиҗәләре буенча региональ оператор тарафыннан сайлап алына торган Россия кредит оешмаларында гамәлгә ашырыла. Мондый конкурс уздыру тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.»;

3) 6 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Региональ операторның күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны финанслауга ел саен тоту хокукы булган акчалар күләме (гомуми мөлкәтенә капиталь ремонт киләсе чорда ясалырга тиешле күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре тарафыннан булдырылган капиталь ремонт фондлары акчалары исәбеннән бирелә торган акчалар күләме) региональ операторга капиталь ремонт өчен узган елда кергән кертемнәр күләменә һәм (яисә) агымдагы елда капиталь ремонт өчен кертемнәрнең фаразланган күләменә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә. Күрсәтелгән өлешнең күләме региональ операторга капиталь ремонт өчен узган елда кергән кертемнәр күләменнән 92 процентны тәшкил итә. Региональ операторга капиталь ремонт өчен узган елда кергән кертемнәр күләменнән калган сигез проценты региональ операторга агымдагы елда кергән акчалар күләмендә исәпкә алынырга тиеш һәм киләсе елда капиталь ремонтны финанслау максатларында файдаланылырга мөмкин.»;

4) 7 статьяга түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Федераль башкарма хакимиятнең финанс-бюджет өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек вазыйфаларын башкаручы органы региональ операторның капиталь ремонтка дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм буларак бирелгән акчалардан, шулай ук региональ оператор счетында, счетларында капиталь ремонт фонды барлыкка китерә торган күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләреннән алынган акчалардан файдалануын Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тикшереп тора.»;

5) 10 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10 статья. **Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программа әзерләү һәм раслау тәртибе, мондый программаларга таләпләр, аларны әзерләү өчен кирәкле белешмәләрне җирле үзидарә органнары тарафыннан бирү тәртибе»;**

б) 4 өлешнең 5 пунктында «елы» сүзен «чоры» сүзенә алмаштырырга;



6) 11 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Капиталь ремонт буенча региональ программада беренче чиратта капиталь ремонт буенча региональ программаны раслау яисә актуальләштерү датасына мондый капиталь ремонт ясалмаган булса, беренче торак урынны хосусыйлаштыру датасына капиталь ремонт ясау таләп ителгән күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау күздә тотылырга тиеш.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә, бу Законның гамәлгә ашырыуын тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 14 мае
№ 37-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 462. Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендә:

а) кырык сигезенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) алтмыш икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«махсус саклау режимы — махсус сакланыла торган табигать территорияләре чикләрендә традицион хуҗалык итүдә куллануга, кереп йөрүгә, рекреациягә һәм эшчәнлекнең башка төрләренә карата чикләү яисә тыю чаралары системасы;»;

2) $135^7$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$135^7$ статья. **Җитештерү аучылык контроле**

1. Җитештерү аучылык контроле дигәндә аучылык хуҗалыгы килешүләре төзегән юридик затларның яисә индивидуаль эшкуарларның аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә таләпләрне бозуны кисәтү, ачыклау һәм бетерү буенча эшчәнлеге аңлашыла.

2. Җитештерү аучылык контроле федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

3) 142 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«142 статья. **Махсус сакланылучы табигать территорияләре категорияләре**

1. Махсус сакланылучы табигать территорияләре режимының үзенчәлекләрен исәпкә алып, күрсәтелгән территорияләрнең түбәндәге категорияләре билгеләнә:

1) дәүләт табигать тыюлыклары, шул исәптән биосфера тыюлыклары;

2) милли парклар;

3) табигать парклары;

4) дәүләт табигать заказниклары;

5) табигать һәйкәлләре;

6) дендрология парклары һәм ботаника бакчалары.

2. Махсус сакланылучы табигать территорияләре федераль, республика яисә җирле әһәмияткә ия булырга һәм тиешенчә федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары карамагында, ә федераль законнарда каралган очракларда шулай ук дәүләт фәнни оешмалары һәм югары белемнең дәүләт мәгариф оешмалары карамагында булырга мөмкин.

3. Дәүләт табигать тыюлыклары һәм милли парклар федераль әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләренә



кертелә. Дәүләт табигать заказниклары, табигать һәйкәлләре, дендрология парклары һәм ботаника бакчалары федераль әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләренә яисә республика әһәмиятендәге махсус сакланылучы табигать территорияләренә кертелергә мөмкин. Табигать парклары республика әһәмиятендәге махсус сакланылучы табигать территорияләренә кертелә.»;

4) 143 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 144 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

6) 146 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«146 статья. **Табигать парклары**

Табигать парклары республика әһәмиятендәге махсус сакланылучы табигать территорияләре булып тора, аларның чикләрендә экологик, мәдәни яисә рекреацион билгеләнештәге зоналар бүленә һәм шуңа бәйле рәвештә икътисадый һәм башка эшчәнлекне тыюлар һәм чикләүләр билгеләнә.»;

7) 147 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«147 статья. **Табигать паркларын төзү тәртибе**

Табигать паркларын төзү федераль законнарда каралган таләпләр нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән гамәлгә ашырыла.»;

8) 148 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

9) 149 статьяның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

10) 151 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«151 статья. **Республика әһәмиятендәге дәүләт табигать заказникларын төзү тәртибе**

1. Республика әһәмиятендәге дәүләт табигать заказникларын төзү федераль законнарда каралган таләпләр нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән гамәлгә ашырыла.

2. Республика әһәмиятендәге дәүләт табигать заказниклары шулай ук Татарстан Республикасы чикләрендә урнашкан федераль әһәмияттәге дәүләт табигать заказникларын үзгәртеп

кору юлы белән дә төзелергә мөмкин, ул Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы тәкъдиме буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештерелеп гамәлгә ашырыла.»;

11) 156 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«156 статья. **Дендрология парклары һәм ботаника бакчалары**

1. Дендрология парклары һәм ботаника бакчалары үсемлекләр дөньясын һәм аның төрлелеген саклау максатларында үсемлекләрнең махсус коллекцияләрен җыю өчен булдырылган махсус сакланылучы табигать территорияләре булып тора.

2. Республика әһәмиятендәге дендрология паркы һәм ботаника бакчасы турындагы нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

3. Федераль законнарда каралган очракларда дендрология паркы һәм ботаника бакчасы турындагы нигезләмә дәүләт фәнни оешмалары һәм югары белемнең дәүләт мәгариф оешмалары тарафыннан раслана.»;

12) 157 статьяның 3 өлешендә «дәүләт хакимиятенең әлеге учреждениеләрне төзү турында карар кабул иткән тиешле органнары раслый торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

13) 158 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

14) 159 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 28 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 1);

2) «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 6-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 9 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1).

**3 статья**



Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 14 мае
№ 38-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 463. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) 2 өлешнең 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) урман фонды җирләрендә урманнардан файдалануны, аларны саклауны (шул исәптән янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыруны һәм урман янгыннарын сүндерүне), яклауны (урманнарны яклауны районлаштырудан һәм дәүләт урман патологиясе мониторингыннан тыш), торгызуны (урман орлыкчылыгын районлаштырудан, урман үсемлекләре орлыкларының федераль фондын булдырудан һәм урманнарны торгызу буенча дәүләт мониторингыннан тыш) оештыру һәм күрсәтелгән җирләрдә урманнарны саклауны, яклауны, торгызуны (шул исәптән урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау һәм торгызу өчен билгеләнгән урман юлларын булдыруны һәм аларны эксплуатацияләүне) тәэмин итү;»;

б) 3 өлештә:

9 пунктта «шартнамәләрен» сүзеннән соң «(дәүләт табигать тыюлыклары һәм милли парклар чикләрендәге махсус саклanылучы табигать территорияләре җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләреннән тыш)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 13¹ — 13³ пунктлар өстәргә:

«13¹) гражданнар үз ихтыяҗлары өчен урман фонды җирләрендә, шулай ук Татарстан Республикасы милкендәге, шул исәптән республика әһәмиятендәге махсус саклanылучы табигать территорияләре җирләрендәге урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнарда әзерләгән агачны исәпкә алу;

13²) агачны һәм аның белән алыш-бирешләр ясауны исәпкә алуның бердәм дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасына мәгълүмат тапшыру;

13³) урман утыртмалары федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы билгеләгән критерийларга һәм таләпләргә туры килгән очракта, урманнарны торгызу өчен билгеләнгән җирләрне урман утыртмалары биләгән җирләргә кертү;»;

в) 4 өлешнең 3 пунктында «ставкалары» сүзеннән соң «(үз ихтыяҗлары өчен федераль әһәмияттәге махсус саклanылучы табигать территорияләре җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча түләү ставкаларыннан тыш)» сүзләрен өстәргә;

2) 2 бүлекнең исемендә **«үз ихтыяҗлары өчен»** сүзләреннән соң **«федераль әһәмияттәге махсус саклanылучы табигать территорияләре җирләренә кертелмәгән җирләрдә»** сүзләрен өстәргә;

3) 4 статьяда:

а) исемдә **«үз ихтыяҗлары өчен»** сүзләреннән соң **«федераль әһәмияттәге махсус саклanылучы табигать территорияләре җирләренә кертелмәгән җирләрдә»** сүзләрен өстәргә;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен федераль әһәмияттәге махсус саклanылучы табигать территорияләре җирләренә кертелмәгән җирләрдә агач әзерләү (алга таба — гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен агач әзерләү) өчен һәлак булган, зарарланган һәм картайган утыртмалар беренче чиратта бирелә.»;

4) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 статья. **Үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзү тәртибе**



1. Гражданнар үз ихтыяҗлары өчен агач әзерләүне урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре нигезендә башкаралар, алар аукцион үткәрмичә генә төзелә.

2. Үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзергә теләгән граждан вәкаләтле органга гариза белән мөрәҗәгать итә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның яшәү урыны буенча теркәлүе турында белешмәләр, шәхесен таныклый торган документ белешмәләре;

2) чикләрендә урман утыртмаларын сату-алу күздә тотыла торган урманчылык (урман паркы) исеме;

3) агачның таләп ителә торган күләме, аның сыйфат күрсәткечләре һәм аны әзерләү максаты.

3. Үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзү турында гариза язмача рәвештә яисә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен, шул исәптән «Интернет» челтәрен файдаланып электрон документ рәвешендә вәкаләтле органга турыдан-туры йә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәге аша бирелергә мөмкин.

4. Үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзү турында гариза алган көннән алып 15 көн эчендә вәкаләтле орган үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзү турында яисә мондый шартнамә төзүдән баш тарту хакында карар кабул итә. Карар кабул ителгән көннән алып 5 көннән дә соңга калмыйча вәкаләтле орган тапшырылуы турында хәбәр ителә торган заказ хаты белән карар хакында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә. Үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, хатта баш тартуның сәбәбе күрсәтелгән булырга тиеш.

5. Вәкаләтле орган үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзүдән баш тарту турында карарны түбәндәге очракларда кабул итә:

1) агачның гаризада күрсәтелгән күләме әлеге Законның 7 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән нормативлардан артып китсә;

2) граждан күрсәткән урманчылыкта (урман паркында) гаризада күрсәтелгән таләп ителә торган сыйфат күрсәткечләренә ия агач күләмнәрен әзерләү өчен җитәрлек урман утыртмалары булмаса;

3) әлеге Законның 7 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән сроклар үтәлмәсә.

6. Үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзү турында карар кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә вәкаләтле орган шундый шартнамә әзерли.

7. Чикләрендә гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен агач әзерләүгә яраклы урман утыртмалары урнашкан урманчылыклар (урман парклары) турында мәгълүмат вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.»;

5) 6 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 статья. **Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен агач әзерләүгә урман утыртмаларын тапшыру»;**

б) 1 өлештә «вәкаләтле белгече» сүзләреннән соң «үз ихтыяҗлары өчен» сүзләрен өстәргә;

в) 3 өлештә беренче җөмләдә «әмма» сүзеннән соң «үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын» сүзләрен, икенче җөмләдә «агач күләменең» сүзләреннән соң «үз ихтыяҗлары өчен» сүзләрен өстәргә;

г) 4 өлештә «таныклаганнан соң һәм» сүзләреннән соң «үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге статья белән үз көчләренә керүнең башка вакытлары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «б» пунктчасының дүртенче һәм бишенче абзацлары 2015 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 14 мае
№ 39-ТРЗ



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 464. «Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 11 һәм 16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» 2005 елның 29 декабрендәге 134-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 3; 2013, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. **Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару формированиеләрен матди-техник тәэмин итү**

1. Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару формированиеләрен матди-техник тәэмин итү, коткару җайланмалары, кораллары белән җиһазландыру аларны төзегән тиешле Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре органнары, оешмалары һәм иҗтимагый берләшмәләре раслаган җиһазландыру табельләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан төзелгән Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару профессиональ хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару профессиональ формированиеләрен матди-техник тәэмин итү, коткару җайланмалары, кораллары белән җиһазландыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару профессиональ хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару профессиональ формированиеләрен җиһазландыру табельләре нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2) 16 статьяда:

а) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Хезмәт шартнамәсе (контракты) белән йөкләнгән бурычларын үтәгәндә һәлак булган яисә хезмәт шартнамәсе (контракты) белән йөкләнгән бурычларын үтәгән чорда һәм шуңа бәйле рәвештә имгәнү (яралану, травма, контузия алу), авырып китү аркасында вафат булган Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару профессиональ хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару профессиональ формированиеләре коткаручыларының мәетләрен күчерү өчен әзерләү, күчерү, җирләүгә бәйле барлык чыгымнар, шулай ук кабер ташлары ясау һәм куюга бәйле чыгымнар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары билгеләгән тәртип һәм нормалар нигезендә Татарстан Республикасы һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары бюджетлары акчалары исәбеннән тотыла.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 8 өлеш өстәргә:

«8. Әлеге статьяның 2 һәм 5 өлешләрендә каралган чыгымнарны финанслау әлеге Законның 10 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 14 мае
№ 40-ТРЗ



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 465. Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 маенда
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6; 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) 2 өлештә «тавыш бирү көненә» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 16 статьяда:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) авыр һәм (яисә) аеруча авыр җинаятьләр кылган өчен хөкем ителүчеләр һәм сайлауларда тавыш бирү көненә күрсәтелгән җинаятьләр өчен хөкем ителүе юкка чыгарылмаган һәм кире алынмаган затлар;»;

түбәндәге эчтәлекле $1^1$ һәм $1^2$ пунктлар өстәргә:

«$1^1$) хөкем ителүе юкка чыгарылган яисә кире алынган авыр җинаятьләр кылган өчен ирегеннән мәхрүм ителгән затлар — хөкем ителүе юкка чыгарылган һәм кире алынган көннән алып ун ел үткәнчегә кадәр;

$1^2$) хөкем ителүе юкка чыгарылган яисә кире алынган аеруча авыр җинаятьләр кылган өчен ирегеннән мәхрүм ителгән затлар — хөкем ителүе юкка чыгарылган яисә кире алынган көннән алып унбиш ел үткәнчегә кадәр;»;

2 пунктка «, әгәр мондый затларга карата әлеге өлешнең $1^1$ һәм $1^2$ пунктларындагы гамәлләр кагылмаса» сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ — $6^3$ өлешләр өстәргә:

«$6^1$. Әгәр әлеге статьяның 6 өлешендәге $1^1$ һәм $1^2$ пунктларында каралган пассив сайлау хокукын чикләүләрнең гамәлдә булу срогы сайлауларда тавыш бирү көненә кадәр сайлау кампаниясе чорында чыкса, пассив сайлау хокукы чикләнгән граждан

әлеге сайлауларда законда билгеләнгән тәртиптә кандидат булып күрсәтелергә хокуклы.

6². Әгәр гражданның хөкем ителүенә китергән гамәл яңа җинаять законы нигезендә авыр яисә аеруча авыр җинаять дип танылмаса, әлеге статьяның 6 өлешендәге 1, 1¹ һәм 1² пунктларында каралган пассив сайлау хокукы чикләүләре гамәле әлеге җинаять законы үз көченә кергән көннән туктатыла.

6³. Әгәр гражданның хөкем ителүенә китергән гамәл яңа җинаять законы нигезендә аеруча авыр җинаять дип танылса яисә гражданның хөкем ителүенә китергән аеруча авыр җинаять яңа җинаять законы нигезендә авыр җинаять дип танылса, әлеге статьяның 6 өлешендәге 1¹ һәм 1² пунктларында каралган пассив сайлау хокукы чикләүләре хөкем ителү юкка чыгарылган яисә кире алынган көннән алып ун ел тәмамланганчыга кадәр гамәлдә була.»;

2) 11 статьяда:

а) 1 өлешнең икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Әлеге сайлау комиссияләрен төзү шулай ук башка сәяси партияләрнең һәм бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең тәкъдимнәренә нигезләнеп гамәлгә ашырыла.»;

б) 4¹ өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

3) 12 статьяның 7 өлешендәге 2 пунктында «, шулай ук әлеге Кодексның 97¹ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 13 статьяның 8 өлешендәге 2 пунктында «, шулай ук әлеге Кодексның 97¹ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 15 статьяның 7 өлешендәге 2 пунктында «, шулай ук әлеге Кодексның 97¹ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

6) 16 статьяда:

а) 4 өлешнең 2 пунктында «, шулай ук әлеге Кодексның 97¹ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләрдән» сүзләрен төшереп калдырырга

б) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:



«6. Әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә төзелгән участок комиссиясенең вәкаләтләр чоры биш ел тәшкил итә. Участок комиссиясенең вәкаләтләре, сайлау участоклары исемлеген төгәлләштерүгә бәйле рәвештә сайлау участогы бетерелгән очракта, территория комиссиясе карары белән вакытыннан алда туктатыла. Әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә төзелгән участок комиссиясенең вәкаләтләр чоры шул комиссия катнаша торган сайлау кампаниясе чорында тәмамланса, аның вәкаләтләре чоры бу сайлау кампаниясе тәмамланганчыга кадәр озайтыла. Әлеге статьяның 6¹ өлеше нигезендә төзелгән участок комиссиясенең вәкаләтләр чоры, аны төзегән комиссия тарафыннан билгеләнә, ләкин сайлаулар нәтиҗәләрен рәсми бастырып чыгарган көннән ун көннән дә иртәрәк булмаган вакытта бетә алмый, монда югарырак комиссиягә тавыш бирү һәм (яисә) тавышларны санау тәртибе бозылу аркасында әлеге комиссия гамәленә (гамәл кылмавына) шикаятьләр (гаризалар) алынмау йә әлеге фактлар буенча суд тикшерүе алып барылмау шарт. Тиешле сайлау участогында тавыш бирү йомгакларына шикаять бирелгән очракта, мондый участок комиссиясенең вәкаләтләре югарырак комиссия карар кабул иткән көннән йә шикаять (гариза) буенча суд карары үз көченә кергән көннән туктатыла.»;

в) 7 өлештә:

6 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

7 пунктка «, шулай ук вакытыннан алда тавыш бирү» сүзләрен өстәргә;

7) 18 статьяның 19 өлешендәге 4 пунктында «бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларыннан,» сүзләрен төшереп калдырырга;

8) 20 статьяда:

а) 3 өлешнең 1 пунктында «бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 4 өлешнең беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Даими нигездә эш итүче сайлау комиссиясенең сайланган кандидатлар тарафыннан, кандидатлар исемлекләре депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән сайлау берләшмәләре тарафыннан билгеләнеп куелган киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларының вәкаләтләре чоры шул ук органга яисә шул ук вазыйфага киләсе сайлауларда кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен теркәү тәмамланганчыга дәвам итә.»;

в) 9 өлештә «һәм әлеге Кодексның 97¹ статьясы нигезендә кандидатлар исемлекләренә депутат мандатлары тапшырылган сәяси партияләрнең» сүзләрен төшереп калдырырга;

9) 21 статьяда:

а) 1 өлешнең беренче җөмләсендә «бүтән сайлау участокларында тавыш бирү таныклыклары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 өлештә «Тавыш бирү көнендә» сүзләреннән соң «, шулай ук вакытыннан алда тавыш бирү көннәрендә» сүзләрен өстәргә;

в) 5 өлештә «санаганда» сүзеннән соң «вакытыннан алда тавыш бирү уздырганда» сүзләрен өстәргә;

10) 22 статьяда:

а) 4 өлештә «күрсәтелгән» сүзенә кадәр «алдан тавыш бирү чорына йә» сүзләрен өстәргә;

б) 6 өлештә:

1 пунктта «бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын бирү реестры,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктта «тавыш бирү көнендә» сүзләреннән соң «, шулай ук вакытыннан алда тавыш бирү көннәрендә» сүзләрен өстәргә;

11) 23 статьяның 4 пунктында «тавыш бирү көнендә» сүзләреннән соң «, вакытыннан алда тавыш бирү көннәрендә» сүзләрен өстәргә;

12) 29 статьяның 11 өлешендә:

беренче җөмләдә «, шулай ук сайлаучыга бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы бирелгән очракта» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче җөмләдә «, ә бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы бирелсә, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгын биргән комиссия әгъзасы имзасы белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

13) 31 статьяның 2 өлешендә «сәяси партияләр исемлеге» сүзләрен «сәяси партияләр, сәяси партияләрнең региональ бүлекләре һәм башка структур бүлекчәләре исемлеге» сүзләренә алмаштырырга;

14) 33 статьяның 2 өлешендә «съезд (конференция, җыелыш)» сүзләрен «съезд (конференция, гомуми җыелыш, җыелыш)» сүзләренә алмаштырырга;

15) 36 статьяның 3 өлешендәге 1 пунктында «съезд (конференция, җыелыш)» сүзләрен «съезд (конференция, гомуми җыелыш, җыелыш)» сүзләренә алмаштырырга;



16) 37 статьяның 3 өлешендә:

беренче абзацта «сәяси партия съезды (конференциясе, җыелышы),» сүзләрен «сәяси партия съезды (аның региональ бүлегенең конференциясе яисә гомуми җыелышы, сәяси партиянең башка структур бүлекчәсенең гомуми җыелышы, ә «Сәяси партияләр турында» Федераль законда каралган очракларда сәяси партиянең тиешле органы, аның региональ бүлеге яисә башка структур бүлекчәсе)» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «съезд (конференция, җыелыш)» сүзләрен «съезд (конференция, гомуми җыелыш, җыелыш)» сүзләренә алмаштырырга;

17) 38 статьяның 2 өлешендә «сәяси партиянең кимендә ун әгъзасы» сүзләреннән соң «(Татарстан Республикасында сәяси партиянең региональ бүлеге булган очракта сәяси партиянең әлеге ун әгъзасы шушы региональ бүлектә торырга тиеш)» сүзләрен өстәргә;

18) 39 статьяда:

а) 1 өлештә:

1 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы һәм урыны, яшәү урынының адресы, паспортының яисә гражданның паспортын алмаштыручы документның сериясе, номеры һәм бирү датасы, паспортын яисә гражданның паспортын алмаштыручы документны биргән органның исеме яисә коды, салым түләүченең идентификация номеры (булган очракта), гражданлыгы, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманы күрсәтеп, һөнәри белем турында белешмәләр (булган очракта), аны тәмамлау елы һәм белем һәм квалификация турындагы документның реквизитлары, төп эш яисә хезмәт итү урыны, биләгән вазыйфасы, (төп эш яисә хезмәт итү урыны булмаган очракта — шөгыльләренең төре);

1 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әгәр кандидат элек хөкем ителгән булса яисә аның хөкем ителүе гамәлдә булса, — кандидатның хөкем ителүе турында белешмәләр, әгәр хөкем ителүе юкка чыгарылган яисә кире алынган булса, — шулай ук хөкем ителүне юкка чыгару яисә кире алу датасы турында белешмәләр;»;

түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$) паспортының (паспортның Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән аерым битләренең) яисә гражданның паспортын алмаштыручы документының күчермәсе;»;

б) $1^1$ өлештә «кандидат сайлау комиссиясенә шулай ук» сүзләрен «кандидат әлеге статьяның 1 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган гариза белән бергә сайлау комиссиясенә шулай ук» сүзләренә алмаштырырга;

в) $1^3$ өлештә «үзенең теркәлү вакытына» сүзләрен «кандидатны теркәү өчен кирәкле документлар бирү вакытына» сүзләренә алмаштырырга;

г) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Кандидат гаризада кайсы сәяси партиядән булуын йә тавыш бирү көненә кадәр бер елдан да соңга калмыйча законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән бер генә иҗтимагый берләшмәдән булуын һәм үзенең шушы сәяси партиядәге, шушы иҗтимагый берләшмәдәге статусын күрсәтергә хокуклы, гариза белән бергә әлеге белешмәләрне раслаучы һәм сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең вәкаләтле заты йә сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең тиешле структур бүлекчәсенең вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган документның тапшырылуы шарт.»;

д) 5 өлешнең икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Паспорт яисә гражданның паспортын алмаштыручы документ кандидат тарафыннан әлеге статьяның 3 өлеше нигезендә сайлау комиссиясенә документларны шәхсән тапшырганда бирелә, паспортның яисә гражданның паспортын алмаштыручы документның күчермәсе сайлау комиссиясендә кандидат үзе булганда ясала һәм гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларны кабул итеп алган зат имзасы белән таныклана.»;

19) 40 статьяда:

а) 1 өлештә «басма» сүзен «кәгазь чыганакта» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә:

1 пунктның икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Кандидат гаризада кайсы сәяси партиядән булуын йә тавыш бирү көненә кадәр бер елдан да соңга калмыйча законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән бер генә иҗтимагый берләшмәдән булуын һәм үзенең шушы сәяси партиядәге, шушы иҗтимагый берләшмәдәге статусын күрсәтергә хокуклы, гариза белән бергә әлеге белешмәләрне раслаучы һәм сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең вәкаләтле заты йә сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең тиешле структур бүлекчәсенең вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган документның тапшырылуы шарт.»;

2 пунктта «кандидатның шәхесен таныклаучы документның (паспортының яисә гражданның паспортын алмаштыручы документның) күчермәсен» сүзләрен «паспортның (паспортның Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан



билгеләнгән аерым битләренең) яисә гражданның паспортын алмаштыручы документның күчермәсе» сүзләренә алмаштырырга;

в) $3^2$ өлештә «кандидат сайлау комиссиясенә шулай ук» сүзләрен «39 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында каралган гариза белән бергә сайлау комиссиясенә шулай ук» сүзләренә алмаштырырга;

г) $3^3$ өлештә «үзенең теркәлү вакытына» сүзләрен «кандидатлар исемлеген теркәү өчен кирәкле документларны тапшыру вакытына» сүзләренә алмаштырырга;

д) $4^1$ өлештә беренче җөмләне төшереп калдырырга;

е) түбәндәге эчтәлекле $5^1$ өлеш өстәргә:

«$5^1$. Әлеге Кодексның 39 статьясындагы 1 өлешнең 1 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында, 3 пунктында, 2 өлешендә (Дәүләт Советына сайлаулар уздырганда – шулай ук $1^1$ өлешендә) каралган документларның булмавы сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе тарафыннан әлеге кандидатны кандидатлар исемлегеннән аны таныклаганчы төшереп калдыру өчен нигез булып тора.»;

20) 41 статьяда:

а) 1 өлештә:

2 пунктта «2 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән» сүзләрен «$1^1$, 2 һәм 3 пунктларда күрсәтелгән» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «съездының (конференциясенең, җыелышының)» сүзләрен «съездының (конференциясенең, гомуми җыелышының, җыелышының)» сүзләренә алмаштырырга;

б) $1^1$ өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$1^1$. Сайлау берләшмәсе тарафыннан күпмандатлы сайлау округы буенча берничә кандидат күрсәтелгән очракта, шулай ук, әгәр сайлау комиссиясенә берничә округ сайлау комиссиясенең вәкаләтләре йөкләнгән һәм сайлау берләшмәсе тарафыннан кандидатлар берничә бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округлары буенча күрсәтелгән булса, кандидатларны теркәүче сайлау комиссиясенә әлеге статьяның 1 өлешендәге 5 һәм 6 пунктларында каралган документларны сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле йә әлеге документларны шушы сайлау берләшмәсе тарафыннан күрсәтелгән беренче булып тапшырган кандидат тапшырырга мөмкин. Мондый очракларда шушы сайлау берләшмәсе тарафыннан күрсәтелгән бүтән кандидатлар әлеге статьяның 1 өлешендәге 5 һәм 6 пунктларында каралган документларны шул ук сайлау комиссиясенә тапшырмаска да мөмкин.»;

в) $1^2$ өлештә «кандидат сайлау комиссиясенә шулай ук» сүзләрен «39 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында каралган гариза белән бергә сайлау комиссиясенә шулай ук» сүзләренә алмаштырырга;

г) 1[3] өлештә «үзенең теркәлү вакытына» сүзләрен «кандидатны теркәү өчен кирәкле документларны тапшыру вакытына» сүзләренә алмаштырырга;

д) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Кандидат гаризада кайсы сәяси партиядән булуын йә тавыш бирү көненә кадәр бер елдан да соңга калмыйча законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән бер генә иҗтимагый берләшмәдән булуын һәм үзенең шушы сәяси партиядәге, шушы иҗтимагый берләшмәдәге статусын күрсәтергә хокуклы, гариза белән бергә әлеге белешмәләрне раслаучы һәм сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең вәкаләтле заты йә сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең тиешле структур бүлекчәсенең вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган документның тапшырылуы шарт.»;

21) 42 статьяда:

а) 1 өлешнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) сәяси партия съездының (аның региональ бүлекчәсе конференциясенең яисә гомуми җыелышының, сәяси партиянең башка структур бүлекчәсенең гомуми җыелышының, ә «Сәяси партияләр турында» Федераль законда каралган очракларда, сәяси партиянең тиешле органының, аның региональ бүлегенең яисә башка структур бүлекчәсенең), башка иҗтимагый берләшмә съездының (конференциясенең, җыелышының), аның региональ яисә җирле бүлегенең бердәй сайлау округы буенча кандидат күрсәтү турында карары;»;

б) 2 өлешнең 1 пунктындагы икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Кандидат гаризада кайсы сәяси партиядән булуын йә тавыш бирү көненә кадәр бер елдан да соңга калмыйча законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән бер генә иҗтимагый берләшмәдән булуын һәм үзенең шушы сәяси партиядәге, шушы иҗтимагый берләшмәдәге статусын күрсәтергә хокуклы, гариза белән бергә әлеге белешмәләрне раслаучы һәм сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең вәкаләтле заты йә сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый берләшмәнең тиешле структур бүлекчәсенең вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган документның тапшырылуы шарт.»;

в) 2[1] өлештә «кандидат сайлау комиссиясенә шулай ук» сүзләрен «39 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында каралган гариза белән бергә сайлау комиссиясенә шулай ук» сүзләренә алмаштырырга;

г) 2[2] өлештә «үзенең теркәлү вакытына» сүзләрен «кандидатны теркәү өчен кирәкле документларны тапшыру вакытына» сүзләренә алмаштырырга;



22) түбәндәге эчтәлекле 42[1] статья өстәргә:

«42[1] статья. **Дәүләт Советы, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлауларда кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен күрсәтүне хуплау**

1. Дәүләт Советына, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарына депутатларны сайлауларда кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү өчен кирәкле шарт – сайлаучыларның кандидатны, кандидатлар исемлеген күрсәтүне хуплавы, ул исә әлеге статьяда күрсәтелгән сайлаулар нәтиҗәләре буенча билгеләнә йә сайлаучыларның кандидатны, кандидатлар исемлеген хуплап җыелган кирәкле сандагы имзалары белән раслана.

2. Сәяси партия тарафыннан күрсәтелгән кандидатларның федераль исемлеге Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын соңгы сайлаулар нәтиҗәләре буенча депутат мандатлары бүлешүгә кертелгән булса яисә федераль сайлау округы буенча тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның кимендә 3 процент тавышын җыйган булса, Дәүләт Советына, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарына депутатларны сайлауларда сәяси партия, аның региональ бүлекчәсе яисә башка структур бүлекчә тарафыннан (региональ бүлек яисә башка структур бүлекчә тарафыннан кандидатлар исемлеге күрсәтү сәяси партия уставында каралган булса) бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округы буенча кандидатны, кандидатлар исемлеген күрсәтү (әлеге статьяда алга таба – сәяси партия тарафыннан күрсәтү) сайлаучылар тарафыннан хупланган дип санала, һәм сайлаучыларның имзаларын җыю таләп ителми.

3. Сәяси партия тарафыннан күрсәтелгән кандидатлар исемлеге Дәүләт Советы депутатларын соңгы сайлаулар нәтиҗәләре буенча депутат мандатлары бүлешүгә кертелгән булса яисә бердәм сайлау округы буенча тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның кимендә 3 процент тавышын җыйган булса, Дәүләт Советына, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарына депутатлар сайлауларда әлеге статьядагы 2 өлешнең гамәлдә булуы кагылмый торган сәяси партия тарафыннан бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округы буенча кандидатны, кандидатлар исемлеген күрсәтү сайлаучылар тарафыннан хупланган дип санала, һәм тиешле сайлауларда сайлаучыларның имзаларын җыю таләп ителми.

4. Дәүләт Советына депутатлар сайлауларда әлеге статьядагы 2 һәм 3 өлешләрнең гамәлдә булуы кагылмый торган сәяси партия тарафыннан бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округы буенча кандидатны, кандидатлар исемлеген күрсәтү түбәндәге

очракларның теләсә кайсында сайлаучылар тарафыннан хупланган дип санала, һәм күрсәтелгән сайлауларда сайлаучыларның имзаларын җыю таләп ителми:

а) сәяси партия тарафыннан күрсәтелгән кандидатлар исемлеге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнарына соңгы сайлаулар нәтиҗәләре буенча кимендә аларның берсендә депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән булса;

б) сәяси партия тарафыннан күрсәтелгән кандидатлар исемлеген хуплап муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарына соңгы сайлауларда Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән сайлаучылар саныннан кимендә барлыгы 0,5 проценты тавыш биргән булса.

5. Муниципаль берәмлекнең шушы вәкиллекле органына соңгы сайлаулар нәтиҗәләре буенча әлеге сәяси партия тарафыннан күрсәтелгән бер генә депутат сайланган булса да (шул исәптән кандидатлар исемлеге составында), муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына депутатлар сайлауларда әлеге статьяның 2 һәм 3 өлешләренең гамәлдә булуы кагылмый торган сәяси партия тарафыннан бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округы буенча кандидатны, кандидатлар исемлеген күрсәтү сайлаучылар тарафыннан хупланган дип санала, һәм тиешле сайлауларда сайлаучыларның имзаларын җыю таләп ителми.

6. Сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (публикацияләнгән) көнгә бу сәяси партия тарафыннан бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округы буенча яисә кандидатлар исемлеге составында күрсәтелгән һәм соңгы сайлауларда шушы муниципаль район составына керә торган кимендә бер җирлекнең вәкиллекле органы депутаты булып сайланган кандидат бу җирлекнең вәкиллекле органы составыннан әлеге муниципаль районның вәкиллекле органы депутаты итеп сайланса, муниципаль район составына керә торган җирлекнең вәкиллекле органына депутатлар сайлауларда әлеге статьяның 2, 3 һәм 5 өлешләренең гамәлдә булуы кагылмый торган сәяси партия тарафыннан бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округы буенча кандидат, кандидатлар исемлеген күрсәтү сайлаучылар тарафыннан хупланган дип санала, һәм күрсәтелгән сайлауларда сайлаучыларның имзаларын җыю таләп ителми.

7. Дәүләт Советы депутатларын, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын сайлауларда әлеге статьяның 2 – 6 өлешләренең гамәлдә булуы кагылмый торган сәяси партия тарафыннан бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округы буенча, кандидат, кандидатлар исемлеген күрсәтүне хуплап, кандидатның үз-үзен күрсәтүен хуплап, әлеге Кодексның 43 һәм



44 статьяларында билгеләнгән күләмдә сайлаучылар имзалары җыелырга тиеш.

8. «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә әлеге статьядагы 2 өлешнең гамәлдә булуы кагыла торган сәяси партияләр исемлеге Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан төзелә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә аның сайтында урнаштырыла һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар нәтиҗәләре буенча яңартыла.

9. Әлеге статьядагы 3 – 6 өлешләрнең гамәлдә булуы кагыла торган сәяси партияләр исемлекләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан төзелә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә аның сайтында урнаштырыла һәм Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар һәм муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлаулар, Татарстан Республикасында җирлекләрнең вәкиллекле органнары составыннан муниципаль районнарның вәкиллекле органнары депутатларын сайлау нәтиҗәләре буенча яңартыла.»;

23) 43 статьяда:

а) статьяның исемендә «, кандидатлар исемлекләрен» сүзләрен өстәргә;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Кандидатлар, кандидатлар исемлеген күрсәтүне хуплап, сайлаучылар имзалары җыелырга мөмкин.»;

в) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирле үзидарәнең вазыйфаи затын сайлауларда сәяси партия, аның региональ бүлекчәсе яисә башка структур бүлекчәсе тарафыннан (әгәр кандидатларны региональ яисә башка структур бүлекчә тарафыннан күрсәтү сәяси партия уставында каралган булса) күрсәтелгән кандидатны теркәү федераль законда билгеләнгән тәртиптә сәяси партия, аның региональ бүлекчәсе яисә башка структур бүлекчәсе тарафыннан кабул ителгән карар нигезендә сайлаучылар имзаларын җыймыйча гына гамәлгә ашырыла.

г) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Бердәм сайлау округы буенча күрсәтелгән кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен теркәү өчен кирәкле имзалар саны сайлау округы территориясендә теркәлгән сайлаучыларның гомуми саныннан 0,5 процент тәшкил итә, ә бермандатлы сайлау округлары буенча күрсәтелгән кандидатларны теркәү өчен бермандатлы сайлау округлары схемасында күрсәтелгән тиешле

сайлау округы территориясендә теркәлгән сайлаучылар санының 0,5 процентын тәшкил итә, әмма федераль законда каралган очраклардан һәм әлеге статьяның 4[1] статьясында каралган очраклардан тыш, 10 имзадан да азрак булмаска тиеш.»;

д) түбәндәге эчтәлекле 4[1] өлеш өстәргә:

«4[1]. Дәүләт Советы депутатларын сайлауларда бермандатлы сайлау округы буенча күрсәтелгән кандидатны теркәү өчен кирәкле имзалар саны бермандатлы сайлау округлары схемасында күрсәтелгән тиешле сайлау округы территориясендә теркәлгән сайлаучылар санының 3 процентын тәшкил итә, ләкин ул 60 имзадан да ким була алмый.»;

е) 5 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

24) 44 статьяда:

а) статьяның исемендә «кандидатны» сүзеннән соң «кандидатлар исемлеген» сүзләрен өстәргә;

б) 1 өлешнең өченче җөмләсен төшереп калдырырга;

в) 2 өлештә «кандидат» сүзеннән соң «, сайлау берләшмәсе» сүзләрен, «кандидатның» сүзеннән соң «, сайлау берләшмәсенең» сүзләрен өстәргә;

г) 3 өлештә «, сайлау берләшмәсе» сүзләрен өстәргә;

д) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Имзалар бары тик кандидат, кандидатлар исемлеге күрсәтелгән шул сайлау округында актив сайлау хокукына ия сайлаучылар арасында гына җыелырга мөмкин. Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, милек рәвешләренә карамастан оешмаларның, учреждениеләрнең идарә органнарының, сайлау комиссияләренең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының имзалар җыюда катнашуы, шулай ук имзалар җыю барышында сайлаучыларны мәҗбүр итү һәм имза куйган өчен аларны бүләкләү рөхсәт ителми. Эш урыннарында, хезмәт хакы, пенсияләр, пособиеләр, стипендияләр, башка социаль түләүләрне бирү барышында һәм урыннарында, шулай ук хәйрия ярдәме күрсәткәндә имзалар җыю тыела. Әлеге өлеш нигезләмәләрен бозып җыелган имзалар гамәлгә яраксыз булалар.»;

е) 7 өлешнең беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Имзалар кәгазендә белешмәләре күрсәтелә торган кандидат элек хөкем ителгән булса яисә хөкем ителүе гамәлдә булса, өстәмә рәвештә һәр имза кәгазендә кандидатның хөкем ителгәнлеге турында белешмә күрсәтелә.»;

ж) 8 өлештә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда» сүзләрен «Дәүләт Советы депутатларын сайлауларда» сүзләренә алмаштырырга;



з) 9 өлештә «өстәмә рәвештә туган көнен» сүзләрен «өстәмә рәвештә туган числосын» сүзләренә алмаштырырга, «кандидатны» сүзеннән соң «, кандидатлар исемлеген» сүзләрен, «төрле кандидатлар» сүзләреннән соң «, кандидатлар исемлекләре» сүзләрен, «бер үк кандидатны» сүзләреннән соң «, кандидатлар исемлеген» сүзләрен өстәргә;

и) 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Кандидатлар исемлеген күрсәтүне хуплап, сайлаучылар имзалары белән тутырылган һәр имзалар кәгазе сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле тарафыннан таныкланырга тиеш. Кандидатны күрсәтүне (үз-үзен күрсәтүне) хуплап, сайлаучылар имзалары белән тутырылган һәр имзалар кәгазе кандидат тарафыннан таныкланырга тиеш. Имзалар кәгазен таныклаганда сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле, кандидат фамилиясе, исеме һәм атасының исеме янына кулдан имзасын куя һәм аны кую датасын күрсәтә.»;

к) 12 өлештә «кандидатны» сүзеннән соң «, кандидатлар исемлеген» сүзләрен өстәргә;

л) 13 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Сайлаучылар имзаларын җыю тәмамланганнан соң, кандидат, сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкилләре сайлаучыларның җыелган имзаларының гомуми санын исәплиләр һәм сайлауларны оештыручы комиссия тарафыннан билгеләнгән форма буенча имзалар җыю йомгаклары турында беркетмә төзиләр. Беркетмәгә тиешенчә кандидат, сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле имза сала.«;

м) 14 өлештә «ике нөсхәдә» сүзләрен төшереп калдырырга;

25) 45 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Паспортның (паспортның Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән аерым битләренең) яисә гражданның паспортын алмаштыручы документның һәм (яки) гаризада белем, төп эш яисә хезмәт урыны, били торган вазыйфасы (шөгыленең төре), шулай ук кандидатның депутат булып торуы турында күрсәтелгән белешмәләрне раслаучы документларның күчермәләре булмаган очракта кандидат, сайлау берләшмәсе аны (аларны) кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү турында мәсьәлә сайлау комиссиясе тарафыннан каралырга тиешле утырыш көненә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча бирергә хокуклы.»;

б) 2 өлештә:

беренче абзацта «кандидат» сүзеннән соң «, кандидатлар исемлеге» сүзләрен, «кандидатны» сүзеннән соң «, кандидатлар исемлеген» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта «кандидат» сүзеннән соң «, кандидатлар исемлеге» сүзләрен, «кандидатны» сүзеннән соң «, кандидатлар исемлеген» сүзләрен өстәргә;

в) 3 өлешнең 1 пунктында «Муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органы депутатларының һәм муниципаль сайлауларда сайланган муниципаль берәмлекләр башлыкларының» сүзләрен «Муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органы депутатларының һәм (яисә) муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының» сүзләренә алмаштырырга;

г) 3[1] өлештә «сайлауларны оештыра торган сайлау комиссиясенә» сүзләрен «кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен теркәүне гамәлгә ашыручы сайлау комиссиясенә» сүзләренә алмаштырырга;

26) 46 статьяда:

а) 7 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Эшләү чорына җәлеп ителүче экспертлар төп эштән азат ителәләр, аларның эш урыннары (вазыйфалары), билгеләнгән вазыйфаи окладлары һәм эш урыны буенча башка түләүләре сакланып кала.»;

б) 10 өлештә беренче җөмләдә «кандидатны» сүзеннән соң «, кандидатлар исемлеген» сүзләрен өстәргә, икенче җөмләдә «кандидатны» сүзеннән соң «, кандидатлар исемлеген» сүзләрен өстәргә, «таләп ителсә, кандидатны» сүзләреннән соң «кандидатлар исемлеген» сүзләрен өстәргә;

в) 11 өлештә беренче җөмләдә «һәр кандидатны» сүзләреннән соң «, кандидатлар исемлеген» сүзләрен, дүртенче җөмләдә «кандидатка» сүзеннән соң «сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиленә» сүзләрен өстәргә;

г) 12 өлештә «кандидатларны» сүзеннән соң «, кандидатлар исемлеген» сүзләрен өстәргә, «кандидат» сүзеннән соң «сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле» сүзләрен өстәргә;

д) 13 өлештә «кандидатны күрсәтү инициаторлары» сүзләрен «имзалар кәгазьләрен таныклаучы затлар» сүзләренә алмаштырырга;

е) 16 өлештә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) имзалар кәгазендә чынбарлыкка туры килми торган белешмәләр күрсәткән сайлаучыларның имзалары. Бу очракта имза бары тик Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә тору һәм яшәү урыны буенча теркәүне гамәлгә ашыра торган органның рәсми белешмәсе булганда гына йә әлеге статьяның 7 өлеше нигезендә тикшерүгә җәлеп ителгән экспертның бәяләмәсе нигезендә генә таныла;»;



6 пунктта «сайлаучылар имзаларын тикшерү эшенә җәлеп ителгән» сүзләрен «тикшерүгә җәлеп ителгән» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта «бу төзәтмәләр» сүзләрен «бу имзалар» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) әгәр имзалар кәгазе сайлаучылар имзаларын җыюны башкарган затның, кандидатның, кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсе вәкаләтле вәкиленең кулдан язылган имзалары белән таныкланмаган булса, йә бу имзаларның берәрсе дөрес булмаса, йә имзалар җыю вакытына 18 яшь тулмаган сайлаучылар имзаларын җыюны башкарган зат имзалар кәгазен таныклаган булса һәм (яисә) бу зат суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез дип танылган булса, йә имзалар кәгазен таныклау даталарының берәрсе күрсәтелмәгән булса яисә кулдан язылмаган булса, йә сайлаучылар имзаларын җыюны башкарган зат турындагы белешмәләрдә һәм (яисә) имза кую датасында шушы зат, кандидат, кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсе вәкаләтле вәкиле тарафыннан сайлаучылар имзаларын җыюны башкарган зат, кандидат, кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсе вәкаләтле вәкиле белән махсус килештермичә кертелгән төзәтмәләр булса, йә имзалар кәгазендә сайлаучылар имзаларын җыюны башкарган зат турындагы, кандидат, кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсе вәкаләтле вәкиле турындагы белешмәләр тулысынча күрсәтелмәгән булса яисә дөреслеккә туры килмәсә, йә сайлаучылар имзаларын җыюны башкарган зат турындагы белешмәләр аның үз кулы белән кертелмәгән йә кулдан язылмаган яисә карандаш белән язылган булса;

9 пунктта «5, 6, 8, һәм 10 нчы кушымталарны» сүзләрен «4[1], 5, 6, 7[1], 8 һәм 10 нчы кушымталарда билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктта «сайлаучыларның имзаларын тикшерү эшенә җәлеп ителгән» сүзләрен «тикшерүгә җәлеп ителгән» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктта «кандидат» сүзеннән соң «һәм (яисә) кандидат, кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсе вәкаләтле вәкиле» сүзләрен өстәргә;

13 пунктта «кандидатның» сүзеннән соң «һәм (яисә) кандидат, кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсе вәкаләтле вәкиленең» сүзләрен өстәргә;

ж) 17 өлештә «кандидатны» сүзеннән соң «кандидатлар исемлеген» сүзләрен өстәргә, «санала» сүзен «таныла» сүзенә алмаштырырга;

з) 21 өлештә «кандидатны» сүзеннән соң «, кандидатлар исемлеген» сүзләрен өстәргә;

и) 22 өлештә «һәм кандидат» сүзеннән соң «кандидатлар исемлеген» сүзләрен өстәргә;

к) 24 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. Беркетмәнең күчермәсе, кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү турындагы мәсьәлә каралырга тиешле комиссия утырышына кадәр кимендә ике тәүлектән дә соңга калмыйча, әлеге кандидатка, сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиленә тапшырыла. Әгәр тикшерү нәтиҗәләре буенча сайлаучыларның дөрес имзалары саны кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү өчен җитәрлек булмавы ачыкланса йә дөрес булмаган һәм (яисә) гамәлгә яраксыз имзаларның саны тикшерү өчен аралап алынган имзаларның гомуми саныннан 10 процент һәм аннан күбрәк булса, кандидат, сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле комиссиядә йомгаклау беркетмәсенең күчермәсе белән бергә имзалар кәгазьләрен тикшерү ведомостьларының таныкланган күчермәләрен алырга хокуклы, аларда сайлаучыларның имзаларын дөрес түгел һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип тану нигезләре (сәбәпләре), шундый имзалар булган папкаларның, имзалар кәгазенең номерлары һәм имзалар кәгазендәге юл күрсәтелә, шулай ук кандидат тиешле имзаларны дөрес түгел һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез була торган рәсми документларның күчермәләрен алырга хокуклы.»;

л) 25 өлешнең беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Йомгаклау беркетмәсе кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү йә кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәүдән баш тарту турында комиссия карарына кушып бирелә.»;

27) 47 статьяда:

а) 6 өлештә:

түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пункт өстәргә:

«$6^1$) әгәр кандидатны теркәү өчен 200 һәм аннан артыграк сайлаучыларның имзалары таләп ителсә, — тикшерү өчен сайлап алынган, әгәр федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, имзаларның гомуми санынан дөрес булмаган һәм (яисә) гамәлгә яраксыз имзаларның 10 һәм аннан артыграк процентын ачыклау;



7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) кандидатны теркәү өчен бирелгән сайлаучыларның дөрес имзаларының саны җитмәү;»;

8 пунктта «юкка чыгарылмаган һәм кире алынмаган» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 7 өлештә түбәндәге эчтәлекле $2^1$ һәм $2^2$ пунктлар өстәргә:

«$2^1$) кандидатлар исемлеген теркәү өчен бирелгән сайлаучылар имзалары арасында, имзалар җыю, әгәр Федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, закон белән тыелган урыннарда җыелган имзаларның 10 процентан артык булуы;

$2^2$) әгәр кандидатлар исемлеген теркәү өчен 200 һәм аннан артыграк сайлаучыларның имзалары таләп ителсә, — тикшерү өчен сайлап алынган, әгәр федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, имзаларның гомуми санынан дөрес булмаган һәм (яисә) гамәлгә яраксыз имзаларның 10 һәм аннан артыграк процентын ачыклау;»;

в) 8 өлешнең 2 пунктында «юкка чыгарылмаган һәм кире алынмаган» сүзләрен төшереп калдырырга;

28) 60 статьяның 13 өлешендә «йә сайланмаган һәм тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның 3 процентан да кимрәк тавышын җыйган кандидатны» сүзләрен төшереп калдырырга;

29) 66 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Тиешле бюджет акчалары исәбеннән сайлау комиссияләренең түбәндәге чыгымнары финанслана:

1) сайлау комиссияләренең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларына, сайлау комиссияләре аппаратлары хезмәткәрләренә хезмәт өчен өстәмә түләү (бүләкләү), тиешле сайлауларны әзерләү һәм үткәрү чорына төп эшеннән азат ителгән сайлау комиссияләренең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларына компенсацияләр түләү, шулай ук сайлау комиссияләрендә гражданхокукый шартнамәләр буенча эшләүче гражданнарга һәм сайлау комиссияләре каршындагы контроль-ревизия хезмәтләре составында эшләү өчен җибәрелә торган белгечләргә түләүләр;

2) матбугат продукциясен әзерләү һәм нәшрият эшчәнлеген гамәлгә ашыру чыгымнары;

3) тиешле сайлауларны әзерләү һәм үткәрү, сайлау комиссияләренең эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле җайланмалар (шул исәптән технологик), башка матди кыйммәтләр сатып алу, китерү һәм урнаштыру;

4) транспорт чыгымнары;

5) сайлау документларын китерү һәм саклау, аларны архивка тапшыру өчен әзерләү яисә юкка чыгару;

6) тиешле сайлауларны әзерләүгә, шулай ук сайлау комиссияләренең эшчәнлеген тәэмин итүгә һәм үткәрүгә бәйле командировкалар һәм башка максатлар;

7) сайлау системасын үстерү, шул исәптән яңа сайлау технологияләрен, автоматлаштыру чараларын гамәлгә кертү, сайлаучыларның хокукый культурасын арттыру һәм сайлауларны оештыручыларны укыту.»;

б) 12 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларны уздырганда, шулай ук сайлаучыларның саны ике йөз мең кешедән арткан муниципаль берәмлекләрдә җирле үзидарә органнарына сайлаулар уздырганда кулланыла торган бюллетеньнәрне, махсус билгеләрне (маркаларны) сатып алулар тиешле сайлауларны оештыра торган комиссия тарафыннан яисә түбәнгерәк тиешле комиссияләр карары нигезендә «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

в) 13 өлештә «сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле товарлар» сүзләрен «товарларны, эшләрне яисә хезмәт күрсәтүләрне сатып алуга» сүзләренә алмаштырырга;

30) 69 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарын сайлауларда кандидатның сайлау фонды, кандидатның сайлау кампаниясен финанслау чыгымнары биш мең сумнан артмаган очракта, махсус сайлау счеты ачылмыйча төзелә. Бу очракта сайлау фонды кандидатның бары тик үз акчалары исәбеннән генә төзелә.»;

31) 70 статьяның 3 өлешендәге 1 пунктында «кандидатны» сүзеннән соң «, кандидатлар исемлеге» сүзләрен өстәргә;

32) 73 статьяда:

а) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Әгәр теркәлгән кандидат, шул исәптән кандидатлар исемлегендәге кандидат та, элек хөкем ителгән булса яисә аның хөкем ителүе гамәлдә булса, мәгълүмат стендында кандидатның хөкем ителүе турында белешмәләр, ә әгәр хөкем ителүе юкка чыгарылган яисә кире алынган булса, хөкем ителүне юкка чыгару яисә кире алу датасы турында белешмәләр урнаштырыла.»;

б) 8 өлештә:



«тавыш бирү өчен стационар әрҗәләр» сүзләренә кадәр «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 21 статьясындагы 9 пунктының «б» пунктчасы нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана торган технологик җиһазлау нормативларына таянып, үтә күренмәле яисә ярым үтә күренмәле материалдан әзерләнгән» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле өченче җөмлә өстәргә: «Электрон тавыш бирү үткәргәндә электрон тавыш бирү комплекслары файдаланыла.»;

33) 74 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

34) 75 статьяда:

а) 2 өлештә «сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе күрсәтмәсе буенча» сүзләрен «тиешле сайлау комиссиясе күрсәтмәсе буенча» сүзләренә алмаштырырга;

б) $5^1$ өлештә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

в) 10 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Әгәр сайлау бюллетененә кертелгән теркәлгән кандидат элек хөкем ителгән булса яисә аның хөкем ителүе гамәлдә булса, шул хактагы белешмәләр сайлау бюллетенендә күрсәтелергә тиеш. «;

г) 16 өлешнең беренче җөмләсенә «(шул исәптән вакытыннан алда тавыш бирү)» сүзләрен өстәргә;

35) 76 статьяда:

а) 2 өлештә «кабат тавыш бирү» сүзләреннән соң «вакытыннан алда тавыш бирү һәм» сүзләрен өстәргә;

б) 5 өлештә «әгәр сайлаучы бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш бирсә, — шулай ук бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгы да күрсәтелә» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 7 өлештә өченче җөмләне төшереп калдырырга;

г) 9 өлештә дүртенче җөмләне төшереп калдырырга;

д) 14 өлештә «йә алардан файдаланганда, тавышларны санауның техник чараларына» сүзләрен өстәргә;

е) 15 өлешнең беренче җөмләсендә «референдум,» сүзен төшереп калдырырга;

36) түбәндәге эчтәлекле $76^1$ статья өстәргә:

«76[1] статья. **Вакытыннан алда тавыш бирү**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлаулар уздырганда тавыш бирү көнендә нигезле сәбәп (отпуск, командировка, хезмәт һәм уку эшчәнлеге режимы, дәүләт һәм иҗтимагый вазыйфалар үтәү, сәламәтлеге торышы һәм башка нигезле сәбәпләр) аркасында үзенең тору урынында була алмаган һәм сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлау участогындагы тавыш бирү бинасына килә алмаган сайлаучыга вакытыннан алда тавыш бирү мөмкинлеге бирелергә тиеш. Вакытыннан алда тавыш бирү сайлаучы тарафыннан территория комиссиясе (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе) (тавыш бирү көненә кадәр 10 — 4 көн кала) яисә участок комиссиясе бинасында (тавыш бирү көненә кадәр өч көннән дә иртәрәк түгел) бюллетень тутыру юлы белән үткәрелә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда, Татарстан Республикасы референдумында, җирле үзидарә органнарына сайлауларда, җирле референдумда тавыш бирү көне, закон белән тавыш бирү бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары белән каралганда, башка сайлауларда тавыш бирү көне белән берләштерелгән очракта, сайлаучы бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирә торган комиссия бинасында вакытыннан алда (әмма тавыш бирү көненә кадәр 10 көннән дә иртәрәк түгел) тавыш бирә ала.

3. Вакытыннан алда тавыш бирү башкарыла торган биналар әлеге Законның 73 статьясындагы 2 өлеше нигезендә җиһазландырылган һәм тәэмин ителгән булырга тиеш. Вакытыннан алда тавыш бирү биналары җиһазы вакытыннан алда тавыш бирүне уздырганда тиешле комиссиянең барлык әгъзаларының, күзәтүчеләрнең, әлеге Законның 21 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затларның булу мөмкинлеген күздә тотарга тиеш. Вакытыннан алда тавыш бирү эш көннәрендә кичке вакытта (җирле вакыт буенча 16 сәгатьтән соң) һәм ял көнендә кимендә дүрт сәгать уздырыла. Вакытыннан алда тавыш бирүне уздыру өчен комиссия эше графигы сайлауларны оештыручы комиссия яисә аның йөкләмәсе белән түбәнгерәк комиссияләр тарафыннан билгеләнә, тиешле комиссиянең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында (булган очракта) урнаштырыла, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылырга яисә башка алым белән халыкка игълан ителергә тиеш. Вакытыннан алда тавыш бирү әлеге Законның 76 статьясында каралган таләпләрне үтәп, әлеге статья белән билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып уздырыла. Вакытыннан алда тавыш бирүне оештыру тавыш бирү серен тәэмин итәргә, сайлаучының ихтыяр белдерүен бозып күрсәтү ихтималын калдырмаска, бюллетеньнең саклануын һәм тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә сайлаучының тавышын исәпкә алуны тәэмин итәргә тиеш.

4. Территория комиссиясе (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе) вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучыларның исемлеген һәрбер сайлау участогы буенча аерым төзи.

5. Вакытыннан алда тавыш бирүче сайлаучы тиешле комиссиягә, вакытыннан алда тавыш бирү сәбәбен күрсәтеп, гариза бирә. Гаризада сайлаучының фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, аның яшәү урыны адресы күрсәтелгән булырга тиеш. Тиешле комиссия әгъзасы сайлаучының гаризасында бу сайлаучының вакытыннан алда тавыш бирүенең датасын һәм вакытын язып куя. Гариза вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучыларның исемлегенә (ә участок комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш биргән очракта — сайлаучыларның исемлегенә) кушып бирелә.

6. Сайлаучы территория комиссиясе, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе бинасында тавыш бирсә, аңа бирелә торган бюллетеньнең алгы ягында өске уң почмакта тиешле комиссиясенең ике әгъзасының имзалары куела, алар комиссия мөһере белән таныклана. Сайлаучы бюллетень алганда, вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучыларның исемлегендә аның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, туган елы (18 яшьтә булса — өстәмә рәвештә туган көне һәм ае), яшәү урыны адресы күрсәтелә, шуннан соң референдумда катнашучы исемлектә үзенең паспортының яисә гражданның паспортын алмаштыручы документның сериясен һәм номерын язып куя. Сайлаучы ризалыгыннан яисә аның үтенече буенча ул күрсәткән паспортның яисә гражданның паспортын алмаштыручы документның сериясе һәм номеры хәлиткеч тавыш хокукына ия комиссия әгъзасы тарафыннан язып куелырга мөмкин. Сайлаучы язманың дөреслеген тикшерә һәм бюллетень алу турындагы тиешле графада кул куя. Сайлаучыга бюллетень биргән комиссия әгъзасы шулай ук вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучылар исемлегенең тиешле графасына имза сала.

7. Вакытыннан алда тавыш бирү уздыру өчен үтә күренмәле булмаган махсус конвертлар кулланыла. Вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучы тутырган бюллетень ябыштырып куела торган конвертка яшерен тавыш бирү урыныннан читтә сайлаучы тарафыннан салына. Конвертның ябыштырылган урынында тиешенчә территория комиссиясенең, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең, округ сайлау комиссиясенең яисә участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия ике әгъзасы,

шулай ук киңәш бирү тавышы хокукына ия комиссия әгъзалары, күзәтүчеләр (теләк буенча) имза сала. Күрсәтелгән имзалар тиешле комиссия мөһере белән таныклана.

8. Бюллетеньнәр салынган мөһерләнгән конверт тиешле комиссиянең секретаренда саклана: территория комиссиясе, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе бинасында — бюллетеньнәр салынган конвертлар участок комиссиясенә тапшырылган вакытка кадәр, участок комиссиясе бинасында — тавыш бирү көненә кадәр.

9. Территориаль комиссия (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе), тавыш бирү көненә кадәрге көннән дә соңга калмыйча, вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучыларның тиешле исемлеген аңа кушып бирелгән сайлаучыларның вакытыннан алда тавыш бирү турындагы гаризалары белән бергә, вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучыларның бюллетеньнәре салынган конвертларны түбәнгерәк һәр участок комиссиясенә тапшыра.

10. Вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучыларның исемлеген алганнан соң ук участок комиссиясе тарафыннан территориаль комиссия, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучылар исемлегендә сайлаучыларның фамилиясе янына «Вакытыннан алда тавыш бирде» дигән тамга куела. Вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучылар исемлеге, аңа кушып бирелгән сайлаучыларның вакытыннан алда тавыш бирү турындагы гаризалары белән бергә, сайлаучылар исемлегенә өстәп куела. Әгәр сайлаучы участок комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш бирсә, «Вакытыннан алда тавыш бирде» дигән тамга сайлаучылар исемлегенә бюллетень биргәндә куела.

11. Һәр сайлау участогы буенча вакытыннан алда тавыш биргән, шул исәптән территориаль комиссия, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе бинасында, сайлаучылар саны турында мәгълүмат тавыш бирү көненә кадәр участок комиссиясе, территориаль комиссия, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе тарафыннан турыдан-туры югарырак сайлау комиссиясенә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә һәм срокларда Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырыла.

12. Участок комиссиясе рәисе тавыш бирү көнендә тавыш бирү башланыр алдыннан, әмма тавышларны санауның техник чараларын әзерләгәннән һәм аларны тавыш бирү режимына күчергәннән соң (алардан файдаланган очракта), участок комиссияләре әгъзалары, күзәтүчеләр, әлеге Кодексның 21 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затлар булганда, шул сайлау участогында сайлаучылар исемлегенә кертелгән вакытыннан алда тавыш биргән, шул исәптән территориаль комиссия, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе бинасында, сайлаучыларның саны турында хәбәр итә, күреп танышу өчен бюллетеньнәр салынган мөһерләнгән конвертларны бирә. Шуннан соң участок комиссиясе рәисе бер-бер артлы һәр конвертны ача бара.



13. Вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучыларның саны сайлау участогындагы сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар санының бер процентыннан артып китсә (ләкин кимендә ун сайлаучы), вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучыларның конвертларыннан чыгарылган бюллетеньнәрнең арткы ягына бюллетеньнәр конвертлардан чыгарылганнан соң ук участок комиссиясе мөһере куела.

14. Участок комиссиясе рәисе, әлеге статьяның 12 һәм 13 өлешләрендә күрсәтелгән гамәлләрне кылганнан соң, сайлаучының ихтыяр белдерү серен саклап, бюллетеньнәрне тавыш бирү әрҗәсенә яки тавышларны санауның техник чарасына (ул кулланылган очракта) сала. Конвертта әлеге статьяның 7 өлешендә каралган реквизитлар булмаса яки конверттан тиешле сайлау округы буенча тавыш бирү өчен билгеләнгән рәвештәге бердән артык бюллетень алынган булса, тиешле сайлау округы буенча әлеге конверттан алынган барлык тавыш бирү бюллетеньнәре гамәлгә яраксыз дип таныла, бу хакта акт төзелә. Бу бюллетеньнәрнең һәркайсының алгы ягында, кандидатлар фамилиясеннән (сайлау берләшмәләре исемнәреннән) уңда урнашкан квадратларга, бюллетеньне гамәлгә яраксыз дип тану сәбәбе турында языла, ул участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия ике әгъзасының имзасы белән раслана һәм участок комиссиясенең мөхере белән таныклана.»;

37) 77 статьяның 8 өлешендә «тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү өчен тиешле санда күчерелмә әрҗәләр» сүзләрен «тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүләрне оештыру өчен «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 21 статьясындагы 9 пунктының «б» пунктчасы нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе раслый торган технологик җайланмалар нормативлары буенча үтә күренмәле яисә ярым үтә күренмәле материалдан ясалган тавыш бирү өчен тиешле санда күчерелмә әрҗәләр» сүзләренә алмаштырырга;

38) 78 статьяда:

а) 2 өлешнең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) түбәндәге тәртиптә беркетмә юллары:

1 юл: тавыш бирү тәмамланган мизгелгә исемлеккә кертелгән сайлаучылар саны;

2 юл: участок комиссиясе тарафыннан алынган бюллетеньнәр саны;

3 юл: алдан тавыш биргән сайлаучыларга, шул исәптән 4 юлда аерым – территория комиссиясе (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе) бинасында, бирелгән бюллетеньнәр саны;

5 юл: тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

6 юл: тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

7 юл: юкка чыгарылган бюллетеньнәр саны;

8 юл: тавыш бирү өчен күчерелмә әрҗәләрдәге бюллетеньнәр саны;

9 юл: тавыш бирү өчен стационар әрҗәләрдәге бюллетеньнәр саны;

10 юл: гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр саны;

11 юл: гамәлгә яраклы бюллетеньнәр саны;

12 юл: юкка чыккан бюллетеньнәр саны;

13 юл: алганда исәпкә алынмаган бюллетеньнәр саны.»;

б) 3 өлештә «16 юлына» сүзләрен «14 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 өлештә «16 юлына» сүзләрен «14 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

39) 79 статьяда:

а) 3 өлештә:

беренче җөмләдә «5 юлына» сүзләрен «7 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

икенче җөмләне төшереп калдырырга;

өченче җөмләдә «һәм бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Тавышларны санауның техник чаралары кулланылганда, алынган күрсәткечләр, игълан ителгәннән соң, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәнең зурайтылган рәвешенең 7 юлына кертеләләр.»;

б) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Участок комиссиясе рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре участок комиссиясе тарафыннан алынган бюллетеньнәрнең санын төгәлләштерә, игълан итә һәм аны тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 2 юлына кертә (территория комиссиясе (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе) бинасында вакытыннан алда тавыш биргәннәр конвертларыннан алынган бюллетеньнәр турында күрсәткечләр күрсәтелгән санга керми). Тавышларны санауның техник чаралары кулланылганда, алынган күрсәткечләр, игълан ителгәннән соң, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәнең зурайтылган рәвешенең 2 юлына кертеләләр.»;



в) 5 өлештә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) тавыш бирү тәмамланган мизгелгә сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар санын (нинди дә сәбәпләр аркасында киткән сайлаучыларны исәпкә алмыйча);»;

түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:

«$3^1$) алдан тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны (сайлаучылар исемлегендә тиешле билгеләр саны буенча билгеләнә; территория комиссиясе, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучылар саны алдан тавыш биргән сайлаучылар исемлеге буенча тикшерелә).»;

4 – 6 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

г) 6 өлештә:

түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$) 3 һәм 4 юлларда – вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;»;

2 пунктта «3 юлга» сүзләрен «5 юлга» сүзләренә алмаштырырга, «тавыш биргән» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктта «4 юлга» сүзләрен «6 юлга» сүзләренә алмаштырырга;

4 – 6, $6^1$, 7 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

унынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

д) 13 өлештә «6 юлына» сүзләрен «8 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

е) түбәндәге эчтәлекле $16^1$ өлеш өстәргә:

«$16^1$. Территория комиссиясе, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучылар саны (вакытыннан алда тавыш бирүне территория комиссиясе, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе һәм участок комиссиясе биналарында үткәргәндә – күрсәтелгән комиссияләр биналарында вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучылар саны) сайлау участогында сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучыларның бер процентыннан (ләкин ун сайлаучыдан да

ким түгел) артыграк булса, участок комиссиясе комиссиянең теләсә кайсы әгъзасы, күзәтүче таләбе буенча әлеге Кодексның 76[1] статьясының 13 өлеше нигезендә арткы ягына участок комиссиясе мөһере сугылган бюллетеньнәр буенча тавышларны аерым санау үткәрергә тиеш. Күрсәтелгән санау нәтиҗәләре буенча участок комиссиясе тарафыннан акт төзелә, ул тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәгә кушымта итеп бирелә.»;

ж) 17 өлешнең сигезенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Гамәлгә яраксыз бюллетеньнәрнең гомуми саны (әлеге статьяның 13 өлеше һәм әлеге Кодексның 76[1] статьяның 14 өлеше нигезендә гамәлгә яраксыз дип танылган бюллетеньнәр санын исәпкә алып) тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 10 юлына язып куела.»;

з) 18 өлештә «16 юлына» сүзләрен «14 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

и) 19 өлештә «9 юлына» сүзләрен «11 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

к) 20 өлештә «7 юлына» сүзләрен «9 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

л) 22 өлештә «14 һәм 15 юлларына» сүзләрен «12 һәм 13 юлларына» сүзләренә алмаштырырга;

м) 23 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Санау тәмамланганнан соң, тиешле бюллетеньнәрдә тавыш бирелгән теркәлгән кандидатлар, кандидатлар исемлекләре буенча сортларга аерылган бюллетеньнәр аерым төргәкләргә төреп куела. Гамәлгә яраксыз һәм юкка чыгарылган бюллетеньнәр аерым төргәкләргә төреп куела. Һәр төргәккә андагы бюллетеньнәрнең саны, тиешле бюллетеньнәрдә тамга салынган теркәлгән кандидатның фамилиясе яисә тиешле бюллетеньнәрдә кандидатлары исемлегенә тамга салынган сайлау берләшмәсенең исеме язып куела йә тиешенчә «Гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр» тамгасы яисә башка тамгалар сугыла. Шул рәвешле җыеп куелган бюллетеньнәр, шулай ук әлеге статьяның 12 һәм 13 өлешләре нигезендә төргәкләргә төрелгән бюллетеньнәр, сайлаучылар исемлеге капчыкларга яисә тартмаларга тутырыла, аларда сайлау участогының номеры, барлык тутырылган бюллетеньнәрнең саны күрсәтелә. Капчыкларга яисә тартмаларга мөһер сугыла, һәм алар бары тик югарырак комиссия яисә суд карары буенча гына ачылырга мөмкин. Күрсәтелгән капчыкларга яисә тартмаларга участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары да, шулай ук киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары да үз имзаларын куярга хокуклы. Капчыкларны яисә тартмаларны тутыру әлеге Кодексның 21 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән затлар барында гамәлгә ашырыла, һәм аларга капчыкларга яисә тартмаларга үз имзаларын кую мөмкинлеге бирелә.»;



н) түбәндәге эчтәлекле 23[1] өлеш өстәргә:

«23[1]. Тавышларны санауның техник чарасы кулланылганда, сайлаучылар исемлекләре белән эшләүне тәгәлләгәннән соң участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары, күзәтүчеләр, әлеге Кодексның 21 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затлар барында түбәндәгеләр башкарыла:

1) тавыш бирү бинасында тавыш бирүдә нинди дә булса сәбәпләр аркасында тавышларны санауның техник чарасы кулланылмаган булса, участок комиссиясе тавышларны санауның әлеге техник чарасында махсус тартмадагы йә тавыш бирү өчен резерв стационар әрҗәдәге мөһерләрнең (пломбаларның) бөтенлеген тикшерә, мондый әрҗәне ача һәм андагы барлык бюллетеньнәрне, тавыш бирү сере бозылмаслык итеп, тавышларны санауның техник чарасына төшерә;

2) участок комиссиясе тавыш бирү өчен күчерелмә әрҗәләрдәге бюллетеньнәрне әлеге статьяның 13 өлешендә каралган тәртиптә саный, аннары барлык бюллетеньнәр тавыш бирү өчен күчерелмә әрҗәләрдәге тавышларны санау режимына күчерелгән тавышларны санауның техник чарасына салына, бюллетеньнәрне салу тавыш бирү сере бозылмаслык итеп башкарыла;

3) участок комиссиясе сайлаучылар исемлекләре белән эшләгән этапта алынган күрсәткечләрне, ягъни тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәнең зурайтылган рәвешенең 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7 юлларына кертелгән күрсәткечләрне тавышларны санауның техник чарасына кертә;

4) участок комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәне тавышларны санауның техник чарасыннан бастырып чыгара, тиешле күрсәткечләр турында игълан итә һәм аларны тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәнең зурайтылган рәвешенең 8, 9, 10, 11, 14 һәм алдагы юлларына кертә;

5) участок комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәгә кертелгән күрсәткечләрнең контроль чагыштырмаларын тикшерә. Күрсәтелгән контроль чагыштырмалар үтәлмәсә, участок комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәнең барлык юллары яисә аерым юллары буенча тавышларны өстәмә санау, шул исәптән бюллетеньнәрне өстәмә рәвештә кулдан санау турында карар кабул итә. Өстәмә санаулар нәтиҗәсендә контроль чагыштырмалар кабат үтәлмәсә, участок комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәгә

кушымта итеп бирелә торган тиешле карар кабул итә һәм аерма турындагы күрсәткечләрне тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәнең 12 һәм 13 юлларына кертә;

6) әлеге статьяның $16^1$ өлешендә каралган очракта участок комиссиясе, вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучылар конвертларыннан алынган һәм арткы ягына участок комиссиясе мөһере сугылган бюллетеньнәрне аерып куеп, бюллетеньнәрне сортларга аера. Күрсәтелгән бюллетеньнәр буенча тавышларны аерым санау кулдан йә тавышларны санауның техник чарасын кулланып башкарыла. Күрсәтелгән санау нәтиҗәләре буенча участок комиссиясе акт төзи, ул тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәгә кушымта итеп бирелә.»;

о) 24 өлешкә түбәндәге эчтәлекле икенче – дүртенче җөмләләр өстәргә: «Тавышларны турыдан-туры санаганда шунда булган затлардан дәлилләнгән шикаятьләр (гаризалар) кергән очракта, тавышларны санауның техник чарасын кулланган участок комиссиясе тавышларны кичекмәстән әлеге чарадан башка (кулдан) турыдан-туры санау үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы. Мондый санау нәтиҗәләре буенча тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсенең 10, 11, 14 һәм алдагы юлларының берсендә генә булса да тавышларны кулдан санау күрсәткечләре һәм тавышларны санауның техник чарасын кулланып алынган күрсәткечләр арасында бер проценттан артыграк (кечерәк санны зуррагына бүлү юлы белән ачыклана торган), ләкин кимендә өч берәмлеккә аерма булуы ачыкланса, кулдан санау нәтиҗәләре буенча тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзелә. Мондый аерма ачыкланмаса, тавышларны санауның техник чарасы ярдәмендә алынган беркетмә имзалана һәм тавышларны кабат санаганда алынган күрсәткечләрнең беренче күрсәткечләр белән туры килүе турында акт төзелә, ул тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсе белән бергә югарырак комиссиягә җибәрелә.»;

п) 25 өлешкә түбәндәге эчтәлекле өченче җөмлә өстәргә: «Тавышларны санауның техник чарасын кулланып йә электрон тавыш бирү комплексыннан файдаланып алынган тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә алда әйтелгән имзалаудан соң юридик көчкә ия була.»;

р) 33 өлештә «1 – 15 юлларында» сүзләрен «1 – 13 юлларында» сүзләренә, «1 – 15 юлларына» сүзләрен «1 – 13 юлларына» сүзләренә, «16 юлына» сүзләрен «14 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

40) 80 статьяда:



а) 7 өлешнең икенче һәм өченче җөмләләрен төшереп калдырырга;

б) 13 өлештә «1 – 15 юлларына» сүзләрен «1 – 13 юлларына» сүзләренә, «16 юлын» сүзләрен «14 юлын» сүзләренә алмаштырырга;

41) 82 статьяда:

а) 1 өлештә «, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә «, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

42) 91 статьяның 13 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

43) $91^1$ статьяның 3 өлешендәге 2 пунктында «шулай ук әлеге Кодексның $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләрдән» сүзләрен төшереп калдырырга;

44) 93 статьяның 14 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

45) 95 статьяның 4 өлешендәге 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

46) 97 статьяда:

а) 3 өлештә «7 процент һәм аннан артыграк» сүзләрен «5 процент һәм аннан артыграк» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә «7 процент һәм аннан артыграк» сүзләрен «5 процент һәм аннан артыграк» сүзләренә, «7 проценттан кимрәк» сүзләрен «5 проценттан кимрәк» сүзләренә алмаштырырга;

в) 5 өлештә «7 проценттан кимрәге» сүзләрен «5 проценттан кимрәге» сүзләренә алмаштырырга;

г) $7^1$ өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

д) 9 өлештә «$97^1$ статьясындагы 4 өлешендә яисә» сүзләрен төшереп калдырырга;

47) $97^1$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

48) 98 статьяда:

а) 1 өлешнең өченче җөмләсен үз көчен югалткан дип танырга;

б) 8 өлештә «(әлеге Кодексның $97^1$ статьясы нигезендә алынган депутат мандатларын исәпкә алып)» сүзләрен төшереп калдырырга;

49) 99 статьяның 1 өлешендә «Сәяси партияләр арасында» сүзләрен төшереп калдырырга;

50) 100 статьяда:
а) 1 өлештә «өч көн эчендә» сүзләрен «биш көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга;
б) 2 өлештә «$97^{1}$ статьясындагы 4 өлешендә яисә» сүзләрен төшереп калдырырга;

51) 103 статьяда:
а) 1 өлештә «$97^{1}$ статьясындагы 4 өлеше яисә» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;
в) 5 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5. Депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатларның республика исемлегенә кертелгән теркәлгән кандидат әлеге республика исемлегеннән түбәндәге очракта төшереп калдырыла:»;

52) $104^{4}$ статьяда:
а) 6 өлештә «Муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының» сүзләрен «Муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының һәм (яисә) муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының» сүзләренә алмаштырырга;
б) 7 өлештә «кандидатның кире алынмаган һәм юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булган очракта» сүзләрен «кандидат элек хөкем ителгән яисә хөкем ителүе гамәлдә булса» сүзләренә алмаштырырга;

53) $104^{5}$ статьяда:
а) 1 өлештә «муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының» сүзләрен «муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының һәм (яисә) муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының» сүзләренә алмаштырырга;
б) 6 өлештә:
2 пунктка «, һәм бу кимчелек әлеге статьяның 5 өлешендә билгеләнгән тәртиптә бетерелмәсә» сүзләрен өстәргә;



3 пунктта «$104^{4}$ статьясының 6 өлешен» сүзләрен «$104^{4}$ статьясының 11 өлешен» сүзләренә алмаштырырга;

54) $104^{8}$ статьяның 12 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

55) $104^{9}$ статьяның 14 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

56) $104^{11}$ статьяның 4 өлешендәге 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

57) $104^{13}$ статьяның 1 өлешендә «өч көн эчендә» сүзләрен «биш көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

58) $108^{1}$ статьяның 3 өлешендәге 2 пунктында «шулай ук әлеге Кодексның $97^{1}$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен чыгарган сәяси партияләрдән» сүзләрен төшереп калдырырга;

59) 117 статьяның 8 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

60) 118 статьяның 6 өлешендә «, әлеге Кодексның 117 статьясындагы 8 өлеше, 120 статьясындагы 3 өлеше һәм 122 статьясындагы 2 өлеше нигезендә муниципаль берәмлек уставында башкасы каралмаса,» сүзләрен төшереп калдырырга;

61) 120 статьяда:
а) 1 өлештә «өч көн эчендә» сүзләрен «биш көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга;
б) 3 һәм 4 өлешләрне үз көчләрен югалткан дип танырга;

62) 122 статьяның 2 һәм 3 өлешләрен үз көчләрен югалткан дип танырга;

63) 127 статьяның 1 өлешендә «өч көн эчендә» сүзләрен «биш көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

64) 132 статьяга түбәндәге эчтәлекле $2^{1}$ өлеш өстәргә:
«$2^{1}$. Әлеге Кодексның 60 статьясындагы 13 өлеше нигезләмәләре, әлеге Кодексның күрсәтелгән нормасы үз көченә кергәннән соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, муници-

паль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлауларны үткәргәндә кулланылмый.»;

65) 1 нче кушымтага искәрмәдә «кандидатның кире алынмаган һәм юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булса» сүзләрен «кандидат элек хөкем ителгән яисә хөкем ителүе гамәлдә булса» сүзләренә алмаштырырга;

66) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 нче кушымта

ТАВЫШ БИРҮ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДА БЕРКЕТМӘЛӘРГӘ КЕРТЕЛГӘН КҮРСӘТКЕЧЛӘРНЕҢ КОНТРОЛЬ ЧАГЫШТЫРМАСЫ (САННАР БЕЛӘН БЕРКЕТМӘЛӘРНЕҢ ӘЛЕГЕ КОДЕКСНЫҢ 78 СТАТЬЯСЫ НИГЕЗЕНДӘ НОМЕР СУГЫЛГАН ЮЛЛАРЫ БИЛГЕЛӘНДЕ)

| | |
|---|---|
| 1 күбрәк яисә тигез | 3 + 5 + 6 |
| 2 тигез | 3 + 5 + 6 + 7 + 12 – 13 |
| 8 + 9 тигез | 10 + 11 |
| 11 тигез | 14 + беркетмәнең калган барлык юллары»; |

67) 10 нчы кушымтада:

а) сызык астындагы юлда «шулай ук» сүзләреннән соң «муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыгы үз вәкаләтләрен башкара торган» сүзләрен өстәргә;

б) сызык астындагы юлда «яисә шөгыльләренең төре» сүзләрен «(төп эш яисә хезмәт итү урыны булмаган очракта – шөгыльләре төре)» сүзләренә алмаштырырга;

в) искәрмәдә «кандидатның кире алынмаган һәм юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булган очракта» сүзләрен «кандидат элек хөкем ителгән яисә хөкем ителүе гамәлдә булса» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:



1) 13 статьяда:

а) 3 пунктта «уку урынында,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 7 пунктта «туган көнен» сүзләрен «туган числосын» сүзләренә алмаштырырга;

в) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Референдумда катнашучыларның референдум үткәрү инициативасын яклаган имзалары куелган имза кәгазенең һәркайсы референдум үткәрү буенча инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле тарафыннан таныкланырга тиеш. Имза кәгазен таныклаганда, инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле үз фамилиясе, исеме һәм атасының исеме каршына үз кулы белән имзасын куя һәм аны кую датасын күрсәтә.»;

г) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Имзалар җыюны төгәлләгәннән соң, референдум үткәрү буенча инициатив төркемнең вәкаләтле вәкилләре референдумда катнашучыларның җыелган имзаларының гомуми санын исәплиләр һәм имзаларны җыю йомгаклары турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән форма буенча беркетмә төзиләр. Беркетмәгә референдум үткәрү буенча инициатив төркемнең тиешле вәкаләтле вәкиле имза куя.»;

2) $13^1$ статьяның 1 пунктында «ике нөсхәдә» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) $13^2$ статьяда:

а) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Җәлеп ителә торган экспертлар эшләү чорында төп эшләреннән азат ителәләр, аларның эш урыны (вазыйфалары), эш урынындагы вазыйфаи окладлары һәм башка түләүләр сакланып кала.»;

б) 6 пунктта «имзаларның дөреслеген тикшерү эшенә җәлеп ителгән» сүзләрен «тикшерү эшенә җәлеп ителгән» сүзләренә алмаштырырга;

в) 7 пунктта:

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) имза кәгазендә дөреслеккә туры килмәгән белешмәләр күрсәткән референдумда катнашучылар имзалары. Бу очракта имза Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны буенча һәм яшәү урыны буенча теркәү белән шөгыльләнүче органның рәсми белешмәсе йә әлеге статьяның 2 пункты нигезендә тикшерү эшенә җәлеп ителгән эксперт бәяләмәсе булганда гына гамәлгә яраксыз дип танылырга мөмкин;»;

«е» пунктчасында «референдумда катнашучыларның имзаларын тикшерү эшенә җәлеп ителгән» сүзләрен «тикшерү эшенә җәлеп ителгән» сүзләренә алмаштырырга;

«ж» пунктчасында «аларга» сүзен «бу имзаларга» сүзләренә алмаштырырга;

«з» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«з) референдумда катнашучыларның имза кәгазендәге барлык имзалары, әгәр имза кәгазе референдумда катнашучылар имзаларын җыйган затның һәм (яисә) референдум үткәрү буенча инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиленең үз куллары белән куелган имзалары белән таныкланмаган булса, йә бу имзаларның берәрсе генә дөрес булмаса, йә имза кәгазе имзалар җыю мизгеленә 18 яшькә җитмәгән, референдумда катнашучылар имзаларын җыйган зат тарафыннан таныкланган булса һәм (яисә) әлеге зат суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип танылган булса, йә имза кәгазен таныклау даталарының берәрсе генә кулдан күрсәтелмәгән яисә кертелмәгән булса, йә референдумда катнашучылар имзаларын җыйган зат турындагы белешмәләрдә һәм (яисә) шушы зат, референдум үткәрү буенча инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле тарафыннан имзалар кую датасында тиешенчә референдумда катнашучылар имзаларын җыйган зат, референдум үткәрү буенча инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле белән махсус килештерелмәгән төзәтүләр булса, йә референдумда катнашучылар имзаларын җыйган зат, референдум үткәрү буенча инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле турындагы белешмәләр имза кәгазендә тулы күләмдә күрсәтелмәгән булса яисә дөреслеккә туры килмәсә, йә референдумда катнашучылар имзаларын җыйган зат турындагы белешмәләр аның үз кулы белән кертелмәгән йә кулдан язылмаган яисә карандаш белән язылган булса;»;

«л» пунктчасында «референдумда катнашучылар имзаларын тикшерү эшенә әлеге статьяның 2 пункты нигезендә җәлеп ителгән» сүзләрен «тикшерү эшенә әлеге статьяның 2 пункты нигезендә җәлеп ителгән» сүзләренә алмаштырырга;

г) 10 пунктта «саналалар» сүзен «танылалар» сүзенә алмаштырырга;

д) 11 пунктта «референдум үткәрү инициаторлары» сүзләрен «имза кәгазьләрен таныклый торган затлар» сүзләренә алмаштырырга;

4) 14 статьяның 4 пунктында:

а) түбәндәге эчтәлекле «б$^{1}$» пунктчасы өстәргә:

«б$^{1}$) референдумны билгеләү өчен 200 һәм аннан артыграк референдумда катнашучылар имзасы булу таләп ителсә, федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, тикшерү өчен сайлап алынган имзаларның гомуми санынннан 10 процент һәм аннан күбрәк дөрес булмаган һәм (яисә) гамәлгә яраксыз имзалар табу;»;

б) «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) референдум билгеләү өчен тапшырылган референдумда катнашучыларның дөрес имзалары саны җитәрлек булмау;»;

5) 17 статьяның «е» пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

6) 19 статьяда:

а) «е» пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

б) «ж» пунктчасында «тавыш бирүне» сүзләреннән соң «, шулай ук вакытыннан алда тавыш бирүне» сүзләрен өстәргә;

7) 22 статьяда:

а) 1 пунктта «бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыклары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 пунктта «Тавыш бирү көнендә» сүзләреннән соң «, шулай ук вакытыннан алда тавыш бирү көннәрендә» сүзләрен өстәргә;

в) 6 пунктта «башка референдум комиссияләрендә,» сүзләреннән соң «алар вакытыннан алда тавыш бирүне үткәргәндә,» сүзләрен өстәргә;

г) 8 пунктта «документ участок комиссиясенә әлеге статьяның 3 пунктында күрсәтелгән чорга» сүзләрен «документ участок комиссиясенә вакытыннан алда тавыш бирү чорында йә әлеге статьяның 3 пунктында күрсәтелгән чорда» сүзләренә алмаштырырга;

д) 9 пунктта:

«а» пунктчасында «бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестры, референдум комиссиясендә булган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

«б» пунктчасында «тавыш бирү көнендә» сүзләреннән соң «, шулай ук вакытыннан алда тавыш бирү көннәрендә» сүзләрен өстәргә;

е) 11 пунктның «г» пунктчасында «тавыш бирү көнендә» сүзләреннән соң «, шулай ук вакытыннан алда тавыш бирү көннәрендә» сүзләрен өстәргә;

8) 26 статьяда:

а) 3 пунктта «йә гражданның бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыгы булу» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 14 пунктта:

бишенче җөмләдә «, шулай ук референдумда катнашучыга бүтән референдумда катнашу таныклыгы бирелгәннән соң гына» сүзләрен төшереп калдырырга;

җиденче җөмләдә «, ә бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгәндә, — шушы таныклыкны биргән комиссия әгъзасының имзасы белән таныклана» сүзләрен төшереп калдырырга;

9) 27 статьяның 2 пунктында «тавыш бирү көненә кадәр 45 көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен «тавыш бирү көненә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

10) 37 статьяның 1 пунктында «үзләре чыгарган кандидатлар исемлеге Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында һәм (яисә) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән булса яисә Татарстан Республикасы Сайлау кодексының $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган булса,» сүзләрен «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында һәм (яисә) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән булса,» сүзләренә алмаштырырга;

11) 43 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән референдум комиссияләренең түбәндәге чыгымнары финанслана:

1) референдум комиссияләренең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларына, референдум комиссияләре аппаратлары хезмәткәрләренә хезмәт өчен өстәмә түләү (бүләкләү), референдум комиссияләренең референдумны әзерләү һәм үткәрү чорында төп эшләреннән азат ителгән хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларына компенсацияләр түләү, шулай ук референдум комиссияләрендә граждан-хокукый шартнамәләр буенча эшләүче гражданнарга һәм референдум комиссияләренең контроль-ревизия хезмәтләре составында эшләү өчен җибәрелгән белгечләргә түләүләр;

2) басма продукция әзерләү һәм нәшерлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

3) референдумны әзерләү һәм үткәрү, референдум комиссияләре эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле җиһазлар



(шул исәптән технологик), башка матди кыйммәтләр алу, аларны китерү һәм урнаштыру;

4) транспорт чыгымнары;

5) референдумны әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле документларны китерү һәм саклау, аларны архивка тапшырырга яисә юкка чыгарырга әзерләү;

6) референдумны әзерләүгә һәм үткәрүгә, шулай ук референдум комиссияләре эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле командировкалар һәм башка максатлар;

7) автоматлаштыру чараларыннан файдалану һәм аларны куллану, референдумда катнашучыларның хокукый культурасын арттыру һәм референдумны оештыручыларны өйрәтү.»;

б) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Референдум уздырганда файдаланыла торган бюллетеньнәр, махсус билгеләр (маркалар) сатып алулар «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

в) 10 пунктта «товарлар кайтаруга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру» сүзләрен «товар, эш яисә хезмәт күрсәтү сатып алу» сүзләренә алмаштырырга;

12) 47 статьяның 7 пунктында «Тавыш бирү бинасында» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 21 статьясындагы 9 пунктының «б» пунктчасы нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе раслый торган технологик җайланмалар нормативлары буенча үтә күренмәле яисә ярым үтә күренмәле материалдан ясалган» сүзләрен өстәргә;

13) 48 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

14) 49 статьяның 9 пунктындагы беренче җөмләсендә «тавыш бирергә» сүзләреннән соң «(шул исәптән вакытыннан алда тавыш бирергә)» сүзләрен өстәргә;

15) 50 статьяда:

а) 2 пунктта «10 көннән дә соңга калмыйча» сүзләреннән соң «, ә вакытыннан алда һәм кабат сайлаулар үткәргәндә — тавыш бирү көненә кадәр биш көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

б) 5 пунктта «әгәр референдумда катнашучы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш бирсә, — шулай ук

бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы да күрсәтелә» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 6 пунктның дүртенче җөмләсен төшереп калдырырга;

16) түбәндәге эчтәлекле 50[1] статья өстәргә:

«50[1] статья. **Вакытыннан алда тавыш бирү**

1. Референдум уздырганда тавыш бирү көнендә нигезле сәбәп (отпуск, командировка, хезмәт һәм уку эшчәнлеге режимы, дәүләт һәм иҗтимагый вазыйфалар үтәү, сәламәтлеге торышы һәм башка нигезле сәбәпләр) аркасында үзенең яшәү урынында була алмаган һәм үзе референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдум участогында тавыш бирү бинасына килә алмаган референдумда катнашучыга вакытыннан алда тавыш бирү мөмкинлеге бирелергә тиеш. Вакытыннан алда тавыш бирү референдумда катнашучы тарафыннан территория комиссиясе (тавыш бирү көненә кадәр 10 — 4 көн кала) яисә участок комиссиясе бинасында (тавыш бирү көненә кадәр 3 көннән дә иртәрәк түгел) бюллетень тутыру юлы белән үткәрелә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда, Татарстан Республикасы референдумында, җирле үзидарә органнарына сайлауларда, җирле референдумда тавыш бирү көне законда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары белән тавыш бирү каралган башка сайлауларда, референдумда тавыш бирү көне белән берләштерелгән очракта, референдумда катнашучы бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирә торган комиссия бинасында вакытыннан алда (әмма тавыш бирү көненә кадәр 10 көннән дә иртәрәк түгел) тавыш бирә ала.

3. Вакытыннан алда тавыш бирү үткәрелә торган биналар әлеге Законның 47 статьясындагы 2 пункты нигезендә җиһазландырылган һәм тәэмин ителгән булырга тиеш. Вакытыннан алда тавыш бирү биналарын җиһазландырганда, вакытыннан алда тавыш бирүне уздырганда тиешле комиссиянең барлык әгъзаларының, күзәтүчеләрнең, әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затларның булу мөмкинлеге күздә тотылырга тиеш. Вакытыннан алда тавыш бирү эш көннәрендә кичен (җирле вакыт буенча 16 сәгатьтән соң) һәм ял көннәрендә кимендә дүрт сәгать уздырыла. Вакытыннан алда тавыш бирүне уздыру комиссияләренең эш графигы Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе яисә аның йөкләмәсе белән түбәнгерәк комиссияләр тарафыннан билгеләнә, тиешле комиссиянең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында (булган очракта) урнаштырыла, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылырга яисә башка алым белән



халыкка игълан ителергә тиеш. Вакытыннан алда тавыш бирү әлеге Законның 50 статьясында каралган таләпләрне үтәп, әлеге статьяда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып уздырыла. Вакытыннан алда тавыш бирүне оештыру тавыш бирү серен тәэмин итәргә, референдумда катнашучының ихтыяр белдерүен бозып күрсәтү ихтималын калдырмаска, бюллетеньнең саклануын һәм тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә референдумда катнашучының тавышын исәпкә алуны тәэмин итәргә тиеш.

4. Территория комиссиясе вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучыларның исемлеген һәрбер референдум участогы буенча аерым төзи.

5. Вакытыннан алда тавыш бирә торган референдумда катнашучы тиешле комиссиягә, вакытыннан алда тавыш бирү сәбәбен күрсәтеп, гариза бирә. Гаризада референдумда катнашучының фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, аның яшәү урыны адресы күрсәтелгән булырга тиеш. Тиешле комиссия әгъзасы референдумда катнашучының гаризасында бу референдумда катнашучының вакытыннан алда тавыш бирүенең датасын һәм вакытын язып куя. Гариза вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучылар исемлегенә (ә участок комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш биргән очракта — референдумда катнашучылар исемлегенә) теркәп куела.

6. Референдумда катнашучы территория комиссиясе бинасында тавыш бирсә, аңа бирелә торган бюллетеньнең алгы ягында өске уң почмакта территория комиссиясенең ике әгъзасының имзалары куела, алар комиссия мөһере белән таныклана. Референдумда катнашучы бюллетень алганда, вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучылар исемлегендә аның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, туган елы (18 яшьтә булса — өстәмә рәвештә туган көне һәм ае), яшәү урыны адресы күрсәтелә, шуннан соң референдумда катнашучы исемлектә үзенең паспортының яисә граждан паспортын алыштыра торган документының сериясен һәм номерын язып куя. Референдумда катнашучы ризалыгы белән яисә аның үтенече буенча ул күрсәткән паспортның яисә граждан паспортын алыштыра торган документның сериясе һәм номеры комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы тарафыннан язып куелырга мөмкин. Референдумда катнашучы язманың дөреслеген тикшерә һәм бюллетень алу турында тиешле графада кул куя. Референдумда катнашучыга бюллетень (бюллетеньнәр) биргән комиссия әгъзасы шулай ук вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучылар исемлегенең тиешле графасына имза сала.

7. Вакытыннан алда тавыш бирүне уздыру өчен үтә күренмәле булмаган махсус конвертлар кулланыла. Вакытын-

нан алда тавыш биргән референдумда катнашучы тотырган бюллетень яшерен тавыш бирү бинасыннан читтә референдумда катнашучы тарафыннан ябыштырып куела торган конвертка салына. Конвертның ябыштырылган урынында тиешенчә территория комиссиясенең яисә участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия ике әгъзасы, шулай ук комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары, күзәтүчеләр (теләк буенча) имза сала. Күрсәтелгән имзалар тиешле комиссия мөһере белән таныклана.

8. Бюллетеньнәр салынган мөһерләнгән конверт тиешле комиссиянең секретаренда саклана: территория комиссиясе бинасында — бюллетеньнәр салынган конвертлар участок комиссиясенә тапшырылган мизгелгә кадәр, участок комиссиясе бинасында — тавыш бирү көненә кадәр.

9. Территория комиссиясе референдумда катнашучыларның вакытыннан алда тавыш бирү турындагы теркәп куелган гаризалары белән бергә вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучыларның тиешле исемлеген, вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучыларның бюллетеньнәре салынган конвертларны тавыш бирү көненә кадәрге көннән дә соңга калмыйча түбәнгерәк һәр участок комиссиясенә тапшыра.

10. Вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучыларның исемлеген алганнан соң ук референдумда катнашучылар исемлегендә территория комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучыларның фамилиясе каршына участок комиссиясе тарафыннан «Вакытыннан алда тавыш бирде» дигән тамга куела. Референдумда катнашучыларның вакытыннан алда тавыш бирү турындагы теркәп куелган гаризалары белән бергә вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучылар исемлеге референдумда катнашучылар исемлегенә теркәп куела. Референдумда катнашучы участок комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш бирсә, «Вакытыннан алда тавыш бирде» дигән тамга, бюллетень биргәндә, референдумда катнашучылар исемлегенә куела.

11. Вакытыннан алда, шул исәптән территория комиссиясе бинасында, тавыш биргән референдумда катнашучылар саны турында мәгълүмат тавыш бирү көненә кадәр һәр референдум участогы буенча аерым-аерым участок комиссиясе, территория комиссиясе тарафыннан турыдан-туры югарырак сайлау комиссиясенә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан — Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә һәм срокларда тапшырыла.



12. Участок комиссиясе рәисе тавыш бирү көнендә тавыш бирү башланыр алдыннан, әмма тавышларны санауның техник чараларын әзерләгәч һәм аларны тавыш бирү режимына күчергәннән соң (алардан файдаланган очракта), участок комиссиясе әгъзалары, күзәтүчеләр, әлеге Законның 22 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән башка затлар булганда, әлеге референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән вакытыннан алда, шул исәптән территория комиссиясе бинасында, тавыш биргән референдумда катнашучылар саны турында хәбәр итә, күреп танышу өчен бюллетеньнәр салынган мөһерләнгән конвертларны күрсәтә. Шуннан соң участок комиссиясе рәисе бер-бер артлы һәр конвертны ача.

13. Вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучыларның саны референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучылар санының бер процентыннан артып китсә (ләкин кимендә ун референдумда катнашучы), вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучыларның конвертларыннан чыгарылган бюллетеньнәрнең арткы ягына бюллетеньнәр конвертлардан чыгарылганнан соң ук участок комиссиясе мөһере сугыла.

14. Әлеге статьяның 12 һәм 13 пунктларында күрсәтелгән гамәлләрне башкарганнан соң участок комиссиясе рәисе, референдумда катнашучыларның ихтыяр белдерү серен саклап, бюллетеньнәрне тавыш бирү өчен стационар әрҗәгә йә тавышларны санауның техник чарасына (ул кулланылган очракта) сала. Конвертта әлеге статьяның 7 пунктында каралган реквизитлар булмаса йә конверттан референдумның тиешле соравы буенча референдумда тавыш бирү өчен билгеләнгән рәвештәге бердән артык бюллетень алынган булса, бу конверттан чыгарылган референдум соравы язылган барлык бюллетеньнәр дә гамәлгә яраксыз дип таныла, бу хакта акт төзелә. Әлеге һәрбер бюллетеньнең алгы ягына, «Әйе» һәм «Юк» («Хуплыйм» һәм «Каршы») позицияләреннән уң якта урнашкан квадратларга, бюллетеньне гамәлгә яраксыз дип тану сәбәбе языла, ул участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия ике әгъзасының имзасы белән раслана һәм участок комиссиясе мөһере белән таныклана.»;

17) 51 статьяның 8 пунктында «тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү өчен тиешле санда күчерелмә әрҗәләр» сүзләрен «тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүләрне оештыру өчен «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 21 статьясындагы 9 пунктының «б»

пунктчасы нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе раслый торган технологик җайланмалар нормативлары буенча үтә күренмәле яисә ярым үтә күренмәле материалдан ясалган тавыш бирү өчен тиешле санда күчерелмә әрҗәләр» сүзләренә алмаштырырга;

18) 52 статьяның 2 пунктындагы «д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) түбәндәге тәртиптә беркетмә юллары:

1 юл: тавыш бирү тәмамланган мизгелгә исемлеккә кертелгән референдумда катнашучылар саны;

2 юл: участок комиссиясе тарафыннан алынган бюллетеньнәр саны;

3 юл: алдан тавыш биргән референдумда катнашучыларга, шул исәптән 4 юлда аерым – территория комиссиясе (муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе) бинасында, бирелгән бюллетеньнәр саны;

5 юл: тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

6 юл: тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

7 юл: юкка чыгарылган бюллетеньнәр саны;

8 юл: тавыш бирү өчен күчерелмә әрҗәләрдәге бюллетеньнәр саны;

9 юл: тавыш бирү өчен стационар әрҗәләрдәге бюллетеньнәр саны;

10 юл: гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр саны;

11 юл: гамәлгә яраклы бюллетеньнәр саны;

12 юл: юкка чыккан бюллетеньнәр саны;

13 юл: алганда исәпкә алынмаган бюллетеньнәр саны;

14 юл һәм аннан соңгы юллар: бюллетеньнәрдәге «Әйе» һәм «Юк» («Хуплыйм» һәм «Каршы») позицияләре буенча референдумда катнашучылар тавышлары саны;»;

19) 53 статьяда:

а) 3 пунктта «5 юлына» сүзләрен «7 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктның беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Участок комиссиясе рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре участок комиссиясе тарафыннан алынган бюллетеньнәр санын төгәлләштерә, игълан итә һәм аны тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 2 юлына кертә (территория комиссиясе (муниципаль берәмлекнең



сайлау комиссиясе, округ сайлау комиссиясе) бинасында вакытыннан алда тавыш биргәннәр конвертларыннан алынган бюллетеньнәр турында күрсәткечләр күрсәтелгән санга керми).»;

в) 5 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) тавыш бирү тәмамланган мизгелгә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучылар санын (нинди дер сәбәпләр белән киткән референдумда катнашучылар санын исәпкә алмыйча);»;

түбәндәге эчтәлекле «в[1]» пунктчасы өстәргә:

«в[1]) алдан тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны (референдумда катнашучылар исемлегендә тиешле билгеләр саны буенча билгеләнә; территория комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучылар саны алдан тавыш биргән референдумда катнашучылар исемлеге буенча тикшерелә).»;

«г», «д», «е» пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

г) 6 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле «а[1]» пунктчасы өстәргә:

«а[1]) 3 һәм 4 юлларга – вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны»;

«б» пунктчасында «3 юлга» сүзләрен «5 юлга» сүзләренә алмаштырырга;

«в» пунктчасында «4 юлга» сүзләрен «6 юлга» сүзләренә алмаштырырга;

«г», «д», «е», «ж», «з» пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

унынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

д) 12 пунктта «6 юлына» сүзләрен «8 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

е) түбәндәге эчтәлекле 14[1] пункт өстәргә:

«14[1]. Территория комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучылар саны (вакытыннан алда тавыш бирүне территория комиссиясе һәм участок комиссиясе биналарында уздырганда күрсәтелгән комиссияләр биналарында вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучылар саны) референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучылар саныннан бер проценттан артыгын (әмма референдумда кимендә ун катнашучы) тәшкил итсә, участок комиссиясе комиссиянең теләсә кайсы әгъзасы, күзәтүче таләбе буенча әлеге Законның 50[1] статьясындагы 13 пункты нигезендә арткы ягында участок комиссиясе мөһере куелган бюллетеньнәр буенча та-

вышларны аерым санарга тиеш. Күрсәтелгән санау нәтиҗәләре буенча участок комиссиясе акт төзи, ул тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәгә кушылып бирелә.»;

ж) 15 пунктның җиденче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Гамәлгә яраксыз бюллетеньнәрнең гомуми саны (әлеге статьяның 12 пункты һәм әлеге Законның 50[1] статьясындагы 14 пункты нигезендә гамәлгә яраксыз дип танылган бюллетеньнәр санын исәпкә алып) тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәнең һәм аның киңәйтелгән рәвешенең 10 юлына язып куела.»;

з) 16 пунктта «10 юлына» сүзләрен «14 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

и) 17 пунктта «9 юлына» сүзләрен «11 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

к) 18 пунктта «7 юлына» сүзләрен «9 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

л) 20 пунктта «9д һәм 9е юлларына» сүзләрен «12 һәм 13 юлларына» сүзләренә алмаштырырга, «9д һәм 9е юлларында» сүзләрен «12 һәм 13 юлларында» сүзләренә алмаштырырга;

м) 21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. Санау тәмамланганнан соң бюллетеньнәр референдумда катнашучыларның референдум соравын хуплап яисә референдум соравына каршы бирелгән тавышлар буенча аерым төргәкләргә төреп куела. Әгәр бюллетеньгә берничә референдум соравы кертелсә, төргәкләргә бүлгәндә болай сортировкалау гамәлгә ашырылмый. Аерым төргәкләргә гамәлгә яраксыз һәм бозылган бюллетеньнәр төреп куела. Һәр төргәктә андагы бюллетеньнәр саны күрсәтелә һәм төргәкләнгән бюллетеньнәр эчтәлегенә туры килә торган тамга куела. Шул рәвешле җыеп куелган бюллетеньнәр, шулай ук әлеге статьяның 12 һәм 13 пунктлары нигезендә төргәкләнгән бюллетеньнәр, референдумда катнашучылар исемлеге капчыкларга яисә тартмаларга тутырыла, аларда референдум участогы номеры, барлык төргәкләнгән бюллетеньнәр саны күрсәтелә. Капчыкларга яисә тартмаларга мөһер сугыла, һәм алар бары тик югарырак комиссия яисә суд карары буенча гына ачылырга мөмкин. Күрсәтелгән капчыкларга яисә тартмаларга участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары да, шулай ук киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары да үз имзаларын куярга хокуклы. Капчыкларны яисә тартмаларны тутыру әлеге Законның 22 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән затлар барында гамәлгә ашырыла һәм аларга капчыкларга яисә тартмаларга үз имзаларын кую мөмкинлеге бирелә.»;

н) 22 пунктта:



«в» пунктчасында «1, 2, 3, 4, 5 һәм 9а, 9б, 9в, 9г, 9г — 1, 9г — 2 юлларына» сүзләрен «1, 2, 3, 4, 5, 6, 7 юлларына» сүзләренә алмаштырырга;

«г» пунктчасында «6, 7, 8, 9, 10 юлларына һәм аннан соңгы юлларына» сүзләрен «8, 9, 10, 11, 14 юлларына һәм аннан соңгы юлларына» сүзләренә алмаштырырга;

«д» пунктчасында «9д һәм 9е юлларына» сүзләрен «12 һәм 13 юлларына» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле «е» пунктчасы өстәргә:

«е) әлеге статьяның 14[1] пунктында каралган очракта участок комиссиясе, референдумда вакытыннан алда тавыш биргән катнашучыларның конвертларыннан алынган һәм арткы ягында участок комиссиясе мөһере куелган бюллетеньнәрне аерып, бюллетеньнәрне сортировкалауны гамәлгә ашыра. Күрсәтелгән бюллетеньнәр буенча тавышларны аерым санау кулдан яисә тавышларны санауның техник чарасын кулланып башкарыла. Күрсәтелгән санау нәтиҗәләре буенча участок комиссиясе акт төзи, ул тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кушылып бирелә.»;

о) 23 пунктта «8, 9, 10 һәм аннан соңгы юллары» сүзләрен «10, 11, 14 һәм аннан соңгы юллары» сүзләренә алмаштырырга;

п) 30 пунктта:

өченче абзацта «8, 9, 10 һәм аннан соңгы юлларында» сүзләрен «10, 11, 14 һәм аннан соңгы юлларында» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «8, 9, 10 һәм аннан соңгы юлларына» сүзләрен «10, 11, 14 һәм аннан соңгы юлларына» сүзләренә алмаштырырга;

р) 35 пунктта:

«1 — 9, 9а — 9е юлларында» сүзләрен «1 — 13 юлларында» сүзләренә алмаштырырга;

«1 — 9, 9а — 9е юлларына» сүзләрен «1 — 13 юлларына» сүзләренә алмаштырырга;

«10 юлына» сүзләрен «14 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

20) 54 статьяда:

а) 3 пунктның бишенче җөмләсен төшереп калдырырга;

б) 8 пунктта «1 — 9, 9а — 9е юлларына» сүзләрен «1 — 13 юлларына» сүзләренә алмаштырырга, «10 юлына» сүзләрен «14 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

21) 55 статьяда:

а) 1 өлешнең бишенче һәм алтынчы абзацларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

б) 4 өлештә «, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

22) 2 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 кушымта

ТАВЫШ БИРҮ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ БЕРКЕТМӘГӘ КЕРТЕЛГӘН КҮРСӘТКЕЧЛӘРНЕҢ КОНТРОЛЬ НИСБӘТЕ
(САННАР БЕЛӘН БЕРКЕТМӘНЕҢ ӘЛЕГЕ ЗАКОННЫҢ 52 СТАТЬЯСЫ НИГЕЗЕНДӘ НОМЕР СУГЫЛГАН ЮЛЛАРЫ БИЛГЕЛӘНДЕ)

| | |
|---|---|
| 1 күбрәк яисә тигез | 3 + 5 + 6 |
| 2 тигез | 3 + 5 + 6 + 7 + 12 – 13 |
| 8 + 9 тигез | 10 + 11 |
| 11 тигез | 14 + беркетмәнең аннан соңгы бөтен юллары». |

**3 статья**

«Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (II өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (II өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8, № 12; 2013, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяда:
а) 4 пунктта «уку урыннарында,» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 7 пунктта «өстәмә рәвештә туган көнен» сүзләрен «өстәмә рәвештә туган числосын» сүзләренә алмаштырырга;
в) $8^1$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«$8^1$. Референдумда катнашучыларның референдум уздыру инициативасын хуплаган имзалары куелган имза кәгазенең һәркайсы референдум уздыру буенча инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле тарафыннан таныкланырга тиеш. Имза кәгазен таныклаганда, референдум уздыру буенча инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле үз фамилиясе, исеме һәм атасының исеме каршына үз кулы белән имза куя һәм аны куюю датасын күрсәтә.»;
г) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«9. Имзалар җыюны тәгәлләгәннән соң, референдум уздыру буенча инициатив төркемнең вәкаләтле вәкилләре референдумда катнашучыларның җыелган имзаларының гомуми санын



исәплиләр һәм муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән форма буенча имзаларны җыю йомгаклары турында беркетмә төзиләр. Беркетмәгә референдум уздыру буенча инициатив төркемнең тиешле вәкаләтле вәкиле имза куя.»;

2) 15 статьяда:
а) 1 пунктта «ике нөсхәдә» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 3 пунктта түбәндәге эчтәлекле бишенче җөмлә өстәргә:
«Тикшерүгә җәлеп ителүче экспертлар эшләү чорына төп эш урынынннан азат ителәләр, аларның эш урыны (вазыйфасы), билгеләнгән вазыйфаи эш хакы һәм эш урыны буенча башка түләүләр саклана.»;
в) 5 пунктта «референдумны уздыру инициаторлары» сүзләрен «имза кәгазьләрен таныклаучы затлар» сүзләренә алмаштырырга;
г) 7 пунктта «имзаларның дөреслеген тикшерү эшенә җәлеп ителгән» сүзләрен «тикшерүгә җәлеп ителгән» сүзләренә алмаштырырга;
д) 8 пунктта:
«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«в) имза кәгазендә дөреслеккә туры килмәгән белешмәләр күрсәткән референдумда катнашучылар имзалары. Бу очракта имза Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны буенча һәм яшәү урыны буенча теркәү белән шөгыльләнүче органның рәсми белешмәсе булганда гына йә әлеге статьяның 3 пункты нигезендә тикшерүгә җәлеп ителгән эксперт бәяләмәсе нигезендә гамәлгә яраксыз дип таныла;»;
«е» пунктчасында «референдумда катнашучыларның имзаларын тикшерү эшенә җәлеп ителгән» сүзләрен «тикшерүгә җәлеп ителгән» сүзләренә алмаштырырга;
«ж» пунктчасында «аларга» сүзләрен «бу имзаларга» сүзләренә алмаштырырга;
«з» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«з) референдумда катнашучыларның имза кәгазендәге барлык имзалары, әгәр имза кәгазе референдумда катнашучылар имзаларын җыйган затның һәм (яисә) референдум уздыру буенча инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиленең үз куллары белән куелган имзалары белән таныкланмаган булса, йә бу имзаларның берәрсе генә дөрес булмаса, йә имза кәгазе имзалар җыю вакытына 18 яшькә җитмәгән, референдумда катнашучылар имзаларын җыйган зат тарафыннан таныкланган булса һәм (яисә) әлеге зат суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип танылган булса, йә имза кәгазен таныклау даталарының берәрсе генә булса да күрсәтелмәгән яисә кулдан кертелмәгән булса, йә ре-

ферендумда катнашучылар имзаларын җыйган зат турындагы белешмәләрдә һәм (яисә) шушы зат, референдум уздыру буенча инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле тарафыннан имза кую датасында референдумда катнашучылар имзаларын җыйган зат, референдум уздыру буенча инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле белән махсус килештерелмәгән төзәтүләр булса, йә референдумда катнашучылар имзаларын җыйган зат, референдум уздыру буенча инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле турындагы белешмәләр имза кәгазендә тулы күләмдә күрсәтелмәгән булса яисә дөреслеккә туры килмәсә, йә референдумда катнашучылар имзаларын җыйган зат турындагы белешмәләр аның үз кулы белән кертелмәгән йә кулдан язылмаган яисә карандаш белән язылган булса;»;

«л» пунктчасында «референдумда катнашучылар имзаларын тикшерү эшенә әлеге статьяның 3 пункты нигезендә җәлеп ителгән» сүзләрен «әлеге статьяның 3 пункты нигезендә тикшерүгә җәлеп ителгән» сүзләренә алмаштырырга;

е) 10 пунктта «санала» сүзен «танылә» сүзенә алмаштырырга;

16 статьяда 2 пунктта:

а) түбәндәге эчтәлекле «б[1]» пунктчасы өстәргә:

«б[1]) референдум билгеләү өчен референдумда катнашучыларның 200 һәм аннан артык имзаларын тапшыру таләп ителсә, — тикшерү өчен сайлап алынган имзаларның гомуми саныннан 10 һәм аннан артык процент дөрес булмаган һәм (яисә) яраксыз имзаларны ачыклау, әгәр федераль закон белән башкасы билгеләнмәгән булса;»;

б) «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) референдумда катнашучыларның референдум билгеләү өчен тапшырылган дөрес имзаларының саны җитәрлек булмавы;»;

3) 20 статьяның «ж» пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

4) 21 статьяда:

а) «е» пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

б) «ж» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ж) референдум участогында тавыш бирү көнендә тавыш бирүне, шулай ук вакытыннан алда тавыш бирүне оештыра;»;

5) 24 статьяда:



а) 1 пунктта «референдумда тавыш бирү өчен бүтән референдум участогында тавыш бирү таныклыклары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 пунктта «Тавыш бирү көнендә» сүзләреннән соң «, шулай ук вакытыннан алда тавыш бирү көннәрендә» сүзләрен өстәргә;

в) 6 пунктта «башка референдум комиссияләрендә» сүзләреннән соң «алар вакытыннан алда тавыш бирүне уздырганда» сүзләрен өстәргә;

г) 8 пунктның беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге статьяның 7 пунктында күрсәтелгән документ участок комиссиясенә әлеге статьяның 3 пунктында күрсәтелгән чорда, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә референдум участокларында вакытыннан алда тавыш бирү чорында йә тавыш бирү башланган чордан алып тиешле территориядә йомгаклау беркетмәсе төзү эше тәмамланганчы бирелергә мөмкин.»;

д) 9 пунктта:

«а» пунктчасында «бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестры, референдум комиссиясендәге бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

«б» пунктчасында «тавыш бирү көнендә» сүзләреннән соң «, шулай ук вакытыннан алда тавыш бирү көннәрендә» сүзләрен өстәргә;

е) 11 пунктның «г» пунктчасында «тавыш бирү көнендә» сүзләреннән соң «, вакытыннан алда тавыш бирү көннәрендә» сүзләрен өстәргә;

6) 27 статьяда:

а) 4 пунктта «йә гражданның референдумда тавыш бирү өчен бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы булуы» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 16 пунктта:

бишенче җөмләдә «, шулай ук референдумда катнашучыга референдумда тавыш бирү өчен бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән очракта» сүзләрен төшереп калдырырга;

җиденче җөмләдә «ә референдумда тавыш бирү өчен бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгәндә, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын биргән комиссия әгъзасы имзасы белән таныклана,» сүзләрен төшереп калдырырга;

8) 28 статьяның 2 пунктында «тавыш бирү көненә кадәр 45 көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен «тавыш бирү көненә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

9) 39 статьяның 1 пунктында «яисә Татарстан Республикасы Сайлау кодексының $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган булса,» сүзләрен төшереп калдырырга;

10) 45 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$. Җирле бюджет акчалары исәбеннән референдум комиссияләренең түбәндәге чыгымнары финанслана:

1) референдум комиссияләренең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларына, референдум комиссияләре аппаратлары хезмәткәрләренә хезмәт өчен өстәмә түләү (бүләкләү), референдум комиссияләренең референдум әзерләү һәм уздыру чорына төп эшеннән азат ителгән хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия әгъзаларына компенсацияләр түләү, шулай ук референдум комиссияләрендә граждан-хокукый шартнамәләр буенча эшләүче гражданнарга һәм референдум комиссияләре каршындагы контроль-ревизия хезмәтләре составында эшләү өчен җибәрелә торган белгечләргә түләүләр;

2) матбугат продукциясен әзерләү һәм нәшрият эшчәнлеген гамәлгә ашыру чыгымнары;

3) референдум әзерләү һәм уздыру, референдум комиссияләренең эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле җиһаз (шул исәптән технологик), башка матди кыйммәтләр сатып алу, китерү һәм урнаштыру;

4) транспорт чыгымнары;

5) референдум әзерләүгә һәм уздыруга бәйле документларны китерү һәм саклау, аларны архивка тапшыруга яисә юкка чыгару өчен әзерләү;

6) референдум әзерләүгә һәм уздыруга, шулай ук референдум комиссияләренең эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле командировкалар һәм башка максатлар;

7) автоматлаштыру чараларыннан файдалану һәм аларны эксплуатацияләү, референдумда катнашучыларның хокукый культурасын арттыру һәм референдумны оештыручыларны укыту.»;

б) 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Референдум уздырганда файдаланыла торган бюллетеньнәр, махсус билгеләр (маркалар) сатып алу «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;



в) 11 пунктта «товарлар кайтаруга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру» сүзләрен «товарны, эшне яисә хезмәт күрсәтүне сатып алу» сүзләренә алмаштырырга;

11) 49 статьяның 7 пунктында «Тавыш бирү бинасында» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 21 статьясындагы 9 пунктның «б» пунктчасы нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе раслый торган технологик җиһазның нормативлары нигезендә үтә күренмәле яисә ярым үтә күренмәле материалдан ясалган» сүзләрен өстәргә;

12) 50 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

13) 51 статьяның 8 пунктындагы өченче җөмләсендә «тавыш бирергә» сүзләреннән соң «(шул исәптән алдан тавыш бирергә)» сүзләрен өстәргә;

14) 52 статьяда:

а) 2 пунктта «итәргә тиеш, ә» сүзләреннән соң «вакытыннан алда тавыш бирү һәм» сүзләрен өстәргә;

б) 5 пунктта «, әгәр референдумда катнашучы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш бирсә, — бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын күрсәткәч» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 6 пунктның дүртенче җөмләсен төшереп калдырырга;

15) түбәндәге эчтәлекле $52^1$ статья өстәргә:

«$52^1$ статья. **Вакытыннан алда тавыш бирү**

1. Референдум уздырганда тавыш бирү көнендә нигезле сәбәп (отпуск, командировка, хезмәт һәм уку эшчәнлеге режимы, дәүләт һәм иҗтимагый вазыйфалар үтәү, сәламәтлеге торышы һәм башка нигезле сәбәпләр) аркасында үзенең тору урынында була алмаган һәм референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдум участогындагы тавыш бирү бинасына килә алмаган референдумда катнашучыга вакытыннан алда тавыш бирү мөмкинлеге бирелергә тиеш. Вакытыннан алда тавыш бирү референдумда катнашучы тарафыннан муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе (тавыш бирү көненә кадәр 10 — 4 көн кала) яисә участок комиссиясе бинасында (тавыш

бирү көненә кадәр өч көннән дә иртәрәк түгел) бюллетень тутыру юлы белән үткәрелә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда, Татарстан Республикасы референдумында, җирле үзидарә органнарына сайлауларда, җирле референдумда тавыш бирү көне белән башка сайлауларда, референдумда тавыш бирү көне берләштерелгән очракта, әгәр тавыш бирү закон белән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча башкарылса, референдумда катнашучы бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирә торган комиссия бинасында вакытыннан алда (әмма тавыш бирү көненә кадәр 10 көннән дә иртәрәк түгел) тавыш бирә ала.

3. Вакытыннан алда тавыш бирү башкарыла торган биналар әлеге Законның 49 статьясындагы 2 пункты нигезендә җиһазландырылган һәм тәэмин ителгән булырга тиеш. Вакытыннан алда тавыш бирү биналары җиһазы вакытыннан алда тавыш бирүне уздырганда тиешле комиссиянең барлык әгъзаларының, күзәтүчеләрнең, әлеге Законның 24 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затларның булу мөмкинлеген күздә тотарга тиеш. Вакытыннан алда тавыш бирү эш көннәрендә кичке вакытта (җирле вакыт буенча 16 сәгатьтән соң) һәм ял көннәрендә кимендә дүрт сәгать уздырыла. Вакытыннан алда тавыш бирүне уздыру өчен комиссия эше графигы Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе яисә аның йөкләмәсе белән түбәнгерәк комиссияләр тарафыннан билгеләнә, тиешле комиссиянең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында (булган очракта) урнаштырыла, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылырга яисә башка алым белән халыкка игълан ителергә тиеш. Вакытыннан алда тавыш бирү әлеге Законның 52 статьясында каралган таләпләрне үтәп, әлеге статья белән билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып уздырыла. Вакытыннан алда тавыш бирүне оештыру тавыш бирү серен тәэмин итәргә, референдумда катнашучының ихтыяр белдерүен бозып күрсәтү ихтималын калдырмаска, бюллетеньнең саклануын һәм тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә референдумда катнашучының тавышын исәпкә алуны тәэмин итәргә тиеш.

4. Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе референдумда вакытыннан алда тавыш биргән катнашучыларның исемлеген һәрбер референдум участогы буенча аерым төзи.

5. Референдумда вакытыннан алда тавыш бирүче катнашучы тиешле комиссиягә, вакытыннан алда тавыш бирү сәбәбен күрсәтеп, гариза бирә. Гаризада референдумда катнашучының фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, аның яшәү урыны адресы күрсәтелгән булырга тиеш. Тиешле комиссия әгъзасы



референдумда катнашучының гаризасында бу референдумда катнашучының вакытыннан алда тавыш бирүенең датасын һәм вакытын язып куя. Гариза референдумда вакытыннан алда тавыш биргән катнашучыларның исемлегенә (ә участок комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш биргән очракта — референдумда катнашучыларның исемлегенә) кушып бирелә.

6. Референдумда катнашучы муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе бинасында тавыш бирсә, аңа бирелә торган бюллетеньнең алгы ягында өске уң почмакта муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең ике әгъзасының имзалары куела, алар комиссия мөһере белән таныклана. Референдумда катнашучы бюллетень алганда, референдумда вакытыннан алда тавыш биргән катнашучыларның исемлегендә аның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, туган елы (18 яшьтә булса — өстәмә рәвештә туган көне һәм ае), яшәү урыны адресы күрсәтелә, шуннан соң референдумда катнашучы исемлектә үзенең паспортының яисә граждан паспортын алыштыра торган документның сериясен һәм номерын язып куя. Референдумда катнашучы ризалыгыннан яисә аның үтенече буенча ул күрсәткән паспортның яисә граждан паспортын алыштыра торган документның сериясе һәм номеры хәлиткеч тавыш хокукы булган комиссия әгъзасы тарафыннан язып куелырга мөмкин. Референдумда катнашучы язманың дөреслеген тикшерә һәм бюллетень алу турындагы тиешле графада кул куя. Референдумда катнашучыга бюллетень биргән комиссия әгъзасы шулай ук референдумда вакытыннан алда тавыш биргән катнашучылар исемлегенең тиешле графасына имза сала.

7. Вакытыннан алда тавыш бирү уздыру өчен үтә күренмәле булмаган махсус конвертлар кулланыла. Референдумда вакытыннан алда тавыш биргән катнашучы тутырган бюллетень ябыштырып куела торган конвертка яшерен тавыш бирү урыныннан читтә референдумда катнашучы тарафыннан салына. Конвертның ябыштырылган урынына тиешенчә муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең яисә участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия ике әгъзасы, шулай ук киңәш бирү тавышы хокукына ия комиссия әгъзалары, күзәтүчеләр (теләк буенча) имза сала. Күрсәтелгән имзалар тиешле комиссия мөһере белән таныклана.

8. Бюллетеньнәр салынган мөһерләнгән конверт тиешле комиссиянең секретарендә саклана: муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе бинасында — бюллетеньнәр салынган конвертлар участок комиссиясенә тапшырылган вакытка кадәр, участок комиссиясе бинасында — тавыш бирү көненә кадәр.

9. Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, тавыш бирү көненә кадәрге көннән дә соңга калмыйча, референдумда вакытыннан алда тавыш биргән катнашучыларның тиешле исемлеген, референдумда катнашучыларның вакытыннан алда тавыш бирү турындагы гаризалары белән бергә, референдумда вакытыннан алда тавыш биргән катнашучыларның бюллетеньнәре салынган конвертларны түбәнгерәк һәр участок комиссиясенә тапшыра.

10. Референдумда вакытыннан алда тавыш биргән катнашучыларның исемлеген алганнан соң ук участок комиссиясе тарафыннан катнашучылар исемлегендә муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе бинасында референдумда вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучыларның фамилиясе янына «Вакытыннан алда тавыш бирде» дигән тамга куела. Референдумда вакытыннан алда тавыш биргән катнашучылар исемлеге, референдумда катнашучыларның вакытыннан алда тавыш бирү турындагы гаризалары белән бергә, референдумда катнашучылар исемлегенә өстәп куела. Әгәр референдумда катнашучы участок комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш бирсә, «Вакытыннан алда тавыш бирде» дигән тамга референдумда катнашучылар исемлегенә бюллетень биргәндә куела.

11. Һәр референдум участогы буенча вакытыннан алда тавыш биргән, шул исәптән муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе бинасында, референдумда катнашучылар саны турында мәгълүмат тавыш бирү көненә кадәр участок комиссиясе, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан турыдан-туры югарырак сайлау комиссиясенә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә һәм срокларда тапшырыла.

12. Участок комиссиясе рәисе тавыш бирү көнендә тавыш бирү башланыр алдыннан, әмма тавышларны санауның техник чараларын әзерләгәннән һәм аларны тавыш бирү режимына күчергәннән соң (алардан файдаланган очракта) участок комиссияләре әгъзалары, күзәтүчеләр, әлеге Законның 24 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затлар булганда шул референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда вакытыннан алда тавыш биргән, шул исәптән муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе бинасында, референдумда катнашучыларның саны турында хәбәр итә, күреп танышу өчен бюллетеньнәр салынган мөһерләнгән конвертны бирә. Шуннан соң участок комиссиясе рәисе бер-бер артлы һәр конвертны ача бара.



13. Референдумда вакытыннан алда тавыш биргән катнашучыларның саны референдум участогындагы референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучылар санының бер процентыннан артып китсә (әмма референдумда кимендә ун катнашучы), референдумда вакытыннан алда тавыш биргән катнашучыларның конвертларыннан чыгарылган бюллетеньнәрнең арткы ягына бюллетеньнәр конвертлардан чыгарылганнан соң ук участок комиссиясе мөһере куела.

14. Әлеге статьяның 12 һәм 13 өлешләрендә күрсәтелгән гамәлләрне башкарганнан соң участок комиссиясе рәисе, референдумда катнашучыларның ихтыяр белдерү серен саклап, бюллетеньнәрне тавыш бирү өчен стационар әрҗәгә яисә тавышларны санауның техник чарасына (ул кулланылган очракта) сала. Әгәр конвертта әлеге статьяның 7 өлешендә каралган реквизитлар булмаса йә конверттан референдумның тиешле соравы буенча референдумда тавыш бирү өчен билгеләнгән формадагы бердән артык бюллетень алынган булса, бу конверттан чыгарылган референдумның шушы соравы булган барлык бюллетеньнәр дөрес түгел дип таныла, бу хакта акт төзелә. Әлеге һәрбер бюллетеньнең алгы ягына, «Әйе» һәм «Юк» («Хуплыйм» һәм «Каршы») язмаларыннан уң якта урнашкан шакмакларга, бюллетеньнең дөрес түгеллеген тану сәбәбе язып куела, ул участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия ике әгъзасының имзасы белән раслана һәм участок комиссиясе мөһере белән таныклана.»;

16) 53 статьяның 8 пунктында «Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү өчен тиешле сандагы күчерелмә әрҗәләр» сүзләрен «Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне оештыру өчен «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 21 статьясындагы 9 пунктның «б» пунктчасы нигезендә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе раслый торган технологик җиһазның нормативлары нигезендә үтә күренмәле яисә ярым үтә күренмәле материалдан ясалган тавыш бирү өчен тиешле сандагы күчерелмә әрҗәләр» сүзләренә алмаштырырга;

17) 54 статьяның 2 пунктындагы «д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) түбәндәге тәртиптә беркетмә юллары:

1 юл: тавыш бирү тәмамланган вакытка исемлеккә кертелгән референдумда катнашучылар саны;

2 юл: участок комиссиясе тарафыннан алынган бюллетеньнәр саны;

3 юл: вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны, шул исәптән аерым 4 юлы белән – муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе бинасында;

5 юл: тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

6 юл: тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

7 юл: юкка чыгарылган бюллетеньнәр саны;

8 юл: тавыш бирүнең күчерелмә әрҗәләрендәге бюллетеньнәр саны;

9 юл: тавыш бирүнең стационар әрҗәләрендәге бюллетеньнәр саны;

10 юл: гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр саны;

11 юл: гамәлгә яраклы бюллетеньнәр саны;

12 юл: югалган бюллетеньнәр саны;

13 юл: алганда исәпкә алынмаган бюллетеньнәр саны;

14 юл һәм аннан соңгы юллар: бюллетеньнәрдәге «Әйе» һәм «Юк» («Хуплыйм» һәм «Каршы») позицияләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары саны;»;

18) 55 статьяда:

а) 3 пунктта «5 юлына» сүзләрен «7 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктның беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Участок комиссиясе рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре участок комиссиясе тарафыннан алынган бюллетеньнәр санын төгәлләштерә, игълан итә һәм аны тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның киңәйтелгән рәвешенең 2 юлына кертә (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе бинасында референдумда вакытыннан алда тавыш биргән катнашучыларның конвертларыннан алынган бюллетеньнәр турында белешмәләр күрсәтелгән санга керми).»;

в) 5 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) тавыш бирү тәмамланган вакытка референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучылар санын (нинди дә булса сәбәпләр белән киткән референдумда катнашучылар санын исәпкә алмыйча);»;

түбәндәге эчтәлекле «в$^1$» пунктчасы өстәргә:



«в$^1$) референдумда вакытыннан алда тавыш биргән катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны (референдумда катнашучылар исемлегендәге тиешле билгеләр санына карап билгеләнә; муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе бинасында референдумда вакытыннан алда тавыш биргән катнашучылар саны референдумда вакытыннан алда тавыш биргән катнашучылар исемлеге буенча тикшерелә);»;

«г», «д», «е» пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

г) 6 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле «а$^1$» пунктчасы өстәргә:

«а$^1$) 3 һәм 4 юлларга – вакытыннан алда тавыш биргән референдумда катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;»;

«б» пунктчасында «3 юлга» сүзләрен «5 юлга» сүзләренә алмаштырырга;

«в» пунктчасында «4 юлга» сүзләрен «6 юлга» сүзләренә алмаштырырга;

«г», «д», «е», «ж», «з» пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

унынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

д) 12 пунктта «6 юлына» сүзләрен «8 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

е) түбәндәге эчтәлекле 14$^1$ пункт өстәргә:

«14$^1$. Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе бинасында референдумда вакытыннан алда тавыш биргән катнашучылар саны (вакытыннан алда тавыш бирүне муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе һәм участок комиссиясе биналарында уздырганда күрсәтелгән комиссияләр биналарында референдумда вакытыннан алда тавыш биргән катнашучылар саны) референдум участогында референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучылар саныннан бер проценттан артыгын (әмма референдумда кимендә ун катнашучы) тәшкил итсә, участок комиссиясе, комиссиянең теләсә кайсы әгъзасы, күзәтүче таләбе буенча, әлеге Законның 52$^1$ статьясындагы 13 пункты нигезендә арткы ягында участок комиссиясе мөһере куелган бюллетеньнәр буенча тавышларны аерым санарга тиеш. Күрсәтелгән санау нәтиҗәләре буенча участок комиссиясе акт төзи, ул тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кушылып бирелә.»;

ж) 15 пунктның җиденче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Гамәлгә яраксыз бюллетеньнәрнең гомуми саны (әлеге статьяның 12 пункты һәм әлеге Законның 52$^1$ статьясындагы 14 пункты нигезендә гамәлгә яраксыз дип танылган бюллетеньнәрнең санын исәпкә алып) тавыш бирү йомгаклары

турында беркетмәнең һәм аның киңәйтелгән рәвешенең 10 юлына язып куела.»;

з) 16 пунктта «10 юлына» сүзләрен «14 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

и) 17 пунктта «9 юлына» сүзләрен «11 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

к) 18 пунктта «7 юлына» сүзләрен «9 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

л) 20 пунктта «9д һәм 9е юлларына» сүзләрен «12 һәм 13 юлларына» сүзләренә алмаштырырга, «9д һәм 9е юлларында» сүзләрен «12 һәм 13 юлларында» сүзләренә алмаштырырга;

м) 21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. Санау тәмамланганнан соң бюллетеньнәр референдумда катнашучыларның референдум соравын хуплап яисә референдум соравына каршы бирелгән тавышлар буенча аерым төргәкләргә төреп куела. Әгәр бюллетеньгә берничә референдум соравы кертелсә, төргәкләргә бүлгәндә болай сортировкалау гамәлгә ашырылмый. Аерым төргәкләргә гамәлгә яраксыз һәм бозылган бюллетеньнәр төреп куела. Һәр төргәктә андагы бюллетеньнәр саны күрсәтелә һәм төргәкләнгән бюллетеньнәр эчтәлегенә туры килә торган тамга куела. Шул рәвешле җыеп куелган бюллетеньнәр, шулай ук әлеге статьяның 12 һәм 13 пунктлары нигезендә төргәкләнгән бюллетеньнәр, референдумда катнашучыларның исемлеге капчыкларга яисә тартмаларга тутырыла, аларда референдум участогы номеры, барлык төргәкләнгән бюллетеньнәр саны күрсәтелә. Капчыкларга яисә тартмаларга мөһер сугыла һәм алар бары тик югарырак комиссия яисә суд карары буенча гына ачылырга мөмкин. Күрсәтелгән капчыкларга яисә тартмаларга участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары да, шулай ук киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары да үз имзаларын куярга хокуклы. Капчыкларны яисә тартмаларны тутыру әлеге Законның 24 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән затлар барында гамәлгә ашырыла һәм аларга капчыкларга яисә тартмаларга үз имзаларын кую мөмкинлеге бирелә.»;

н) 22 пунктта:

«в» пунктчасында «1, 2, 3, 4, 5 һәм 9а, 9б, 9в, 9г, 9г – 1, 9г – 2 юлларына» сүзләрен «1, 2, 3, 4, 5, 6, 7 юлларына» сүзләренә алмаштырырга;

«г» пунктчасында «6, 7, 8, 9, 10 юлларына һәм аннан соңгы юлларына» сүзләрен «8, 9, 10, 11, 14 юлларына һәм аннан соңгы юлларына» сүзләренә алмаштырырга;

«д» пунктчасында «9д һәм 9е юлларына» сүзләрен «12 һәм 13 юлларына» сүзләренә алмаштырырга;



түбәндәге эчтәлекле «е» пунктчасы өстәргә:

«е) әлеге статьяның 14[1] пунктында каралган очракта участок комиссиясе референдумда вакытыннан алда тавыш биргән катнашучыларның конвертларыннан алынган һәм арткы ягында участок комиссиясе мөһере куелган бюллетеньнәрне аерып бюллетеньнәрне сортировкалауны гамәлгә ашыра. Күрсәтелгән бюллетеньнәр буенча тавышларны аерым санау кулдан яисә тавышларны санауның техник чарасын кулланып башкарыла. Күрсәтелгән санау нәтиҗәләре буенча участок комиссиясе акт төзи, ул тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кушылып бирелә.»;

о) 23 пунктта «8, 9, 10 һәм аннан соңгы юллары» сүзләрен «10, 11, 14 һәм аннан соңгы юллары» сүзләренә алмаштырырга;

19) 56 статьяда:

а) 6 пунктның бишенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

б) 12 пунктта «1 – 9е юлларына» сүзләрен «1 – 13 юлларына» сүзләренә алмаштырырга, «10 юлына» сүзләрен «14 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

20) 58 статьяның 1 пунктында «, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

21) 2 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 кушымта

ТАВЫШ БИРҮ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ БЕРКЕТМӘГӘ КЕРТЕЛГӘН КҮРСӘТКЕЧЛӘРНЕҢ КОНТРОЛЬ НИСБӘТЕ (САННАР БЕЛӘН БЕРКЕТМӘНЕҢ ӘЛЕГЕ ЗАКОННЫҢ 54 СТАТЬЯСЫ НИГЕЗЕНДӘ НОМЕР СУГЫЛГАН ЮЛЛАРЫ БИЛГЕЛӘНДЕ)

| | |
|---|---|
| 1 күбрәк яисә тигез | 3 + 5 + 6 |
| 2 тигез | 3 + 5 + 6 + 7 + 12 – 13 |
| 8 + 9 тигез | 10 + 11 |
| 11 тигез | 14 + беркетмәнең бөтен алдагы юллары». |

**4 статья**

«Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе турында» 2012 елның 25 декабрендәге 92-ТРЗ номерлы

Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяда:

а) 4 пунктта «уку урынында,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 7 пунктта «өстәмә рәвештә туган көнен» сүзләрен «өстәмә рәвештә туган числосын» сүзләренә алмаштырырга;

в) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын хуплаган имзалары куелган имза кәгазенең һәркайсы чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру буенча инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле тарафыннан таныкланырга тиеш. Имза кәгазен таныклаганда чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру буенча инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле үз фамилиясе, исеме һәм атасының исеме каршына үз кулы белән имза куя һәм аны кую датасын күрсәтә.»;

2) 11 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Имзалар җыюны тәгалләгәннән соң, чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру буенча инициатив төркемнең вәкаләтле вәкилләре чакыртып алуга тавыш бирүдә катнашучыларның җыелган имзаларының гомуми санын исәплиләр һәм Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән форма буенча имзаларны җыю йомгаклары турында беркетмә төзиләр. Беркетмәгә чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру буенча инициатив төркемнең тиешле вәкаләтле вәкиле имза куя.»;

б) 2 өлештә «ике нөсхәдә» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 12 статьяда:

а) 2 өлештә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Тикшерү эшенә җәлеп ителүче экспертлар эшләү чорына төп эш урыныннан азат ителәләр, аларның эш урыны (вазыйфасы), билгеләнгән вазыйфаи эш хакы һәм эш урыны буенча башка түләүләр саклана.»;

б) 7 өлештә «санала» сүзен «таныла» сүзенә алмаштырырга;

в) 8 өлештә «сайлаучылар имзаларын тикшерү буенча эшкә җәлеп ителгән» сүзләрен «тикшерүгә җәлеп ителгән» сүзләренә алмаштырырга;

г) 9 өлештә:



3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) имза кәгазендә дөреслеккә туры килмәгән белешмәләр күрсәткән сайлаучылар имзалары. Бу очракта имза Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны буенча һәм яшәү урыны буенча теркәү белән шөгыльләнүче органның рәсми белешмәсе булганда гына йә әлеге статьяның 2 пункты нигезендә тикшерүгә җәлеп ителгән эксперт бәяләмәсе нигезендә гамәлгә яраксыз дип таныла;»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) имзалар кәгазендәге имзаларның куелу датасына алдан махсус искәртмичә төзәтмәләр керткән сайлаучылар имзалары, шулай ук имзаларның куелу датасын шәхсән үзләре төзәтмәгән сайлаучыларның имзалары — әлеге статьяның 7 өлеше нигезендә тикшерүгә җәлеп ителгән экспертның язма бәяләмәсе нигезендә;»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) сайлаучылар турындагы бу имзаларга туры килә торган белешмәләргә төзәтмәләр керткән сайлаучыларның имзалары, әгәр бу төзәтмәләр сайлаучылар белән яисә имзалар җыюны гамәлгә ашыручы зат белән махсус килештерелмәгән булса;»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) сайлаучыларның имза кәгазендәге барлык имзалары, әгәр имза кәгазе сайлаучылар имзаларын җыйган затның һәм (яисә) чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру буенча инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиленең үз куллары белән куелган имзалары белән таныкланмаган булса, йә бу имзаларның берәрсе генә дөрес булмаса, йә имза кәгазе имзалар җыю вакытына 18 яшькә җитмәгән сайлаучылар имзаларын җыйган зат тарафыннан таныкланган булса һәм (яисә) әлеге зат суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип танылган булса, йә имза кәгазен таныклау даталарының берәрсе генә булса да күрсәтелмәгән яисә кулдан кертелмәгән булса, йә сайлаучылар имзаларын җыйган зат турындагы белешмәләрдә һәм (яисә) шушы зат, чакыртып алуга тавыш бирүне уздыру буенча инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле тарафыннан имза кую датасында сайлаучылар имзаларын җыйган зат, чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру буенча инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле белән махсус килештерелмәгән төзәтүләр булса, йә сайлаучылар имзаларын җыйган зат, чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру буенча инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле турындагы белешмәләр имза кәгазендә тулы күләмдә күрсәтелмәгән булса яисә дөреслеккә туры килмәсә, йә сайлаучылар имзаларын җыйган зат турындагы белешмәләр аның үз кулы белән кертелмәгән йә кулдан язылмаган яисә карандаш белән язылган булса;»;

11 пунктта «имзалар тикшерү эшенә җәлеп ителгән» сүзләрен «тикшерүгә җәлеп ителгән» сүзләренә алмаштырырга;

4) 13 статьяның 2 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле «2[1]» пунктчасы өстәргә:

«2[1]) чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү өчен сайлаучыларның 200 һәм аннан артык имзаларын тапшыру таләп ителсә, — тикшерү өчен сайлап алынган имзаларның гомуми санынннан 10 һәм аннан артык процент дөрес булмаган һәм (яисә) яраксыз имзаларны ачыклау, әгәр федераль закон белән башкасы билгеләнмәгән булса;»;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) сайлаучыларның чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү өчен тапшырылган дөрес имзаларының саны җитәрлек булмавы;»;

5) 14 статьяның 6 өлешендәге икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тавыш бирүне эш көне булмаган бәйрәм көненә, аннан алдагы көнгә, эш көне булмаган бәйрәм көненнән соң килгән көнгә һәм билгеләнгән тәртиптә эш көне дип игълан ителгән якшәмбегә билгеләү рөхсәт ителми.»;

5) 17 статьяның 1 өлешендәге өченче абзацында «, шәһәрләрдәге район» сүзләрен «һәм башкалар» сүзләренә алмаштырырга;

6) 18 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 статья. **Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе вәкаләтләре**

Чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләгәндә һәм уздырганда Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе:

1) Татарстан Республикасы территориясендә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашуга гражданнар хокукы үтәлешен тикшереп тора;

2) әлеге Законны куллану мәсьәләләре буенча инструкцияләр һәм башка норматив актлар чыгара;

3) чакыртып алу буенча түбәнгерәк комиссияләрнең эшчәнлегенә җитәкчелек итә, аларга хокукый, методик, оештыру-техник ярдәм күрсәтә;

4) инициатив төркемне, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемнәрен терки;



5) чакыртып алу буенча тавыш бирү өчен бюллетень рәвешен һәм текстын, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның исемлегенең һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүгә һәм уздыруга бәйле башка документларның рәвешен раслый;

6) чакыртып алу буенча түбәнгерәк комиссияләрнең мөһерләре үрнәкләрен раслый;

7) чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны, чакыртып алу комиссияләренең эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелгән чараларны бүлә, әлеге чараларны максатчан файдалануны тикшереп тора;

8) чакыртып алу буенча түбәнгерәк комиссияләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләрне (гаризаларны) карый һәм әлеге шикаятьләр (гаризалар) буенча дәлилләнгән карарлар кабул итә;

9) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны мондый тавыш бирүне әзерләү һәм уздыру турындагы мәгълүмат белән тәэмин итә;

10) чакыртып алу комиссияләрен биналар, транспорт чаралары һәм элемтә чаралары белән тәэмин итүне тикшереп тора, чакыртып алу буенча тавыш бирүне матди-техник тәэмин итүнең бүтән мәсьәләләрен карый;

11) чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүгә һәм уздыруга бәйле мәсьәләләр буенча дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итә;

12) федераль законнарда, әлеге Законда, Татарстан Республикасының башка законнарында билгеләнгән бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

8) 19 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19 статья. **Территория комиссияләре вәкаләтләре**

Территория комиссиясе:

1) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашуга гражданнар хокукы үтәлүне тиешле территориядә тикшереп тора;

2) участок комиссияләре эшчәнлеген җайга сала, аларга хокукый, методик, оештыру-техник ярдәм күрсәтә;

3) участок комиссияләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләрне (гаризаларны) карый һәм әлеге шикаятьләр (гаризалар) буенча дәлилләнгән карарлар кабул итә;

4) чакыртып алу буенча агитация уздыруның билгеләнгән тәртибе саклануны тиешле территориядә тикшереп тора;

5) чакыртып алу буенча тавыш бирү бюллетеньнәрен һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүгә һәм уздыруга бәйле башка документларны илтеп җиткерүне оештыра;

6) чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүгә һәм уздыруга бәйле мәсьәләләр буенча дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итә;

7) федераль законнарда, әлеге Законда, Татарстан Республикасының башка законнарында билгеләнгән бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

9) 20 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20 статья. **Участок комиссияләре вәкаләтләре**

Участок комиссиясе:

1) халыкка участок комиссиясенең адресы һәм телефон номеры, аның эш вакыты, шулай ук тавыш бирү көне, вакыты һәм урыны турында хәбәр итә;

2) тавыш бирүдә катнашучылар исемлеген төгәлләштерә, тавыш бирүдә катнашучыларны әлеге исемлек белән таныштыра, әлеге исемлектәге хаталар һәм төгәлсезлекләр турындагы гаризаларны карый һәм аңа тиешле үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләләрне хәл итә;

3) тавыш бирү биналарын, тавыш бирү әрҗәләрен һәм башка җайланмаларны әзерләүне тәэмин итә;

4) тавыш бирүдә катнашучыларга тавыш бирү турында мәгълүмат җиткерүне тәэмин итә;

5) участок территориясендә чакыртып алу буенча агитация уздыруның билгеләнгән тәртибе саклануны тикшереп тора;

6) тавыш бирү көнендә участокта тавыш бирүне оештыра;

7) тавышларны саный, участокта тавыш бирү йомгакларын билгели, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи һәм аны территория комиссиясенә тапшыра;

8) участокта тавыш бирү йомгакларын игълан итә һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең таныкланган күчермәләрен тавыш бирүнең барышын күзәтүче затларга бирә;

9) әлеге Законны, башка законнарны бозуга карата шикаятьләрне (гаризаларны) үз вәкаләтләре чикләрендә карый һәм әлеге шикаятьләр (гаризалар) буенча дәлилләнгән карарлар кабул итә;

10) чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүгә һәм уздыруга бәйле документларны саклауны һәм чакыртып алу буенча югарырак комиссияләргә тапшыруны тәэмин итә;



11) әлеге Закон нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

10) 22 статьяда:

а) 1 өлештә «бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 өлештә «тавыш бирү көнендә» сүзләреннән соң «, шулай ук вакытыннан алда тавыш бирү көннәрендә» сүзләрен өстәргә;

в) 8 өлештә «бүтән комиссияләрдә» сүзләреннән соң «, алар вакытыннан алда тавыш бирүне уздырганда,» сүзләрен өстәргә;

г) 12 өлештә «участок комиссиясенә — » сүзләреннән соң «вакытыннан алда тавыш бирү чорында яисә» сүзләрен өстәргә;

д) 14 өлештә:

1 пунктта «бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестры, комиссиядәге бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) чакыртып алу буенча тиешле тавыш бирү участогының тавыш бирү бинасында тавыш бирү көнендә, шулай ук вакытыннан алда тавыш бирү көннәрендә әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән чорда теләсә кайсы вакытта булырга;»;

11) 25 статьяда:

а) 3 өлештә «йә бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары булудан гыйбарәт» сүзләрен «була» сүзенә алмаштырырга;

б) 12 өлештә «20 көннән дә» сүзләрен «10 көннән дә» сүзләренә алмаштырырга;

в) 14 өлештә «20 көн кала» сүзләрен «10 көн кала» сүзләренә алмаштырырга;

г) 15 өлештә:

бишенче җөмләдә «, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән очракта» сүзләрен төшереп калдырырга;

җиденче җөмләдә «, ә бүтән чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында тавыш бирү таныклыгы бирелгәндә бүтән чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында тавыш бирү таныклыгын биргән комиссия әгъзасы имзасы белән таныклана» сүзләрен төшереп калдырырга;

12) 26 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирү участоклары**

1. Тавыш бирүне уздыру һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын санау өчен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә төзелгән бердәй сайлау участоклары, референдум участоклары файдаланыла.

2. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар вакытлыча булу урыннарында (хастаханәләрдә, шифаханәләрдә, ял йортларында, вокзалларда, аэропортларда, шик белдерелүче һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарында һәм башка вакытлыча булу урыннарында) чакыртып алу буенча тавыш бирү участоклары территория комиссиясе тарафыннан ул билгеләгән срокка тавыш бирү көненә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча, ә аерым очракларда – тавыш бирү көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча төзелергә мөмкин.

3. Чакыртып алу буенча тавыш бирү участоклары исемлекләре, чикләрен (әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы торак пункт территориясенең бер өлешендә урнашкан булса) йә торак пунктлар исемлеген (әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы бер яисә берничә торак пункт территориясендә урнашкан булса) һәм участок комиссияләренең һәм тавыш бирү биналарының номерларын, урнашу урыннарын күрсәтеп, тавыш бирү көненә кадәр 40 көннән дә соңга калмыйча, муниципаль район, шәһәр округы җирле администрациясе башлыгы тарафыннан бастырып чыгарылырга тиеш. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар вакытлыча булу урыннарында (хастаханәләрдә, шифаханәләрдә, ял йортларында, вокзалларда, аэропортларда, шик белдерелүче һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарында һәм башка вакытлыча булу урыннарында) төзелгән чакыртып алу буенча тавыш бирү участоклары турындагы мәгълүмат, алар төзелгән көннән ике көннән дә соңга калмыйча, әлеге учреждениеләрнең администрацияләре тарафыннан чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга җиткерелергә һәм территория комиссиясе тарафыннан бастырып чыгарылырга тиеш.»;

13) 34 статьяның 1 өлешендә «яисә үзләре күрсәткән кандидатлар исемлекләренә Татарстан Республикасы Сайлау кодексының $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган булса» сүзләрен төшереп калдырырга;



14) 39 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны гамәлгә ашыручы комиссияләрнең түбәндәге чыгымнары финанслана:

1) чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны гамәлгә ашыручы комиссияләрнең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларына, чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны гамәлгә ашыручы комиссияләр аппаратлары хезмәткәрләренә хезмәт өчен өстәмә түләүгә (бүләкләүгә), чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләү һәм уздыру чорына төп эшеннән азат ителгән чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны гамәлгә ашыручы комиссияләрнең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларына компенсацияләр түләүгә, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны гамәлгә ашыручы комиссияләрдә граждан-хокукый шартнамәләр буенча эшләүче гражданнарга һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны гамәлгә ашыручы комиссияләр каршындагы контроль-ревизия хезмәтләре составында эшләү өчен җибәрелә торган белгечләргә түләүләр;

2) басма продукцияне чыгару һәм нәширлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру чыгымнары;

3) чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләү һәм уздыру, чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны гамәлгә ашыручы комиссияләрнең эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле җайланмалар (шул исәптән технологик), башка матди кыйммәтләр сатып алу, китерү һәм урнаштыру;

4) транспорт чыгымнары;

5) чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүгә һәм уздыруга кагылышлы документларны китерү һәм саклау, аларны архивка тапшыру өчен әзерләү яисә юкка чыгару;

6) чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүгә һәм уздыруга, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны гамәлгә ашыручы комиссияләрнең эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле командировкалар һәм башка максатлар;

7) автоматлаштыру чараларыннан файдалану һәм аларны эшләтү, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның хокукый культурасын арттыру һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүне оештыручыларны укыту.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 7 һәм 8 өлешләр өстәргә:

«7. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздырганда кулланыла торган бюллетеньнәрне, махсус билгеләрне (маркаларны) сатып алу «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау

хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

8. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләү һәм уздыруга бәйле товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу чакыртып алу буенча комиссияләр тарафыннан тиешле бюджетның расланган бюджет язмасы нигезендә чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турында карар бастырып чыгарылган (бастырылган) көнгә кадәр башкарылырга мөмкин.»;

15) 43 статьяның 8 өлешендә «бинасында» сүзеннән соң «, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан расланган технологик җайланмалар нормативларына туры китереп, үтә күренмәле яисә яртылаш үтә күренмәле материалдан әзерләнгән» сүзләрен өстәргә;

16) 44 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

17) 45 статьяның 9 өлешендәге беренче җөмләсендә «тавыш бирү» сүзләреннән соң «(шул исәптән алдан тавыш бирү)» сүзләрен өстәргә;

18) 46 статьяда:

а) 2 өлештә «20 көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен «10 көннән дә соңга калмыйча, ә вакытыннан алда һәм кабат тавыш бирү уздырганда – тавыш бирү көненә кадәр биш көннән дә соңга калмыйча,» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «тавыш бирү башланыр алдыннан» сүзләрен «нәкъ тавыш бирү вакыты җитәр алдыннан» сүзләренә алмаштырырга, «чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга,» сүзләрен төшереп калдырырга, «(пломба куела)» сүзләрен өстәргә;

в) 5 өлештә «, әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш бирсә, – шулай ук бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы да күрсәтелә» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 6 өлешнең дүртенче җөмләсен төшереп калдырырга;

д) 14 өлешнең икенче җөмләсен төшереп калдырырга;

19) түбәндәге эчтәлекле 46[1] статья өстәргә:

«46[1] статья. **Чакыртып алу буенча вакытыннан алда тавыш бирү**



1. Чакыртып алу буенча тавыш бирү уздырганда тавыш бирү көнендә нигезле сәбәп (отпуск, командировка, хезмәт һәм уку эшчәнлеге режимы, дәүләт һәм иҗтимагый вазыйфалар үтәү, сәламәтлеге торышы һәм башка нигезле сәбәпләр) аркасында үзенең тору урынында була алмаган һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында тавыш бирү бинасына килә алмаган чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыга вакытыннан алда тавыш бирү мөмкинлеге бирелергә тиеш. Вакытыннан алда тавыш бирү чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы тарафыннан территория комиссиясе (тавыш бирү көненә кадәр 10 – 4 көн кала) яисә участок комиссиясе бинасында (тавыш бирү көненә кадәр өч көннән дә иртәрәк түгел) бюллетень тутыру юлы белән үткәрелә.

2. Чакыртып алу буенча, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда, Татарстан Республикасы референдумында, җирле үзидарә органнарына сайлауларда, җирле референдумда тавыш бирү көне законда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары белән тавыш бирү каралган башка сайлауларда, референдумда тавыш бирү көне белән берләштерелгән очракта, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирә торган комиссия бинасында вакытыннан алда (әмма тавыш бирү көненә кадәр 10 көннән дә иртәрәк түгел) тавыш бирә ала.

3. Вакытыннан алда тавыш бирү башкарыла торган биналар әлеге Законның 43 статьясындагы 2 өлеше нигезендә җиһазландырылган һәм тәэмин ителгән булырга тиеш. Вакытыннан алда тавыш бирү биналары җиһазы вакытыннан алда тавыш бирүне уздырганда тиешле комиссиянең барлык әгъзаларының, күзәтүчеләрнең, әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затларның булу мөмкинлеген күздә тотарга тиеш. Вакытыннан алда тавыш бирү эш көннәрендә кичке вакытта (җирле вакыт буенча 16 сәгатьтән соң) һәм ял көннәрендә көненә кимендә дүрт сәгать уздырыла. Вакытыннан алда тавыш бирүне уздыру өчен комиссия эше графигы Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе яисә аның йөкләмәсе белән түбәнгерәк комиссияләр тарафыннан билгеләнә, тиешле комиссиянең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтына (булган очракта) урнаштырыла, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылырга яисә башка ысул белән халыкка игълан ителергә тиеш. Вакытыннан алда тавыш бирү, әлеге Законның 46 статьясында каралган таләпләрне үтәп, әлеге статья белән билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып уздырыла. Вакытыннан алда тавыш бирүне оешты-

ру тавыш бирү серен тәэмин итәргә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының ихтыяр белдерүен бозып күрсәтү ихтималын калдырмаска, бюллетеньнең саклануын һәм тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының тавышын исәпкә алуны тәэмин итәргә тиеш.

4. Территория комиссиясе вакытыннан алда тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның исемлеген һәрбер чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы буенча аерым төзи.

5. Вакытыннан алда тавыш бирүче чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы тиешле комиссиягә, вакытыннан алда тавыш бирү сәбәбен күрсәтеп, гариза бирә. Гаризада чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, аның яшәү урыны адресы күрсәтелгән булырга тиеш. Тиешле комиссия әгъзасы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының гаризасында бу чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының вакытыннан алда тавыш бирүенең датасын һәм вакытын язып куя. Гариза вакытыннан алда тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның исемлегенә (ә участок комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш биргән очракта — чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның исемлегенә) теркәп куела.

6. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы территория комиссиясе бинасында тавыш бирсә, аңа бирелә торган бюллетеньнең алгы ягында өске уң почмакта территория комиссиясенең ике әгъзасының имзалары куела, алар комиссия мөһере белән таныклана. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы бюллетень алганда, вакытыннан алда тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның исемлегендә аның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, туган елы (18 яшьтә булса — өстәмә рәвештә туган көне һәм ае), яшәү урыны адресы күрсәтелә, шуннан соң чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы исемлектә үзенең паспортының яисә граждан паспортын алыштыра торган документның сериясен һәм номерын язып куя. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы күрсәткән паспортның яисә граждан паспортын алыштыра торган документның сериясе һәм номеры аның ризалыгы белән яисә аның үтенече буенча хәлиткеч тавыш хокукына ия комиссия әгъзасы тарафыннан язып куелырга мөмкин. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы язманың дөреслеген тикшерә һәм тиешле графада бюллетень алуы турында кул куя. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыга бюллетень биргән комиссия әгъзасы шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүдә



вакытыннан алда тавыш биргән катнашучылар исемлегенең тиешле графасына кул куя.

7. Вакытыннан алда тавыш бирү уздыру өчен үтә күренмәле булмаган махсус конвертлар кулланыла. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә вакытыннан алда тавыш биргән катнашучы тутырган бюллетень ябыштырып куела торган конвертка чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы тарафыннан яшерен тавыш бирү урыныннан читтә салына. Конвертның ябыштырылган урынында территория комиссиясенең яисә участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия ике әгъзасы, шулай ук киңәш бирү тавышы хокукына ия комиссия әгъзалары, күзәтүчеләр (теләк буенча) имза сала. Күрсәтелгән имзалар тиешле комиссия мөһере белән таныклана.

8. Бюллетеньнәр салынган мөһерләнгән конверт тиешле комиссиянең секретарендә саклана: территория комиссиясе бинасында — бюллетеньнәр салынган конвертлар участок комиссиясенә тапшырылган вакытка кадәр, участок комиссиясе бинасында — тавыш бирү көненә кадәр.

9. Территория комиссиясе теркәп куелган чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның вакытыннан алда тавыш бирү турындагы гаризалары белән бергә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә вакытыннан алда тавыш биргән катнашучыларның тиешле исемлеген, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә вакытыннан алда тавыш биргән катнашучыларның бюллетеньнәре салынган конвертларны тавыш бирү көненә кадәрге көннән дә соңга калмыйча түбәндгерәк һәр участок комиссиясенә тапшыра.

10. Участок комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүдә вакытыннан алда тавыш биргән катнашучыларның исемлеген алганнан соң ук чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегендә территория комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның фамилиясе янына «Вакытыннан алда тавыш бирде» дигән тамга куя. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә вакытыннан алда тавыш биргән катнашучылар исемлеге аңа теркәп куелган чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның вакытыннан алда тавыш бирү турындагы гаризалары белән бергә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә теркәп куела. Әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы участок комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш бирсә, «Вакытыннан алда тавыш бирде» дигән тамга бюллетень биргәндә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә куела.

11. Вакытыннан алда тавыш биргән, шул исәптән территория комиссиясе бинасында, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә

катнашучылар саны турында һәр чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы буенча мәгълүмат тавыш бирү көненә кадәр участок комиссиясе, территория комиссиясе тарафыннан турыдантуры югарырак сайлау комиссиясенә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан – Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә һәм срокларда тапшырыла.

12. Участок комиссиясе рәисе чакыртып алу буенча тавыш бирү көнендә тавыш бирү башланыр алдыннан, әмма тавышларны санауның техник чараларын әзерләгәннән һәм аларны тавыш бирү режимына күчергәннән соң (алардан файдаланган очракта), участок комиссияләре әгъзалары, күзәтүчеләр, әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затлар булганда шул чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә вакытыннан алда тавыш биргән, шул исәптән территория комиссиясе бинасында, катнашучыларның саны турында хәбәр итә, күреп танышу өчен бюллетеньнәр салынган мөһерләнгән конвертны бирә. Шуннан соң участок комиссиясе рәисе бер-бер артлы һәр конвертны ача бара.

13. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә вакытыннан алда тавыш биргән катнашучыларның саны чакыртып алу буенча тавыш бирү участогындагы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар санының бер процентыннан артып китсә (ләкин кимендә ун чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы), чакыртып алу буенча тавыш бирүдә вакытыннан алда тавыш биргән катнашучыларның конвертларыннан алынган бюллетеньнәрнең арткы ягына бюллетеньнәр конвертлардан алынганнан соң ук участок комиссиясе мөһере куела.

14. Әлеге статьяның 12 һәм 13 өлешләрендә күрсәтелгән гамәлләрне башкарганнан соң участок комиссиясе рәисе, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның ихтыяр белдерү серен саклап, бюллетеньнәрне тавыш бирү өчен стационар тартмага яисә тавышларны санауның техник чарасына (ул кулланылган очракта) сала. Әгәр конвертта әлеге статьяның 7 өлешендә каралган реквизитлар булмаса яисә конверттан чакыртып алу буенча тавыш бирү өчен билгеләнгән формадагы бердән артык бюллетень алынган булса, бу конверттан чыгарылган барлык бюллетеньнәр гамәлгә яраксыз дип таныла, бу хакта акт төзелә. Әлеге һәрбер бюллетеньнең алгы ягына, «Чакыртып алу өчен» яисә «Чакыртып алуга каршы» позицияләреннән уң якта



урнашкан шакмакларга бюллетеньнең гамәлгә яраксызлыгын тану сәбәбе язып куела, ул участок комиссиясенең хәлиткеч тавышка ия ике әгъзасының имзасы белән раслана һәм участок комиссиясе мөһере белән таныклана.»;

20) 47 статьяда:

а) 5 өлештә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән гаризалар (телдән мөрәҗәгатьләр) тавыш бирү көненә кадәр 10 көн дәвамында теләсә кайсы вакытта, ләкин тавыш бирү вакыты тәмамланырга алты сәгатьтән дә соңга калмыйча тапшырылырга мөмкин.»;

б) 8 өлешнең беренче җөмләсендә «тиешле санда» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан расланган технологик җайланмалар нормативларына туры китереп, үтә күренмәле яисә яртылаш үтә күренмәле материалдан әзерләнгән» сүзләрен өстәргә.

21) 48 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$. Чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә электрон рәвештә төзелергә мөмкин.»;

б) 2 өлештә:

беренче абзацта беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә кәгазьдә рәсмиләштерелсә, ул бер биттә төзелергә тиеш.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) түбәндәге эзлеклелектә беркетмә юллары:

1 юл: тавыш бирү тәмамланган вакытка исемлеккә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар саны;

2 юл: участок комиссиясе алган бюллетеньнәр саны;

3 юл: вакытыннан алда тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга, шул исәптән аерым 4 юлда – территория комиссиясе бинасында бирелгән бюллетеньнәр саны;

5 юл: тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

6 юл: тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

7 юл: юкка чыгарылган бюллетеньнәр саны;

8 юл: тавыш бирү өчен күчерелмә әрҗәләрдәге бюллетеньнәр саны;

9 юл: тавыш бирү өчен стационар әрҗәләрдәге бюллетеньнәр саны;

10 юл: гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр саны;

11 юл: гамәлгә яраклы бюллетеньнәр саны;

12 юл: югалган бюллетеньнәр саны;

13 юл: алганда исәпкә кертелмәгән бюллетеньнәр саны;

14 юл һәм аннан соңгы юллар: чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бюллетеньнәрендәге «Чакыртып алу өчен» һәм «Чакыртып алуга каршы» позицияләре буенча бирелгән тавышлары саны;»;

9 пунктка «(кәгазьгә язылган беркетмә өчен)» сүзләрен өстәргә;

22) 49 статьяда:

а) 3 өлештә «5 юлына» сүзләрен «7 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлешнең беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Участок комиссиясе рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре участок комиссиясе тарафыннан алынган бюллетеньнәрнең санын төгәлләштерә, игълан итә һәм аны тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 2 юлына кертә (территория комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның конвертлардан алынган бюллетеньнәре турындагы мәгълүматлар күрсәтелгән санга керми).»;

в) 5 өлештә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) тавыш бирү тәмамланган вакытка чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның исемлегенә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар санын (нинди дә булса сәбәпләр аркасында төшеп калган чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны исәпкә алмыйча);»;

түбәндәге эчтәлекле $3^{1}$ пункт өстәргә:

«$3^{1}$) вакытыннан алда тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны (чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегендә тиешле тамгалар саны буенча билгеләнә; территория комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар саны вакытыннан алда тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеге буенча тикшерелә).»;

4 – 6 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

г) 6 өлештә:

түбәндәге эчтәлекле $1^{1}$ пункт өстәргә:



«$1^{1}$) 3 һәм 4 юлларга – вакытыннан алда тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;»;

2 пунктта «3 юлга» сүзләрен «5 юлга» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «4 юлга» сүзләрен «6 юлга» сүзләренә алмаштырырга;

4 – 8 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

унынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

д) 12 өлештә «6 юлына» сүзләрен «8 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

е) түбәндәге эчтәлекле $14^{1}$ өлеш өстәргә:

«$14^{1}$. Территория комиссиясе бинасында вакытыннан алда тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар саны (вакытыннан алда тавыш бирүне территория комиссиясе һәм участок комиссиясе биналарында уздырган очракта – күрсәтелгән комиссия биналарында вакытыннан алда тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар саны) чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар санының бер процентыннан күбрәк булса (ләкин ун чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыдан ким түгел), участок комиссиясе, комиссиянең теләсә кайсы әгъзасы, күзәтүче таләбе буенча, арткы якларына әлеге Законның $46^{1}$ статьясындагы 13 өлеше нигезендә участок комиссиясе мөһере сугылган бюллетеньнәр буенча тавышларны аерым исәпләргә тиеш. Күрсәтелгән исәпләүләр нәтиҗәләре буенча участок комиссиясе акт төзи, ул тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәгә теркәп куела.»;

ж) 15 өлешнең җиденче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Гамәлгә яраксыз бюллетеньнәрнең гомуми саны (әлеге статьяның 12 өлеше һәм әлеге Законның $46^{1}$ статьясындагы 14 өлеше нигезендә гамәлгә яраксыз дип танылган бюллетеньнәр санын исәпкә алып) тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 10 юлына язып куела.»;

з) 16 өлештә «10 юлына» сүзләрен «14 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

и) 17 өлештә «9 юлына» сүзләрен «11 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

к) 18 өлештә «7 юлына» сүзләрен «9 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

л) 20 өлештә «9д һәм 9е юлларына» сүзләрен «12 һәм 13 юлларына» сүзләренә алмаштырырга, «9д һәм 9е юлларында» сүзләрен «12 һәм 13 юлларында» сүзләренә алмаштырырга;

м) 21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. Санау тәмамланганнан соң, бюллетеньнәр чакыртып алуда тавыш бирүчеләрнең «Чакыртып алу өчен» һәм «Чакыртып алуга каршы» биргән тавышлары буенча аерым төргәкләргә төреп куела. Гамәлгә яраксыз һәм юкка чыгарылган бюллетеньнәр аерым төргәкләргә төреп куела. Һәр төргәктә андагы бюллетеньнәрнең саны күрсәтелә һәм төргәкләнгән бюллетеньнәрнең эчтәлегенә туры килә торган тамга салына. Шул рәвешле җыеп куелган бюллетеньнәр, шулай ук әлеге статьяның 11 һәм 12 өлешләре нигезендә төргәкләнгән бюллетеньнәр, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның төргәкләнгән исемлеге капчыкларга яисә тартмаларга тутырыла, анда чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы номеры, барлык төргәкләнгән бюллетеньнәрнең саны күрсәтелә. Капчыкларга яисә тартмаларга мөһер сугыла, һәм алар бары тик чакыртып алу буенча югарырак комиссия яисә суд карары буенча гына ачылырга мөмкин. Күрсәтелгән капчыкларга яисә тартмаларга участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары да, киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары да үз имзаларын куярга хокуклы. Төргәкләү әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән затлар барында башкарыла, һәм аларга капчыкларга яисә тартмаларга үз имзаларын кую мөмкинлеге бирелә.»;

н) 22 өлештә:

3 пунктта «1, 2, 3, 4, 5 һәм 9а, 9б, 9в, 9г, 9г – 1, 9г – 2 юлларына» сүзләрен «1, 2, 3, 4, 5, 6, 7 юлларына» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «6, 7, 8, 9, 10 юлларына һәм аннан соңгы юлларына» сүзләрен «8, 9, 10, 11, 14 юлларына һәм аннан соңгы юлларына» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «9д һәм 9е юлларына» сүзләрен «12 һәм 13 юлларына» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6) әлеге статьяның $14^{1}$ өлешендә каралган очракта участок комиссиясе, вакытыннан алда тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның конвертларыннан алынган һәм арткы якларына участок комиссиясе мөһере куелган бюллетеньнәрне аерып куеп, бюллетеньнәрне сортларга аера. Күрсәтелгән бюллетеньнәр буенча аерым исәпләүләр кулдан яисә тавышларны санауның техник чараларын кулланып башкарыла. Күрсәтелгән исәпләүләрнең нәтиҗәләре буенча участок комиссиясе акт төзи, ул тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә теркәп куела.»;

о) 23 өлештә «8, 9, 10 юлларының берсендә һәм калган юлларында» сүзләрен «10, 11, 14 юлларының берсендә һәм калган юлларында» сүзләренә алмаштырырга;

п) 27 өлешкә түбәндәге эчтәлекле икенче һәм өченче җөмләләр өстәргә: «Әгәр беркетмә электрон рәвештә төзелгән булса, аның күчермәсе беркетмәне кәгазьгә чыгару юлы белән ясала һәм «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда билгеләнгән тәртиптә таныклана. Беркетмәләрнең бирелә торган күчермәләренә номерлар сугыла.»;

р) 29 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең икенче нөсхәсе танышу өчен күзәтүчеләргә, әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән бүтән затларга бирелә, ә аның таныкланган күчермәсе гомуми танышу өчен участок комиссиясе билгеләгән урынга элеп куела. Әгәр беркетмә электрон рәвештә төзелгән булса, аның күчермәсе беркетмәне кәгазьгә чыгару юлы белән ясала һәм, чакыртып алу буенча тавыш бирүгә йомгак ясаганда һәм беркетмәне төзегәндә, шунда булган участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия барлык әгъзалары тарафыннан имзалана. Беркетмәнең икенче нөсхәсе әлеге Законда каралган чакыртып алу буенча тавыш бирү документлары белән бергә, бюллетеньнәрне, участок комиссиясенең киңәш бирү хокукына ия әгъзалары, әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затлар исемлеген кертеп, шулай ук участок комиссиясе мөһере чакыртып алу буенча югарырак комиссиягә саклау өчен тапшырыла.»;

с) 32 өлештә «8, 9, 10 юлларның һичьюгы берсендә һәм калган юлларында» сүзләрен «10, 11, 14 юлларның һичьюгы берсендә һәм калган юлларында» сүзләренә алмаштырырга;

т) 33 өлештә «8, 9, 10 юлларында һәм аннан соңгы юлларында» сүзләрен «10, 11, 14 юлларында һәм калган юлларында» сүзләренә алмаштырырга;

у) 38 өлештә «1 – 9, 9а – 9е юлларында» сүзләрен «1 – 13 юлларында» сүзләренә алмаштырырга; «1 – 9, 9а – 9е юлларына» сүзләрен «1 – 13 юлларына» сүзләренә алмаштырырга; «10 юлына» сүзләрен «14 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

23) 50 статьяда:

а) 8 өлешнең бишенче җөмләсен төшереп калдырырга;

б) 13 өлештә «1 — 9, 9а — 9е юлларына» сүзләрен «1 — 13 юлларына» сүзләренә алмаштырырга; «10 юлына» сүзләрен «14 юлына» сүзләренә алмаштырырга;

24) 51 статьяда:
а) 2 һәм 3 өлешләрне үз көчләрен югалткан дип танырга;
б) 9 өлештә «, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

25) 2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

26) 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Президентын чакыртып алу тәртибе турында»
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

ТАВЫШ БИРҮ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ БЕРКЕТМӘГӘ КЕРТЕЛГӘН КҮРСӘТКЕЧЛӘРНЕҢ КОНТРОЛЬ ЧАГЫШТЫРМАЛАРЫ (ӘЛЕГЕ ЗАКОННЫҢ 48 СТАТЬЯСЫ НИГЕЗЕНДӘ НОМЕРЛАНГАН БЕРКЕТМӘ ЮЛЛАРЫ САННАР БЕЛӘН БИЛГЕЛӘНДЕ)

| | |
|---|---|
| 1 күбрәк яисә тигез | 3 + 5 + 6 |
| 2 тигез | 3 + 5 + 6 + 7 + 12 –13 |
| 8 + 9 тигез | 10 + 11 |
| 11 тигез | 14 + беркетмәнең шуннан соңгы барлык юллары». |

**5 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең эшчәнлеген региональ телеканал һәм радиоканал аша яктыртканда аларның тигезлек гарантияләре турында» 2010 елның 30 июлендәге 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1) Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партия — Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлеген



күрсәткән сәяси партия. Кандидатлар исемлеген күрсәткән сәяси партия дигәндә, әлеге Закон максатларында республика бүлекчәсе кандидатлар исемлеген күрсәткән сәяси партия дип тә аңларга кирәк;»;

2) 4 статьяның 2 өлешендә:
а) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3) күрсәтелгән сәяси партия төзегән фракциягә керүче Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларының;»;

б) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4) Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарының күрсәтелгән сәяси партиянең депутат берләшмәләре (фракцияләре) әгъзалары булып торучы депутатларының, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары депутатларының — күрсәтелгән сәяси партия әгъзаларының;».

**6 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 26 мае
№ 41-ТРЗ

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҺӘМ АНЫҢ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 466. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының илле беренче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының илле беренче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Яңа Савин суд районы буенча 4 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
3. Татарстан Республикасы Зеленодольск суд районы буенча 1 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
4. Татарстан Республикасы Саба суд районы буенча 2 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
5. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы составына Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан кандидатуралар турында.
6. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 575-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).
7. «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 584-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (III укылыш).
8. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 564-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).



9. «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә Татарстан Республикасының дәүләт ярдәме турында» 7404-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).
10. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 585-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
11. «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 601-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
12. «Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 596-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
13. «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 609-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
14. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 8 һәм 73 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 583-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
15. «Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» 604-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
16. «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 595-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
17. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «Бердәм Россия» депутат фракциясе составындагы «Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлар берләшмәсенең 2009 – 2014 еллардагы эшчәнлеге турында мәгълүмат.
18. 2013 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында баланың хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау турында доклад.
19. «Сугыш чоры балалары турында» 493165-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

20. «Балигъ булмаганнарның хокукларын яклау максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проекты хакында.

21. «Азартлы уеннарны оештыру һәм үткәрү эшчәнлеген дәүләт җайга салуы турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 482193-6 номерлы федераль закон проекты хакында (букмекер контораларында һәм тотализаторларда азартлы уеннарны оештыручыларның дәүләт һәм (яисә) муниципаль физкультура-спорт оешмаларында физик культураны һәм спортны финанслау өчен максатчан акча күчерүләрне гамәлгә ашыру бурычларын билгеләү өлешендә).

22. «Россия Федерациясе Торак кодексының 155 статьясына үзгәреш кертү турында» 471133-6 номерлы федераль закон проекты хакында (авария хәлендәге һәм сүтелергә тиеш дип танылган күпфатирлы йортларда милекчеләрне агымдагы ремонт өчен түләүләр кертүдән азат итү өлешендә).

23. «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында» Федераль законның 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 493976-6 номерлы федераль закон проекты турында (статья редакциясен төгәлләштерү өлешендә).

24. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 392886-6 номерлы федераль закон проекты хакында (ялган, контрафакт, сыйфатсыз һәм теркәлү узмаган дарулар, медицина чаралары әйләнешенә каршы көрәш өлешендә).

25. «Россия Федерациясендә суд берләшмәсе органнары турында» Федераль законның 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Калуга өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

26. «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Мордовия Республикасы Дәүләт Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

27. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 495129-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына Россия Федерациясе вәкаләтләрен бирү тәртибе хакында).



28. «Дәүләт социаль ярдәме турында» Федераль законның 12.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 475464-6 номерлы федераль закон проекты турында (Икенче бөтендөнья сугышы тәмамланган көнгә (1945 елның 2 сентябре) 18 яшьтә булмаган эшләмәүче пенсионерларга пенсиягә федераль социаль өстәмәне арттырылган күләмдә түләү хакында).

29. «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» 475804-6 номерлы федераль закон проекты турында (ятим балаларны, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны һәм авыр тормыш хәлендә булган балаларны дәүләт сәламәтлек саклау системасының һәм муниципаль сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларында тәрбияләү яше өлешендә).

30. «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законның $34^3$ статьясына үзгәреш кертү хакында» 485637-6 номерлы федераль закон проекты турында (спорт әзерлеге үтүгә җитәкчелек итүче тренерларның квалификациясен күтәрү өлешендә).

31. Сафиуллин Дамир Харун улының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.

32. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты составы үзгәрү турында.

33. «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе составы үзгәрү турында.

34. Хөкүмәт сәгате: «2012, 2013 елларда Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программаларын гамәлгә ашыру йомгаклары һәм 2014 елда Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасын гамәлгә ашыру барышы турында».

35. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3553-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 467. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары итеп биш елга түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Авиатөзелеш суд районы буенча:
2 нче суд участогына – Гафурова Светлана Равил кызын;

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Идел буе суд районы буенча:
6 нчы суд участогына – Вафина Лилия Кәрим кызын;

Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча:
5 нче суд участогына – Аксакова Анастасия Анатольевнаны.

2. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә сайланган Гафурова Светлана Равил кызының һәм Аксакова Анастасия Анатольевнаның Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вәкаләтләре чоры аларның моннан алдагы вәкаләтләре чоры тәмамланган көннән башлана.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3554-IV ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 468. Татарстан Республикасы Казан шәһәре Яңа Савин суд районы буенча 4 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында

«Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законының $7^1$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Яңа Савин суд районы буенча 4 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфасын башкаруны бер елга отставкадагы судья Кальвик Надежда Витальевнага йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3555-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 469. Татарстан Республикасы Зеленодольск суд районы буенча 1 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында

«Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законының $7^1$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Зеленодольск суд районы буенча 1 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфасын башкаруны бер елга отставкадагы судья Гатина Фирдәвес Гәрәфетдин кызына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3556-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 470. Татарстан Республикасы Саба суд районы буенча 2 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында

«Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законының $7^1$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Саба суд районы буенча 2 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкаруны бер елга отставкадагы судья Вафин Идеал Вәгыйзь улына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3557-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 471. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасын раслау турында

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 159 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы итеп «Яңа гасыр» автоном хәйрия коммерциясез оешмасының гамәлгә куючысы һәм директоры Таишева Лилия Әхәт кызын расларга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3558-IV ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 472. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (575-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын (575-4 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3559-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 473. «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (584-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (584-4 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3560-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 474. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (564-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын (564-4 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3561-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 475. «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә Татарстан Республикасының дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы законы хакында (7404 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә Татарстан Республикасының дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы законын (7404 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3562-IV ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 476. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 585-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 585-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3563-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 477. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (585-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (585-4 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3564-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 478. «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 601-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 601-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3565-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 479. «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (601-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (601-4 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3566-IV ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 480. «Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 596-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 596-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3567-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 481. «Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (596-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (596-4 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3568-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 482. «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 609-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары М.Ә. Гаделшин, А.Ф. Шәрипова тарафыннан кертелгән «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 609-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3569-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 483. «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (609-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (609-4 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3570-IV ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 484. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 8 һәм 73 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 583-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.В. Прокофьев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 8 һәм 73 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 583-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын кире кагарга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3571-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 485. «Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» 604-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Р.И. Вәлиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» 604-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3572-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 486. «Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында (604-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (604-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3573-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 487. «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 595-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.В. Прокофьев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 595-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын кире кагарга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3574-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 488. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «Бердәм Россия» депутат фракциясе составындагы «Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлар берләшмәсенең 2009 – 2014 еллардагы эшчәнлеге турында мәгълүмат хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «Бердәм Россия» депутат фракциясе составындагы «Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлар берләшмәсенең 2009 – 2014 еллардагы эшчәнлеге турында мәгълүматны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3575-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 489. 2013 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында баланың хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау турында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил доклады хакында

2013 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында баланың хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау турында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил докладын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. 2013 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында баланың хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау турында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Г.Л. Удачинаның докладын игътибарга алырга.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы министрлыкларына һәм ведомстволарына, муниципаль берәмлекләр башлыкларына 2013 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында баланың хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау турында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил докладындагы тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру чараларын, шулай ук бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча чаралар комплексын эшләү чараларын күрүне тәкъдим итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3576-IV ДС



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 490. «Сугыш чоры балалары турында» 493165-6 номерлы федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Сугыш чоры балалары турында» 493165-6 номерлы федераль закон проекты концепциясен хупларга.
2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3577-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 491. «Балигъ булмаганнарның хокукларын яклау максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Балигъ булмаганнарның хокукларын яклау максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын хупларга.
2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3578-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 492. «Азартлы уеннарны оештыру һәм үткәрү эшчәнлеген дәүләт җайга салуы турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 482193-6 номерлы федераль закон проекты хакында (букмекер контораларында һәм тотализаторларда азартлы уеннарны оештыручыларның дәүләт һәм (яисә) муниципаль физкультура-спорт оешмаларында физик культураны һәм спортны финанслау өчен максатчан акча күчерүләрне гамәлгә ашыру бурычларын билгеләү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Азартлы уеннарны оештыру һәм үткәрү эшчәнлеген дәүләт җайга салуы турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 482193-6 номерлы федераль закон проектын (букмекер контораларында һәм тотализаторларда азартлы уеннарны оештыручыларның дәүләт һәм (яисә) муниципаль физкультура-спорт оешмаларында физик культураны һәм спортны финанслау өчен максатчан акча күчерүләрне гамәлгә ашыру бурычларын билгеләү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3579-IV ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 493. «Россия Федерациясе Торак кодексының 155 статьясына үзгәреш кертү турында» 471133-6 номерлы федераль закон проекты хакында (авария хәлендәге һәм сүтелергә тиеш дип танылган күпфатирлы йортларда милекчеләрне агымдагы ремонт өчен түләүләр кертүдән азат итү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Торак кодексының 155 статьясына үзгәреш кертү турында» 471133-6 номерлы федераль закон проектын (авария хәлендәге һәм сүтелергә тиеш дип танылган күпфатирлы йортларда милекчеләрне агымдагы ремонт өчен түләүләр кертүдән азат итү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3580-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 494. «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында» Федераль законның 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 493976-6 номерлы федераль закон проекты турында (статья редакциясен төгәлләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында» Федераль законның 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 493976-6 номерлы федераль закон проектын (статья редакциясен төгәлләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3581-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 495. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына ялган, контрафакт, сыйфатсыз һәм теркәлү узмаган дарулар, медицина чаралары һәм ялган биологик актив матдәләр әйләнешенә каршы көрәш өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 392886-6 номерлы федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына ялган, контрафакт, сыйфатсыз һәм теркәлү узмаган дарулар, медицина чаралары һәм ялган биологик актив матдәләр әйләнешенә каршы көрәш өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 392886-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.
2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3582-IV ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 496. «Россия Федерациясендә суд берләшмәсе органнары турында» Федераль законның 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Калуга өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә суд берләшмәсе органнары турында» Федераль законның 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Калуга өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.
2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Калуга өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3583-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 497. «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Мордовия Республикасы Дәүләт Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»

Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Мордовия Республикасы Дәүләт Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Мордовия Республикасы Дәүләт Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3584-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 498. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 495129-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына Россия Федерациясе вәкаләтләрен бирү тәртибе хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 495129-6 номерлы федераль закон проектын (Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына Россия Федерациясе вәкаләтләрен бирү тәртибе хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3585-IV ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 499. «Дәүләт социаль ярдәме турында» Федераль законның 12.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 475464-6 номерлы федераль закон проекты турында (Икенче бөтендөнья сугышы тәмамланган көнгә (1945 елның 2 сентябре) 18 яшьтә булмаган эшләмәүче пенсионерларга пенсиягә федераль социаль өстәмәне арттырылган күләмдә түләү турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Дәүләт социаль ярдәме турында» Федераль законның 12.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 475464-6 номерлы федераль закон проектын (Икенче бөтендөнья сугышы тәмамланган көнгә (1945 елның 2 сентябре) 18 яшьтә булмаган эшләмәүче пенсионерларга пенсиягә федераль социаль өстәмәне арттырылган күләмдә түләү турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3586-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 500. «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» 475804-6 номерлы федераль закон проекты турында (ятим балаларны, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны һәм авыр тормыш хәлендә булган балаларны дәүләт сәламәтлек саклау системасының һәм муниципаль сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларында тәрбияләү яше өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» 475804-6 номерлы федераль закон проектын (ятим балаларны, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны һәм авыр тормыш хәлендә булган балаларны дәүләт сәламәтлек саклау системасының һәм муниципаль сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларында тәрбияләү яше өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3587-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 501. «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законның $34^3$ статьясына үзгәреш кертү хакында» 485637-6 номерлы федераль закон проекты турында (спорт әзерлеге үтүгә җитәкчелек итүче тренерларның квалификациясен күтәрү өлешендә)

1. «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законның $34^3$ статьясына үзгәреш кертү хакында» 485637-6 номерлы федераль закон проектын (спорт әзерлеге үтүгә җитәкчелек итүче тренерларның квалификациясен күтәрү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3588-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 502. Сафиуллин Дамир Харун улының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 пунктының «а» пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

36 нчы Лениногорск бермандатлы сайлау округы буенча сайланган Сафиуллин Дамир Харун улының депутат вәкаләтләрен туктату турында язмача гаризасы нигезендә 2014 елның 19 маеннан аның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган дип санарга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3589-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 503. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты составындагы үзгәрешләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты составыннан Сафиуллин Дамир Харун улын чыгарырга.

2. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитетын сайлау турында» 2009 елның 19 мартындагы 17-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына, «14» санын «13» санына үзгәртеп, үзгәреш кертергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3590-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 504. «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе составы үзгәрү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе составыннан Сафиуллин Дамир Харун улын чыгарырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 мае
№ 3591-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 505. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының илле беренче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының илле беренче утырышын 2014 елның 21 маенда 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 14 мае
№ 3547-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 506. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының илле беренче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының илле беренче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.

2. Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Яңа Савин суд районы буенча 4 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.

3. Татарстан Республикасы Зеленодольск суд районы буенча 1 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.

4. Татарстан Республикасы Саба суд районы буенча 2 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.

5. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы составына Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан кандидатуралар турында.

6. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 575-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

7. «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 584-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (III укылыш).

8. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 564-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

